3. Йомшаклылык, ягымлылык, үз-үзен олы итеп тота белү сыйфатлары.
4. Ихласлылык, дикъкатьлелек, тырышлык сыйфатлары.
5. Балаларны сынап карау юлы белән тану, гыйлем өйрәнүгә мәхәббәт тәрбияләп кызыксындыру, түземлелек сыйфатлары.
6. Нәсыйхәт – яхшылыкка өндәү, тырышлык һәм теләктәшлек сыйфатлары.
7. Битәрләүдән тыелу һәм тырышлыкның бөеклеге.
8. Хөрмәт һәм мәхәббәт күрсәтү.
9. Дөреслек һәм игътибарлылык сыйфатлары.
10. Дәрес укыту ысулына игътибар итү.
11. Гыйлем сайлап алу.
12. Мәктәпнең һәм укытучыларның хәлен күзәтү.
13. Укытучы булган кеше өчен өстәмә кагыйдәләр:

– матур һәм килешле итеп сөйли белергә тиеш;
– язу сәнгатенә оста булырга һәм үзлегеннән иҗат итеп яза белергә тиеш;
– һәрвакытта үзе белән хәтер дәфтәре тотып, шунда ишетелгән яки күңелгә килгән сүзләрне язып беркетеп куеп, соңыннан, җае чыкканда, кирәк булганда аларны файдаланырга тиеш;
– тарих һәм сыйныфлар гыйлемен, шулай ук географияне бик яхшы белергә тиеш;
– укучы балаларга гыйлем бирүче һәм тәрбияләүче зат буларак, барлык кешеләргә караганда да гадел булырга тиеш. *(«Адәми тәгълим» китабыннан)*

Татар мәктәпләрендә программада Р.Фәхреддин хезмәтләре бирелгән, ә рус мәктәбендә аның «Балаларга үгет-нәсыйхәтләре»н сыйныф сәгатьләрендә өйрәтергә була, яшь эти-әниләргә «Ата-аналарга үгет-нәсыйхәтләре»н уку һәм укытучыларга югарыда әйтелгән унөч вазифаны кабатлап уку да комачауламас дип уйлыйм.

**Риза Фәхреддиннең туганы – җәмәгать эшлеклесе,**
**журналист һәм язучы Фатих Кәрими**

Миңлебай авылында Ризаэддин Фәхреддиннең туган апасы Мәгъсүмә яши, ул аны бик ярата һәм аның белән аерылгысыз була. Аның ире Гыйльман ахун Кәримов нәкъ менә кечкенә Ризаэддинга арифметиканың беренче дәресен укыткан кеше. Аларның улы, танылган журналист, язучы Фатих Кәрими, Р.Фәхретдин өчен туган гына түгел, ә дусты, хезмәттәше дә була. Гомере буе Р.Фәхретдин бу гаиләдән аерылмый. Юллары аерылгач, аларны хатлар тоташтырган. «Туганым Мөхәммәтфатих әфәнде! Сезнең иҗатыгыз, хезмәтегез һәм тырышлыгыгыз өчен рәхмәт йөзеннән, сезгә берәр нәрсә бүләк итәргә бик теләдем. Мин нәрсә бүләк итү турында уйлаганда, үз-үземнән фикер барлыкка килде: «Үз тәрҗемәмне язып күндерсәм, ничек булыр? Бу – лаеклы бүләк булыр,» – дип уйладым һәм сиңа бу кәгазьләрне җибәрдем. Ләкин белегез, минем иң зур бүләгем – җанымның чын мәхәббәте. Ә минем язганнарым моны раслау гына. Сезне яратучы Ризаэддин Фәхреддин.»

**Фатих Кәрими** хәзерге Әлмәт районы Миңлебай авылында 1870 нче елның 30 нчы мартында туа. Җиде ел Чистай мәдрәсәсендә укый, гарәп, фарсы телләрен өйрәнә. 1891нче елда Төркиягә китеп, Истанбул университетында белем ала, француз телен дә өйрәнә. Аннары Кырымда авыл мәктәбендә укыта, Бакчасарайда оештырылган укытучылар курсына җитәкчелек итә, әдәбият һәм педагогика дәресләре алып бара. Мәскәүгә барып, бухгалтерия курсларында укый, типография эшләренә өйрәнеп кайта. Төрек, гарәп, фарсы телләрен яхшы белә, русча һәм французча да иркен сөйләшә. Алтын приискасы хуҗасы Шакир Рәмиев белән Европа сәяхәтенә чыгып китәләр. Мәскәүдә, Петербургта, аннан Германия, Бельгия, Франция, Италия һәм башка шәһәрләрне күреп, дүрт ай йөреп, Төркия аша Оренбургка кайталар. Аларның максаты – бу илләрдәге культура учаклары белән танышу. Фатих Кәрими тарихи истәлекләрне, музей һәм китапханәләрне карап, өйрәнеп, көндәлек дәфтәренә язып бара. 1902нче елда «Аурупа сәяхәтнамәсе»н бастырып чыгара. Бу китабы аша ул татар җәмәгатьчелеген беренче мәртәбә Европа илләрендәге культура учаклары, әдәбият һәм сәнгать музейлары белән якыннанрак таныштыра. Татар әдәбияты дәреслегендә (8нче сыйныф) әлеге китаптан өзек урнаштырылган.

Кәримовлар гаиләсе белән Миңлебай авылында 1998нче елда оештырылган Фатих Кәримиләрнең музеенда танышырга мөмкин. Минем укытучым Мөдәрис Ибраһимов әлеге музейның эшчәнлеген башлап җибәрүче һәм оештыручы булды. Ул безне тарих фәненнән укытты, мәктәп директоры булып эшләде. Аның «Үз сукмагым», «Сайланма әсәрләр», «Гыйбрәтле гомер» дигән китаплары дөнья күрде. Шул ук вакытта бөтен көчен Фатих Кәрими турында мәгълүмат туплауга һәм музейны булдыруга юнәлтте. Фатих Кәрими эзләре буйлап, Оренбургка бара. Аннан Мәдинә Рәхимкулова тарафыннан, хәзерге телгә әйләндереп, күчереп язылган «Аурупа сәяхтнамәсе»н алып кайта. Бу күчерелмә авыл музеенда әле дә саклана. М.Рәхимкуллованың язуы искиткеч матур, пөхтә, аңлаешлы, укырга рәхәт.

**Йомгаклау**

Ризаэддин Фәхреддин исән вакытында тәрбия, тарих, дин гыйлемен яктырткан 148 китап бастыра. Һәр җирлектә үзенә генә хас, югалмас эз калдырган шәхес ул. Галимнең кайбер хезмәтләре кат-кат басылуы аның мәртәбәле шәхес икәнен күрсәтеп тора. Аның хезмәтләре бүгенгесе көндә дә бик актуаль, ә алардагы гыйбрәтле сүзләр алтын бәһасенә тиңләшерлек фикерләр булып кала бирәләр.

Татар әдәбиятының һәр жанрында диярлек бик күп әсәрләр язган Фатих Кәрими, журналистика һәм мәгариф эшчәнлеге белән беррәттән, хәзерге татар әдәбиятына нигез салучыларның берсе булып санала. Авторның «Комедия» (1894), «Хөсит бабай» (1895), «Бер шәкерт илә бер студент», (1899), «Җиһангир мәхдүмнең авыл мәктәбендә укуы» (1900), «Салих бабайның өйләнүе» (1897), «Мирза кызы Фатыйма» (1901) әсәрләрендә искелек белән яңалык арасындагы конфликт мәктәп-мәдрәсә контрасты аркылы чагылдырыла һәм укучыга аңлатыла. Аның әдәби әсәрләренә өстәп, үзе күргән җирләр турында язган «Аурупа сәяхәтнамәсе», «Кырымга

сәяхәт» һәм «Истамбул мәктүпләре» әсәрләре ачык, гади теле, стиленең матурлыгы белән татар әдәбиятында мөһим урын тота. Кәрими иҗатының төп идеясе – искечә укыту ысулларын тәнкыйтьләү, татар мәктәбендә реформалар үткәрү өчен көрәш.

**Кулланылган әдәбият**


1. Заһидуллина Д. Ф. Татар әдәбияты.– Казан: «Мәгариф» нәшрияты, 2004.-С.99
2. Ибраһимов Мөдәррис. Сайланма әсәрләр.– Казан: 2005.-272–349 б.
3. Мәшһүр мәгърифәтче-галим, педагог Ризаэддин Фәхреддин мирасын укыту-тәрбия процессында файдалану. – Казан., 2005.-200 б.
4. Ризаэтдин Фәхретдин: Фәнни-биографик җыентык.– Казан: «Рухият», 1999.-224 б.
5. Фәхреддин Ризаэддин.Гаилә.Тәрбияле ана.Тәрбияле хатын. –Казан: Рухият, 2021.-216 б.
6. Фәхреддин Ризаэддин. Балаларга нәсыйхәт. – Казан: Рухият, 2021.-216 б.
7. Фатих Кәрими. Аурупа сәяхәтнамәсе.– Татар әдәбияты. Казан «Мәгариф-вакыт» 2018.


## ВНЕДРЕНИЕ ПЕДАГОГИЧЕСКОГО НАСЛЕДИЯ ШИГАБУТДИНА МАРДЖАНИ


**Гильмутдинова Лилия Ринатовна**
*МБДОУ «Детский сад № 133 комбинированного вида»*
*Кировского района г. Казани*
*Воспитатель 1 кв. категории*


Полномасштабное освоение национального культурного наследия является актуальнейшей задачей современного общества. Педагогическое наследие Шигабутдина Марджани, одного из выдающихся татарских просветителей XIX века, активно изучается в контексте истории, педагогики, культуры и образования. Однако его внедрение в современную практику дошкольного образования остаётся недостаточно исследованной и систематизированной областью.

Шигабутдин Марджани был не только выдающимся учёным и богословом, но и замечательным педагогом, который уделял большое внимание воспитанию и образованию детей. Он очень любил учиться сам и учить других. Он хотел, чтобы все люди, особенно дети, могли узнавать новое и становиться умнее. Актуальность педагогического наследия великого татарского просветителя Шигабутдина Марджани подтверждается в различных научных трудах, образовательных программах и документах, связанных с сохранением культурного и исторического наследия Республики Татарстан. Его подход к обучению был основан на уважении к личности ребёнка, стремлении развивать в нём любознательность, критическое мышление и нравственные качества.

***Цель:***

Создание условий для гармоничного развития личности ребёнка через интеграцию педагогических идей Шигабутдина Марджани, направленных на уважение к личности, развитие любознательности, нравственное воспитание и сохранение культурных традицией.

***Задачи:***

1. Формирование уважительного отношения к личности ребёнка.
2. Развитие любознательности и познавательной активности.
3. Нравственное воспитание.
4. Вовлечение родителей в образовательный процесс.

Внедрение педагогического наследия Шигабутдина Марджани в современный детский сад требует творческого подхода, но его идеи остаются актуальными. Вот конкретные формы, методы и действия педагогического наследия Шигабутдина Марджани, подходящие для дошкольного образования:

***1. Уважение к уникальности ребёнка***

Марджани считал, что каждый ребёнок уникален и обладает своими способностями. Он учил детей с добротой и терпением, стараясь найти подход к каждому. «Ребёнок – это не сосуд, который нужно наполнить, а светильник, который нужно зажечь», – утверждал он.

Для реализации данного принципа в детском саду заполняются индивидуальные «Карты интересов». Каждому ребёнку создаётся карта, где отмечаются его склонности (любит рисовать, конструировать, слушать сказки). На основе этого планируются активности.

В группе организуются зоны («уголки») с разными видами занятий (творчество, эксперименты, чтение). Дети сами выбирают, чем заняться, развивая самостоятельность.

***2. Развитие любознательности через игру***

Он стремился пробудить в детях интерес к знаниям, учил их задавать вопросы и искать ответы. Марджани считал, что обучение должно быть интересным и увлекательным.

Создаются мини – проекты, связанные с природой, культурой или историей («Почему листья желтеют?», «Как жили наши предки?»). Дети вместе с воспитателем ищут ответы через опыты, рисунки, беседы. Дети очень любят экспериментировать. Простые опыты (смешивание цветов, наблюдение за ростом растений), где дети выдвигают гипотезы и делают выводы.

***3. Сочетание традиций и инноваций***

Шигабутдин Марджани учил детей уважать традиции, но при этом быть открытыми к новым знаниям. Он считал, что образование должно быть гармоничным и включать как духовные, так и светские науки. «Не забывайте свои корни, но и не бойтесь идти вперёд. Знания прошлого и настоящего – это два крыла, которые помогут вам взлететь».

В детском саду детям можно не только читать сказки, но и использовать интерактивную доску для показа татарских народных сказок с анимацией. После просмотра мультфильма – обсуждение: «Чему нас учит эта история?», «Что вам больше всего понравилось?»

Знакомство детей с татарским орнаментом происходит через аппликации, лепку из глины или роспись деревянных заготовок. Воспитанники создают «собственные» узоры для татарского национального костюма на бумаге. Дети также рассматривают традиционные татарские костюмы, играют в народные игры: «Түбәтәй».

***4. Нравственное воспитание***

Шигабутдин Марджани уделял большое внимание воспитанию в детях честности, доброты и уважения к другим. Он учил их быть ответственными и помогать тем, кто в этом нуждается. Цитата: «Самое важное в человеке – это его сердце. Будьте добрыми, честными и справедливыми, и тогда вы станете настоящими людьми»

С воспитанниками детского сада стоит обсудить различные ситуаций из жизни, например: «Как помочь другу?», «Почему нельзя обзываться?», «Как преодолеть страхи и стоять за то, что правильно?», «Как решать конфликты и находить компромиссы?», «Примеры добрых и злых поступков», «Как быть честным, даже когда это трудно?». Сценки, где дети примеряют роли («добрый волшебник», «честный продавец»), учатся решать конфликты, могут помочь в нравственном воспитании детей.

С целью развития эмоционального интеллекта, формирования навыков выражения добрых чувств, укрепления доверительных отношений между детьми, родителями и воспитателями проводится акция «Доброе письмо». Родители и дети пишут друг другу «письма» с добрыми словами и обмениваются ими в группе.

***5. Развитие критического мышления***

Марджани учил детей не просто запоминать информацию, но и думать, анализировать и делать собственные выводы. «Не верьте всему, что слышите. Думайте, спрашивайте, ищите истину», – высказывался просветитель.

Для развития критического мышления дошкольников используются вопросы-загадки:

«Почему снег тает в руке?», «Могут ли рыбы летать?», «Почему солнце светит днём, а луна ночью?», Может ли дерево быть домом?», «Почему звёзды мерцают?», «Может ли облако быть

тяжёлым?», «Почему вода мокрая?», «Почему листья меняют цвет осенью?», «Почему радуга разноцветная?», «Почему у кошек глаза светятся в темноте?», «Может ли вода быть твёрдой?», «Может ли снег быть тёплым?», «Почему у людей есть тени?». Дети учатся аргументировать ответы.

***6. Создание развивающей среды***

Шигабутдин Марджани воспитывал в детях любовь к своей культуре, языку и традициям, но при этом учил их уважать другие народы и культуры.

В группе детского сада оформляется уголок «Мудрые слова», где размещаются цитаты Марджани в адаптированной форме: «Знания – как свет: чем больше их, тем ярче жизнь», «Если хотите, чтобы дети стали лучше, станьте лучше сами», «Ошибки – это ступеньки на пути к знаниям. Не бойтесь ошибаться, бойтесь не учиться на своих ошибках», «Каждый ребёнок – это будущее. Вера в себя и трудолюбие помогут вам достичь любых высот». Выставка «Наши традиции»: куклы в национальных костюмах, предметы быта, детские рисунки по мотивам татарских сказок.

Педагогический опыт Шигабутдина Марджани можно интегрировать в современный детский сад через игру, диалог, творчество и уважение к личности ребёнка. Главное – сделать акцент на свободе выбора, связи с культурой и эмоциональном интеллекте. Эти методы не требуют сложного оборудования, но помогают воспитывать детей в духе гармонии, любознательности и уважения к своим корням.

## ТАТАР МӘГЪРИФӘТЧЕЛӘРЕНЕҢ БАЙ МИРАСЫ

**Вәлиева Гүзәлия Фатыйх кызы**
*Балтач районы Сосна төп гомуми белем мәктәбе*
*Туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучысы*

Татар халкының үзенә генә хас бай тарихлы педагогик карашлар системасы бар. Халкыбызның гомер-гомергә аң-белемгә, мәгърифәткә омтылып яшәве, укымышлы кешеләрне олылавы, укырга яратуы һәркемгә мәгълүм.

Һәр халыкның, шул исәптән татар халкының да иң изге максаты – һәрьяклап камил шәхес тәрбияләү. Тарихи үсеш дәвамында халыкның хәтер сандыгында шәхес тәрбияләү белән бәйле карашлары, фикерләре, ысуллары тупланып килгән, һәм бу рухи хәзинә, өзлексез камилләшә барып, буыннан-буынга тапшырылган.

Яшь буынны тәрбияләүдә татар мәгърифәтчеләре мирасы зур әһәмияткә ия. Яшүсмерләрдә кешелеклелек сыйфатлары формалаштыру – бик мөһим проблема. Халык педагогикасының да төп бурычы булып халыкны кешелеклелеккә, мәрхәмәтлелеккә өйрәтү тора.

Һәр халыкның тарихи мирасында күренекле шәхес, галим һәм фикер ияләренең иҗатлары, язган хезмәтләре зур урын алып тора. Безнең татар халкыбызның бай традицияле мәдәни һәм рухи мирасыбызда Шиһабетдин Мәрҗани, Ризаэддин Фәхреддин һәм Каюм Насыйрилар – кешене кеше һәм шәхес итеп тәрбияләүнең дөрес юлын күрсәтеп калдырган галимнәр.

Шиһабетдин Мәрҗани – яңа милли педагогикага нигез салучы. Аның педагогик карашлары бүгенге мөгалимнәрнең теоретик әзерлеген тирәнәйтергә, белемнәрен үстерергә, методик осталыкларын заман таләп иткәнчә алдынгы технологияләр ярдәмендә, тагын да яхшыртырга булыша. Үзенең бөтен тормышын мәгърифәтчелек фикерен таратуга, яшь буынга белем һәм тәрбия бирүгә, халыкның дөньяга карашын киңәйтүгә багышланган мәшһүр Шиһабетдин Мәрҗани татар иҗтимагый фикере, мәгърифәте һәм мәдәнияте тарихында тирән эз калдырды.

«Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» («Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр») – Мәрҗанинең иң танылган әсәре. «Мөстәфадел-әхбар…» китабын кыскача

татар тарихы дип атарга мөмкин. Анда татар халкының этник тарихы, мәгарифе, рухи мирасы, күренекле шәхесләре, мәчет-мәдрәсәләре хакында күп төрле мәгълүматлар бар.

Безнең Сосна авылында XVIII гасырда ук шактый абруйлы мәдрәсәләр булган. Аларның иң борынгысы – икенче җәмигъ мәчете каршындагысы. Сосна мәдрәсәләре турында Ризаэддин Фәхретдиннең «Асар», Шиһабетдин Мәрҗанинең «Мөстафәдел – әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» хезмәтләрендә хөрмәт белән искә алына.

Ризаэддин Фәхреддин үзенең «Гаилә», «Тәрбияле ана», «Тәрбияле бала», Каюм Насыйриның «Тәрбия» һәм «Әхлак рисаләсе» һәм башка бик күп китапларында бала тәрбияләү, гаилә ныклыгы һәм аның бәхетенә ирешү, үзеңне җәмгыятьтә тоту кагыйдәләрен, нәсыйхәтләрен үтемле, тормышчан итеп күрсәткән.

Р.Фәхреддиннең хезмәтләре – гасырлар дәвамында тупланган, халык тәҗрибәсенә нигезләнгән һәм югары әхлаклы шәхес тәрбияләүдә мөһим чыганак.

Галим, педагог, мәгърифәтче Риза Фәхреддиннең тәрбия юнәлешендәге тирән эчтәлекле хезмәтләре үз заманында халык арасында бик киң тарала. Бүгенге көндә дә бу хезмәтләр актуальлеген югалтмыйча, көннән-көн укыту-тәрбия процессында киңрәк кулланылыш таба. Дәресләрдә һәм сыйныфтан тыш чараларда галимебезнең бай мирасыннан гыйлем һәм тәрбия чарасы буларак уңышлы файдаланабыз.

Һәр төбәкнең, һәр авылның күренекле шәхесләре бар. Безнең Балтач яклары да элек-электән үзенең укымышлы галимнәре, мәшһүр шәхесләре белән данлана.

Райондашыбыз, Татарстанның баш казые, дини язучы, оста вәгазьче Җәлил хәзрәт Фазлыевны мин мәгърифәтчеләребезнең дәвамчысы, бүгенге көн мәгърифәтчесе дип атар идем. Аның дин, тәрбия, яшәеш турындагы тирән эчтәлекле нәсыйхәтләре һәркемнең күңеленә үтеп керә.

Бүгенге заман мәгърифәтчесе Җәлил хәзрәт Фазлыев, тырышлык һәм белемле булуның матур бер үрнәген күрсәтеп, районда гына түгел, республикабызда, бөтен татар галәмендә киң танылу алды.

Татар мәгърифәтчеләренең дәвамчысы буларак, Җәлил хәзрәт Фазлыев эшчәнлеге татар иҗтимагый фикер үсеше тарихында, этика-эстетика, әдәп-әхлак, дини-дөньяви фәннәр юнәлешендә мөһим роль уйный. Ул – дини һәм дөньяви эчтәлектәге әхлакый китаплар, мәктәп-гимназияләр өчен әхлак дәресләрен укыту программалары авторы. Тирән мәгънәле вәгазьләре белән һәркемнең күңелен нурландыра, гыйлем, мәгърифәт тарата.

Җәлил хәзрәт Фазлыевның тирән эчтәлекле нәсыйхәтләре – укытучыга белем һәм тәрбия өлкәсендә олы кинәшче. Аның иҗатын җентекләп өйрәнү – безнең мөһим бурычыбыз.

Районыбызның һәм мәгариф эшенең бай тарихын өйрәнүче тынгысыз җанлы мәгариф ветераны Мәгъсүм Абдулла улы Мөхәммәтҗановның да хезмәте олы мактауга лаек. Ул СССР Мәгариф министрлыгы, СССР Фәннәр Академиясенең Мактау таныклыгына ия була. 1987 елда мәгариф өлкәсендәге казанышлары һәм нәтиҗәле эшчәнлеге өчен РСФСРның «Халык мәгарифе отличнигы», «Балтачның мактаулы гражданины» күпсанлы мактау таныклыкларына, Рәхмәт хатларына лаек булган Мәгъсүм ага хәзерге көндә 7 китап авторы да: «Буразналардан сирпелгән җылылык» (МТС «Сельхозтехника» тарихы 2001–2008); «Ташны ярып үскән гөлләр» (балалар йорты тарихы, 2008); «Алгарыш ташкыны ак җилкәннәр» (мәгариф тарихы, 2008–2010); «Пионер эзләреннән үткәннәргә сәяхәт» (2010); «Әрәмәләр шавы» (Яңгул авылы тарихы, 2012); «Сорнай» (колхоз тарихы, 2014); «Ызаннарда безнең эзләр» (Балтач «Агрохимсервис» берләшмәсе тарихыннан, 2015).

Мәгъсүм Абдулла улы Мөхәммәтҗановның да хезмәтләрен тәрбия сәгатьләрендә, дәресләрдә даими кулланабыз.

«РСФСРның халык мәгарифе отличнигы», Татарстан Мәгариф министрлыгының «Мәгарифне үстерүдәге хезмәтләре өчен» билгеләре иясе, «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» исеменә лаек булган райондашыбыз Гарифҗан Мөхәммәтшин – Балтач төбәгенең күп гасырлык тарихына, аның үсешенә өлеш керткән, үзенең хезмәте һәм батырлыгы белән аны данлаган фидакарь җанлы кешеләр турында 2006 нчы елда «Балтач энциклопедия»сенең I китабы, Балтач

төбәге авыллары, аларда оешкан авыл Советлары, колхозлар, төрле елларда эшләгән мәктәп-мәдрәсәләр, гомумән – районыбыз, аның үткәне һәм бүгенгесе турында саллы мәгълүмат бирүче 2010 нчы елда «Балтач энциклопедия» сенең II китабы дөнья күрде. Ким дигәндә 350 еллык данлы, гыйбрәтле тарихы булган туган авылы Арбор авылы хакында «Урбар» китабы 2013 елда китап сөючеләргә барып иреште.

Тәрҗемә өлкәсендә дә актив эшли. Төрек һәм немец шагыйрьләрен татар теленә тәрҗемә итә. Г.Мөхәммәтшинның үткен публицистик язмалары еш басыла. Халык әсәрләрен җыю, барлау, укучыларга ирештерү буенча актив эшли. Район һәм туган авылы тарихын өйрәнү юләлешендә зур эш башкара.

Республика матбугатында үзенең тирән фикерле язмалары белән билгеле шәхес, тарихчы, зур хөрмәткә лаек ветеран укытучы Рәфхәт Шәкүр улы Зарипов, Россия һәм Татарстанның атказанган укытучысы, озак еллар Балтач районының Карадуган авылындагы «Себер юлы тарихы» музее директоры булган, туган төбәге тарихына багышланган «Себер юлы серләре», туган авылы тарихын яктырткан «Мәгърифәтле Таузар иле» исемле китаплар авторы Зиятдинов Бакый Шәймулла улының хезмәтләре дә эзсез югалмас.

Тарихи – мәдәни хәтерен барлаган һәм өйрәнгән, белгән һәм бәһаләгән халык кына мираслы була! Без – китаплы, белемле, бай мираслы халык. Мирасыбызны бөртекләп туплау, саклау һәм киләчәккә илтеп җиткерү безнең максат булуын һәрчак истә тотыйк. Әйе, «киләчәге бар милләт без, тарихларга, шәхесләргә бай милләт без!». Мондый шәхесләре, тарихлары булган халыкның киләчәге өметле.


**Кулланылган әдәбият һәм чыганаклар:**

1. Ә. Н. Хуҗиәхмәтов. «Мәгърифәт йолдызлыгы», Казан, «Мәгариф» нәшрияты, 2002;
2. Р. Ә. Шакирҗанов. «Мәшһүр татар галимнәре», Казан, ТКН, 2011;
3. Р. Ф. Бәдретдинов. «Төнге яктылык», Казан, «Ак бүре» нәшрияты, 2023.


## РИЗАЭДДИН ФӘХРЕДДИН МИРАСЫН УКЫТУ-ТӘРБИЯ ПРОЦЕССЫНДА ФАЙДАЛАНУ


**Каримова Фәния Илдус кызы**

*Казан шәһәре Яңа – Савин районының*
*«Инглиз теле тирәнтен өйрәнелә торган*
*9 нчы урта гомуми белем мәктәбе»*
*гомуми белем муниципаль*
*бюджет учреждениесе,*
*Туган тел һәм әдәбияты укытучысы*


Күренекле фикер иясе Ризаэддин Фәхреддин бар тормышын халыкка хезмәт итүгә багышлаган, гомере буена армый-талмый якты нур чәчеп яшәгән. Хезмәтләрендә ул кеше тәрбияләүне үзенең изге вазифасы итеп санаган, милләтне аң-белемле белән бергә, әдәп-әхлак ягыннан тәрбияләүгә дә зур көч куйган.

Мәгърифәтче, язучы, журналист буларак та, тәрбия өлкәсендәге хезмәтләре белән дә тел һәм әдәбият фәненә зур өлеш керткән бу олы шәхескә хөрмәтебез бик зур.

Ризаэддин Фәхреддин – әдип, тарихчы, дин һәм хокук белгече, мөфти, педагог, журналист, тюрколог, философ, археограф, тәрҗемәче, библиограф, архивчы, китапханәче һ.б.

Ризаэддин Фәхреддин шәхес тәрбияләүнең никадәр авыр, катлаулы һәм дәвамлы эш икәнлеген: «..Тәрбия – акрынлык вә тәртип белән камиллек булдыру димәктер…», – дип «Адабе тәгълим» китабында ассызыклап яза. Бу китабында тәрбия эшенең нечкәлекләренә һәм үзенчәлекләренә туктала.

Р.Фәхреддин яшь буынга үрнәк тәрбия, гүзәл холык, тирән белем бирергә алынган укытучы-мөгаллимнәрнең дә һөнәри осталыклары, камиллекләре ни дәрәҗәдә югары булырга, аларның гаять зур мәгълүматлы, җитди әзерлекле һәм ихлас, чиста күңелле кешеләр булырга тиешлегенә басым ясый. Автор бер китабының исеме астына: «Балаларыгызны үзегезнең заманыгыздан башка заман өчен укытыгыз, чөнки алар сезнең заманыгыздан башка бер заманда яшәү өчен дөньяга килгәннәр» (Аллаһының киң күңелле хөрмәтле кешесе – Гали хәлифә), – дигән хөрмәтле сүзләрен китергән.

Әхлак дәресләре өчен Ризаэддин Фәхреддин хезмәтләренә нигезләнеп төзелгән «Балаларга үгет-нәсыйхәт» китабын еш кулланабыз. Дәрескә әзерләнгәндә, бөек мәгърифәтченең гыйбрәтле сүзләрен, үтемле үгет-нәсихәтләрен мисал итеп алабыз. Әдипнең хезмәтләре укучыларны әхлак турында уйлауга этәрә, күркәм сыйфатларны үзләштерергә ярдәм итә. Дәресләрдә әдәби әсәрләрне өйрәнгәннән соң, гомуми нәтиҗә ясау өчен, Риза казый нәсыйхәтләреннән мисаллар китерәбез.

Ризаэддин Фәхреддиннең бөтен гомере Игелеккә, Белемгә, Яктылыкка, Иманга хезмәт итүгә багышланды. Р.Фәхреддин – чын мәгънәсендә олуг педагог. Чөнки аның бөтен эшчәнлеге игелеккә, толерантлыкка, халыкны белемле һәм тәрбияле итүгә юнәлдерелгән. Бу затның халык педагогикасына, яшәеш тәҗрибәсенә, ислам диненә, башка халыкларның рухи казанышларына нигезләнгән тәрбия китаплары («Тәрбияле бала», «Тәрбияле ана», «Тәрбияле ата», «Тәрбияле хатын») халкыбызны иманлы, әхлаклы итүдә инде гасыр буена дәреслек, тәрбия әсбабы вазыйфасын үтәп киләләр.

Бөек мәгърифәтчебез халык традицияләрен, мәдәниятен саклау һәм үстерүгә зур әһәмият бирә. «Һәр милләт кешесе үзенең үткәнен белсен һәм үз тарихы белән дус булсын, башка милләт кешесенең дә традицияләрен хөрмәт итсен» – ди. Мәктәбебездә тәрбияви чаралар халкыбызның гасырлар буена тупланган тормыш тәҗрибәсенә, зирәк акылына, тапкыр фикерләренә, үзенчәлекле тәрбия алымнарына һәм әхлак чараларына нигезләп алып барыла.

Татар халкының гореф-гадәтләрен, мәдәниятен, йолаларын саклап калу нияте белән сыйныфтан тыш чаралар үткәрелә. Сөмбелә, Нәүруз, Карга боткасы, Кече сабантуй бәйрәмнәрен балалар ел саен зур әзерлек белән каршы алалар.

Бүгенге укучыларыбыз мәшһүр галимебез Р.Фәхреддин күрергә теләгән бөтен яктан да үрнәк балалар булып җитешсеннәр һәм халкыбызга лаеклы булып, милләтебез горурланырлык, ул хыялланган зур шәхесләр булып үссеннәр иде, ә ата-аналар исә, үзләренең балаларына игътибарлырак һәм үзләре дә балаларына бөтен яктан үрнәк булсыннар иде.

## ИЖ – БУБЫЙ МӘГЪРИФӘТЧЕЛӘРЕ

**Ногманова Миләүшә Сәлим кызы**
*Әгерҗе шәһәре*
*МБГББУ 4 нче номерлы мәктәп*
*Туган тел һәм әдәбият укытучысы*

Татар дөньясы тарихында онытылмаслык исемнәр бар. Шундыйларның берсе – атаклы Бубыйлар нәселе. Бу атаклы нәселнең чылбыры кемнән башлана? Миңа шунысы билгеле: бу нәсел кешеләре Нигъмәтуллин фамилиясе белән йөртелә башлый.Татар иҗтимагый фикерендә тирән эз калдырган педагоглар, дин галимнәре, күп хезмәтләр һәм дәреслекләр авторлары– бертуган Гобәйдулла, Габдулла һәм Мөхлисә Бубый – Нигъмәтуллиннар тырышлыгы белән Иж– Бубый авылы IX гасыр ахыры – XX йөз башы татар мәгарифе һәм мәдәнияте үзәкләренең берсе булып әверелгән. XX гасыр башында халыкны аң-белемгә тартып, милләтебезнең зыялыларын үстереп, укыту-тәрбиянең куелышы һәм эчке тәртип ягыннан алдынгы саналган, бөтен Русиядә

дан-шөһрәт казанган берничә татар мәдрәсәсе исемлегенә Әгерже төбәгендәге Иж-Бубый мәдрәсәсе дә керә. Районыбызның, милләтебезнең горурлыгы булган Буби мәдрәсәсе XX гасыр башында бөтен Рәсәйдә танылa. Аның уку-укыту торышы ничек булган, XX гасыр башында нинди үзгәрешләр кичерә? Русиядәге мөселман хатын – кызлары өчен беренче уку йортларыннан булган татар мәдрәсәсенең эшчәнлеген өйрәнү, тирән фикерле, белемле, киң мәгълүматлы шәхесләр тәрбияләп чыгучы уку йортының чәчәк аткан вакытында ни өчен ябылуын ачыклау теләге мине эзләнү эшенә китерде.

**Фәнни эшемнең темасы** «Иж-Бубый мәгърифәтчеләре» дип атала.

**Эшемнең максаты:** Иж-Бубый авылының танылуына төп сәбәпче– татарның атаклы мәгърифәтчеләре Нигъмәтуллин– Бубиларның педагогик эшчәнлеген өйрәнү һәм аларның татар җәмгыятен үстерүдәге ролен ачыклау.

XX гасыр башында бертуган Бубилар нигез салган ирләр һәм кызлар мәдрәсәләре Русиядә дәрәҗәле уку йорты саналган. Габдулла Буби биредә алдынгы уку ысулларын кертүгә, урыс телен өйрәтүгә ирешкән.Аларның эшчәнлеге бүгенге көндә дә актуальлеген югалтмый Бубый данын кешелеккә танытуда галимнәр Ж.Вәлиди, А.Рөстәмева, А.Мәхмүтова, Р.Мәрданов, Р.Миңнуллин, Татарстан Үзәк архивы хәзмәткәре Сөләйман Рәхимов, Америка галиме Гайшә Азадә Рорлих, Иж-Бубый музеен оештыручы Рәмзия Хәлиуллина, авыл халкы, укытучылар коллективы күп көч куялар. Бубый мәдрәсәсенең данын еракларга тараткан төп сәбәп-биредә дин гыйлеме белән беррәттән, дөньяви фәннәр укытылу. Мәдрәсәнең ике уку бинасы, гомуми тулай торагы, бай китапханәсе, җиһазландырылган спорт мәйданчыгы булган. Кызлар мәдрәсәсе «Дәрелмөгаллимат», ирләрнеке «Дәрелмөгаллимин» дип йөртелгән. Бубый мәдрәсәсен тәмамлаучы һәркем « уытучы» таныклыгына ия булган. Мәдрәсәдә 15–20 төрле фән укытылган. Уку бай һәм ярлы балалары өчен берниндi түләүсез булган.Тәртипле уку йортында бары тик ике тапкыр дәрес өзгәннәр: бу – Лев Толстой һәм Габдулла Тукай үлгән көннәр. Мәдрәсәдә Н. Думави, З.Байчурина, Д.Гобәйди, Җ.Вәлиди кебек танылган шәхесләр укыган һәм укыткан. Әлеге белем бирү йорты бары тик бай татарлар, купецлар һәм сәнәгатьчеләрнең матди ярдәме белән генә эшләгән. Әгерже төбәге заманында гыйлем дөньясының зур мәгърифәт учагы булган Иж-Бубый мәдрәсәсе белән әле дә хаклы рәвештә горурлана.

## ТАТАР МӘГЪРИФӘТЧЕСЕ ФАТИХ КӘРИМИНЕҢ ОЛЫ МИРАСЫ

**Фатыхова Эльмира Расих кызы**
*Казан шәһәре Яңа Савин районы*
*«Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган*
*85 нче урта гомуми белем мәктәбе»*
*гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенең*
*Туган (татар) тел һәм әдәбият укытучысы*

2025 елда танылган мәгърифәтче, педагог, язучы, тәрҗемәче, журналист, «Вакыт», «Яңа вакыт» газеталарының баш мөхәррире Фатих Кәриминең (Гыйльман улы Кәримов) тууына 155 ел тула. Шул нисбәттән мәгърифәт йолдызы Фатих Кәриминең тормышын, иҗатын, педагогик эшчәнлеген, олы мирасын өйрәнү, аның яңа (җәдиди-фәнни) мәктәп челтәрләрен барлыкка китерү, бер эзгә салу, аларның эшчәнлеген оештыруга керткән зур өлеше белән танышу – **актуаль проблемаларның** берсе, дип саныйм.

Фәнни-эзләнү эшемнең төп **максаты** – XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы мәгърифәтчесе, педагог, язучы, тәрҗемәче, журналист, «Вакыт», «Яңа вакыт»газеталарының баш мөхәррире Фатих Кәриминең тормыш юлын, иҗатын, педагогик эшчәнлеген өйрәнү, олы мирасын пропагандалау.

Әлеге максатка ирешү өчен, түбәндәге **бурычлар** куелды:

1. Татар мәгърифәтчесе Фатих Кәриминең тормышын, иҗатын, педагогик эшчәнлеген өйрәнү.
2. Халкыбызның олуг шәхесе Фатих Кәриминең тормышын, иҗатын, педагогик эшчәнлеген яктырткан публицистик һәм фәнни-популяр әдәбият, архив материаллары белән танышу.
3. Танылган мәгърифәтче Фатих Кәрими турында фәнни, тарихи һәм Интернет-материаллар туплау.

Танылган мәгърифәтче, педагог, язучы, тәрҗемәче, журналист Фатих Кәрими (Фатих Гыйльман улы Кәримов) 1870 елның 30 (18) мартында Бөгелмә өязе Миңлебай авылында мулла-ахун гаиләсендә туган. Аның әтисе Гыйльман ахун Бөгелмә өязендә мәгариф эшен яңарту (җәдитләштерү) хәрәкәтен башлап йөрүчеләрдән булган. Башта атасында, аннан җиде ел Чистай мәдрәсәсендә укыган, гарәп, фарсы телләрен өйрәнгән. 1891 елдан Төркиянең Истанбул университетында белем алган. Шунда ул француз телен дә өйрәнгән. Төркиядә уку барышында мәгариф эшләрен оештыру, программа һәм укыту планнарын яңарту, яңа кулланмалар, дәреслекләр әзерләү эшләренең куелышы белән махсус рәвештә кызыксынган. Истанбулда укуын тәмамлагач, 1896 елда Фатих Кәрими Кырымга укытучы итеп чакыралган. 1899 елга кадәр Бакчасарайда яңа ысул («ысулы җәдит»), аваз методы («ысулы саутия») белән укырга-язарга өйрәтү методын гамәлгә ашыру өчен укытучыларны әзерләү курсларына җитәкчелек иткән, әдәбият һәм педагогика дәресләрен алып барган. Ул Гали бай Хөсәенов белән берлектә яңа (җәдиди-фәнни) мәктәп челтәрләрен барлыкка китерү, аны бер эзгә салу, аның эшчәнлеген оештыруга зур өлеш керткән. Үзенең әдәби иҗат эшчәнлеген дә яңа мәктәп өчен көрәшкә юнәлткән.

1900 елда, Оренбургка күчкәч, Кәримовлар, нәшрият эшен җәелдерү максатыннан, типография сатып алганнар һәм җәдит мәктәпләре өчен татарча дәреслекләр һәм китаплар бастырганнар. Шул ук чорда Фатих Кәрими Татар Каргалысы мәдрәсәсендә укытучыларны яңа ысул белән эшләргә әзерләү курслары оештырган һәм анда табигать белеме, физика, химия, география фәннәрен һәм методикаларын укыткан.

1901–1902 елларда Фатих Кәрими җәдитчә укыту өчен кулланма «Мөгаллим һәм мәрәбби. Раһнамә» («Укытучы һәм тәрбияче. Юл күрсәткеч») дигән ике кисәктән торган педагогик хезмәт бастырган. Революциягә кадәрге мәктәпләрдә ул төзегән «Мохтасар җәгърәфия» («Кыскача география»), «Мохтасар тарих гомуми» («Кыскача гомуми тарих»), «Мохтасар тарих ислам», «Тарих әнбия» («Пәйгамбәрләр тарихы») кебек дәреслекләр кулланылышта булган, география, тарих дәреслекләре кабат-кабат басылган.

Татар Каргалысында курслар ябылгач, Фатих Кәрими Оренбургта мәдәният, укыту, тәрбия эшләрен алып барган. Башта «Хөсәения» мәдрәсәсендә, ә аннары аның базасында ачылган Татар, Башкорт, Казах һәм Көнчыгыш халык мәгарифе институтларында татар, башкорт һәм казах мәктәпләренә мөгаллимнәр әзерләү курсларында укыткан, педагогия техникумында оештырылган кыска сроклы төрле курсларда эшләгән. 1925 елда Фатих Кәрими Мәскәүгә күчкән, СССР халыкларының Үзәк нәшриятында эшләгән һәм Н.Нариманов исемендәге Көнчыгыш университетында төрек теле укыткан. Гомумән, революциядән соң Фатих Кәрими үзен тулысынча укытучы эшенә багышлаган, төрле курсларда укыту эшеннән тукталмаган. Н.Агаев белән бергә экономик географиядән дәреслек язган. 1921–1924 елларда укытучылар институты өчен Европа географиясе, Россия географиясе, гомуми география, кыскача бөтендөнья тарихы, гомуми тарих һ.б. дәреслекләр, методик кулланмалар төзегән, тәрбия мәсьәләләренә караган «Әзһәр әхлак» («Чын әхлак»), «Мәктәпкәчә тәрбия», «Иҗтимагый тәрбия» һ.б. хезмәтләр язып бастырган.

Фатих Кәрими – XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы яңа әдәбиятыбызны зур мәйданга чыгаруда зур өлеш керткән шәхесләребезнең берсе. Ул үзенең әдәби иҗат эшчәнлеген яңа мәктәп өчен көрәшкә юнәлткән. «Җиһангир мәхдүмнең авыл мәдрәсәсендә укуы» («Торналы авылы мәктәбендә») (Петербург, 1898), «Бер шәкерт илә бер студент» (Казан, 1899) хикәяләрендә искечә уку-укытуның тормыш өчен яраксызлыгын күрсәтергә теләгән, татар яшьләренә йокыдын уянырга, яңа методлы рус мәктәпләрендә укучы студентлардан үрнәк алырга чакырган. «Салих

бабайның өйләнүе» (Оренбург, 1901), «Морза кызы Фатыйма» (Казан, 1907) әсәрләрендә автор, мәгърифәтчелек карашларыннан чыгып, саф мәхәббәткә дан җырлаган, шәхеснең дәрәҗәсе нәселдәнлек белән генә түгел, бәлки тырышлык һәм эшчәнлек, намуслылык һәм тәрбиялелек нәтиҗәсендә барлыкка килә, дигән идея үткәргән. Ә «Аурупа сәяхәтнамәсе» (Петербург, 1902), «Истанбул мәктүбләре» (Оренбург, 1913) әсәрләре сәяхәтнамә жанрында язылган.

1925 елда Фатих Кәриминең «Фатих Кәрими әсәрләре» дигән хикәяләр («Салих б191абайның өйләнүе», «Бер шәкерт илә бер студент», «Җиһангир мәхдүмнең авыл мәдрәсәсендә укуы», «Гаяш хәлфә») җыентыгы. Ул Польша язучысы Ф. Ф. Пуцековичның дөньядагы 30 халыкның тормышы һәм көнкүрешенә Казанда басылып чыккан багышланган берничә брошюрасын, 7 елдан соң В. И. Ленин, В. В. Бартольд хезмәтләрен тәрҗемә иткән.

1905 елгы революциядән соң, Фатих Кәрими үзен тулысынча журналистлык хезмәтенә багышлаган. «Вакыт»газетасының күп кенә прогрессив карашлы мәкаләләре, рус әдәбияты тарихы һәм башка халыкларның мәдәниятенә багышланган материаллар аның каләме белән язылган. 1917 елның 1 ноябреннән башлап Фатих Кәрими үз нәширлегендә «Яңа вакыт»газетасын чыгара башлаган. Ул үзенең газетасында, Совет властен яклап, аның хезмәт ияләренә бәхет алып килүен күрсәтеп мәкаләләр язып бастырган. Фатих Кәрими совет матбугатында озак еллар эшләгән. Ул Оренбургта чыккан «Эшчеләр дөньясы», «Юл», «Сабан» газеталарында үзенең мәкаләләрен бастырган.

Татар мәгърифәтчелегенең күренекле вәкиле булган Фатих Кәрими бөтен тормышын һәм талантын халыкка хезмәт итүгә багышлаган, татар халкының аң-белемен күтәрүдә, аны Европа культурасына якынайтуда тарихи әһәмиятле хезмәтләр башкарган. Фатих Кәриминең иҗаты һәм тормышына караган мәгълүматлар ТР Фәннәр Академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институты фондларында, ТР Милли архивында, Милли мәдәният музеенда саклана. Әлмәт районы Миңлебай авылында 1998 елдан «Әлмәт туган якны өйрәнү музее филиалы – Фатих Кәрими исемендәге мемориаль музей» эшли.

Әдипнең гомере фаҗигале тәмамланган. 1937 елның 4 августында аны Мәскәүдә кулга алганнар. Шул ук елның 27 сентябрендә СССР Югары судының хәрби коллегиясе Фатих Кәримине үлем җәзасына хөкем иткән.

## ТАТАР ХАТЫН-КЫЗЛАРЫ – МӘГЪРИФӘТ ЮЛЫНДА

**Хафизова Румия Абузаровна**
*МБОУ СОШ № 6 г.Бугульма*
*Учитель родного языка и литературы*

Максат: Ләбибә Хөсәениянең тормышы һәм педагогик эшчәнлеге белән таныштырырга

Максаттан чыгып, түбәндәге бурычлар куелды:

1) татар халкының мәгърифәтче хатын-кызлары турындагы белемнәрне киңәйтү;

2) Ләбибә Хөсәениянең тормышы турында тулырак мәгълүмат туплау;

3) Ләбибә Хөсәениянең татар хатын-кызлары тормышына керткән ролен ачыклау.

Татар мәгърифәтчеләре турында өйрәнү бүгенге көндә дә актуаль булып кала.

Эшемнең структурасына килгәндә, фәнни эзләнү эше керештән, ике бүлектән, йомгак, файдаланылган әдәбият исемлегеннән тора.

«Кереш» тә теманың бүгенге көндә актульлеге, эш алдында куелган максат һәм бурычлары, эшнең объекты һәм предметы ачылды.

Беренче бүлектә татар халкының мәшһүр татар хатын-кызлары күрсәтелде.

Икенче бүлектә Ләбибә Хөсәения һәм аның мәктәбе турында бирелде.

«Йомгаклау» да башкарылган эш буенча гомуми нәтиҗәләр ясалды.

«Кулланлган әдәбият исемлеге» ндә 9 чыганак күрсәтелде

Мәгърифәтебез таңында беренче яшь йолдызларыбызга нур биргән, үзләренең тырышлыклары, уңганлыклары белән мәктәпләр салдырып татар кызларыннан төрле белгечләр әзерләүгә нигез салган, гомумән, татар хатын-кызларын мәгърифәтле, мәдәниятле итүгә зур көч куйган беренчеләр рәтендә халкыбызның мөхтәрәмә ханымнар – Ләбибә Хөсәения һәм Фатиха Аитова.

Ләбибә Хөсәениянең тормыш һәм иҗат юлы белән кызыксыну мине фәнни-гамәли эшенә этәрде. Ул татар тарихында эз калдырган мәгърифәтчеләрнең берсе.

Ләбибә Хөсәения, Ләбибә Һади (Кади) кызы Хөсәения (Һадиева) (1880–1921) – Казан шәһәрендә 1904–1918 елларда эшләгән татар кызлары өчен мәктәпне ачучы һәм мөдәррисе.

1880 елның 7 декабрендә Казан губернасы Чистай өязе (хәзерге Норлат районы) Яңа Әмзә авылында туган. Әтисе Һади Шәмсетдин улы Бакиров, мәдрәсә тәмамлап, башта Яңа Әмзә авылында, соңыннан Казан артындагы (хәзерге Биектау районы) Чуаш Иле авылында мулла һәм мәдрәсәдә укытучы була. Л.Хөсәения башта әтисеннән, аннары бертуган абыйсы (булачак тарихчы) Мөнир Һадиевтан, Казанга күчкәч, Галимҗан Барудидан белем ала. Ләбибә үзе кебек яшь кызларга белем бирүне изге бурычы итеп санап үсә.

1896 елга кадәр Сембер губернасы Барыш районы Тирескә авылындагы миллионер Акчуриннарның йон юу фабрикасында эшче кызларны укыта. 1896 елда Мөхәммәдия мәдрәсәсе мөдәррисе Галимҗан Баруди (Галиев) чакыруы буенча Казанга килә. Г.Барудиның хатыны Маһруй Исхак кызы Галиевага өендә кыз балалар укытуда ярдәм итә башлый. Казанда беренче булып кызларны яңа ысул белән укыта башлаучы Маһруй абыстайдан җәдитчә укытырга өйрәнә. 1903 елда Маһруй ханым каты чирләгәч, кызлар мәктәбе эшен оештырып алып бару тулысынча диярлек Ләбибә кулына күчә.

Мәхәллә байларыннан үз өенең ишегалды түренә кызлар укыту өчен мәктәп салдырып бирүгә ирешә. Бу – Казанда кызлар укыту өчен махсус салынган беренче мәктәп була. 1904 елда Уфага барып,

*Татар теле* мөгаллимә исемен юллап, рөхсәт кәгазе алып кайта. 1910 елда үзенең педагогик әзерлеген тиешле документ белән рәсмиләштермәсә, киләсе уку елыннан мәктәбен ябу белән куркыталар. 1911 елның гыйнварында Уфага барып, Диния нәзарәтендә имтиханнан үтеп, 1911 елның 1 февралендә мөдәррислек шәһадәтнамәсен алып кайта. Мәктәпне бетергән кызлар «Мәктәптә укытырга хокуклы татар мөгаллимәсе» дигән таныклык алып чыга. Мәктәпне тәмамлаган кызлар Казан, Уфа губерналарында, Сарытау, Мәскәү, Тамбов, Екатеринбург, Пенза, Самар, Урта Азия (бигрәк тә хәзерге Үзбәкстан, Кыргызстан) җирлегендәге татар мәктәпләрендә мөгаллимә булып эшлиләр. Кече сыйныфларда дәрес бирүче кызларның белемнәрен күтәрү өчен, укытучылар әзерләү курслары оештыра, анда укыту өчен Мөхәммәдия мәдрәсәсеннән (яшертен) мөгаллимнәр чакырта. Л.Хөсәения мәктәбен бетергән кызлар Фатиха Аитова мәктәбендә укыта башлыйлар.

Ләбибә Хөсәения башлаган изге эш аның йөзләгән укучылары аша буыннан буынга, безнең көннәргә кадәр уңышлы тапшырылып килә.

## ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ УКУЧЫЛАРГА ӘХЛАК ТӘРБИЯСЕ БИРҮДӘ РИЗАЭДДН ФӘХРЕДДИН ХЕЗМӘТЛӘРЕНЕҢ РОЛЕ

**Хөсәенова Миләүшә Әмирҗан кызы**
*МБОУ «Школа № 31» г. Казани*
*Туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

Хезмәт юлымның **төп максаты** – балаларны төрле яктан үстерү, әдәби әсәрләр, әбибабаларыбызның гореф-гадәтләре аша әдәп-әхлак тәрбиясе бирү.

**Бурычлар**:

– халкыбызнын узенэ генэ хас, узенчэлекле педагогикасы– нэтижэле тэрбия чараларын тэрбия алымнарында кулланып эшлэүгэ ирешү;

– укучыларның телдән сөйләм күнекмәләрен ныгыту;
– аларда мөстәкыйль һәм иҗади фикер йөртү, чагыштыру, нәтиҗә ясау кебек күнекмәләрне формалаштыру;
– яхшылык эшләп яшәргә омтылыш тәрбияләү.

Балаларда һәрнәрсәгә мәхәббәт, акыл, намус, кешелеклелек, мәрхәмәтлелек кебек сыйфатлар тәрбияләүдә мәгърифәтчеләребез хезмәтләрен куллану уңай нәтиҗәләр бирә.

Бөек мәгърифәтчебез Ризаэддин бине Фәхреддин – үгет-нәсыйхәтләр бирү буенча гаять күп хезмәтләр калдырган шәхесләрнең берсе.

Татар теле һәм әдәбияты укытучысы буларак, мин Риза Фәхретдин мирасын балаларга җиткерүне үземнең бурычым дип саныйм. Чөнки тел һәм әдәбият дәресләрендә ата-анага ихтирам, мәхәббәт, хөрмәт күрсәтү, ата-ана хакын хаклау балаларның төп бурычы булып тору, игелеклелек, шәфкатьлелек, хезмәткә хөрмәт мәсьәләләре күтәрелә.

Ризаэддин Фәхреддиннең «Нәсыйхәт» китабы укучыларны әхлак турында уйлауга этәрә, күркәм сыйфатларны үзләштерергә ярдәм итә. Әдәби әсәрләрне өйрәнгәннән соң, гомуми нәтиҗә ясау өчен, Риза казый нәсыйхәтләреннән мисаллар китерәм.

Һәр әдәби образга тирән мәгънә салына. Һәрбер образның үзенә хас уңай яки тискәре сыйфатлары бар. Ә без үзебезнең алдыбызга тискәре сыйфатларга тәнкыйть күзлегеннән карый белүче, уңай сыйфатларга ия булган шәхес тәрбияләү бурычын куябыз.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә кирәк: дәресләрдә Р.Фәхреддин хезмәтләрен куллану киләчәк буынны шәхес итеп тәрбияләүдә отышлы чара үрнәге булып тора. Чөнки Р.Фәхреддин гомере буе тәрбия эшенә зур әһәмият бирә. «Тәрбия – акырынлык вә тәртип белән камиллек булдыру димәктер… Тәрбиясе булмаган җирдә гүзәл ашлык җитешмәгән кебек, тиешле тәрбия бирелмәгәндә гүзәл кеше дә җитешмәс. Шулай икән, тәрбия иң кирәкле бер эш булачактыр», – дип яза ул. Р.Фәхреддин мирасын укыту-тәрбия процессында куллану иң уңышлы юнәлешләрнең берсе булып тора.

Балаларда һәрнәрсәгә мәхәббәт, акыл, намус, кешелеклелек, мәрхәмәтлелек кебек сыйфатлар тәрбияләүдә мәгърифәтчеләребез хезмәтләрен куллану уңай нәтиҗәләр бирә.

Бөек мәърифәтчебез Ризаэддин бине Фәхреддин – үгет– нәсыйхәтләр бирү буенча гаять күп хезмәтләр калдырган шәхесләрнең берсе.

«Тәрбияле бала», «Тәрбияле ана», «Тәрбияле ата» «Гаилә», «Нәсыйхәт» кебек хезмәтләре сыйныф сәгатьләре, класстан тыш чаралар, әти-әниләр җыелышларында куллану өчен алыштыргысыз дәрәҗәдә бай материал булып торалар. Татар теле һәм әдәбияты укытучысы буларак, мин Риза Фәхретдин мирасын балаларга җиткерүне үземнең бурычым дип саныйм. Чөнки тел һәм әдәбият дәресләрендә ата-анага ихтирам, мәхәббәт, хөрмәт күрсәтү, ата-ана хакын хаклау балаларның төп бурычы булып тору, игелеклелек, шәфкатьлелек, хезмәткә хөрмәт мәсьәләләре күтәрелә. Укучыларга әхлак тәрбиясе бирүдә әдәбият дәресләренең роле әйтеп бетергесез зур. Чөнки әдәбият бөтен барлыгы белән тәрбия фәне, әдәби образлар аның төп нигезен тәшкил итә. Ризаэтдин Фәхретдин юкка гына: «Әхлак белән әдәбият бергә булырлар. Бер кавемнең әдәбияты нинди рәвештә булса, әхлагы да шул рәвештә булыр», – дип язмаган. Шушы сүзләргә таянып, мин, әдәбият һәм татар теле дәресләрендә әхлак тәрбиясенә караган мәсьәләләрне хәл иткәндә, Р.Фәхреддин хезмәтләреннән файдалану алымнарын ачыкларга телим.

Әдәбият дәресләрендә күп кулланыла торган чыганакларның берсе – «Җәвамигуль кәлим шәрхе». Бу хезмәттә пәйгамбәребезнең 344 хәдисенә Р.Фәхреддин тарафыннан зур һәм киң аңлатма бирелгән.

Бозык яшьләрдән бозык милләт туа. Әмма төзек вә фазыйләтле яшьләрдән төзек бер милләт хасил буладыр. Шуның өчен яхшы вә әхлаклы яшьләр җитештерергә кирәк. Болар олугларның хакларын да ригаять итә булырлар, милләтне дә тәрбия кылырлар (245 хәдис).

Бу хәдисләр аша Р.Фәхреддиннең бала тәрбияләүдә ата-аналар һәм укытучылар алдына зур бурычлар билгеләгәне күренә.

Ризаэддин Фәхреддиннең «Нәсыйхәт» китабы укучыларны әхлак турында уйлауга этәрә, күркәм сыйфатларны үзләштерергә ярдәм итә. Әдәби әсәрләрне өйрәнгәннән соң, гомуми нәтиҗә ясау өчен, Риза казый нәсыйхәтләреннән мисаллар китерәм.

Һәр әдәби образга тирән мәгънә салына. Һәрбер образның үзенә хас уңай яки тискәре сыйфатлары бар. Ә без үзебезнең алдыбызга тискәре сыйфатларга тәнкыйть күзлегеннән карый белүче, уңай сыйфатларга ия булган шәхес тәрбияләү бурычын куябыз.

Дәресләрдә Р.Фәхреддин хезмәтләрен куллану киләчәк буынны шәхес итеп тәрбияләүдә отышлы чара үрнәге булып тора. Чөнки Р. Фәхреддин гомере буе тәрбия эшенә зур әһәмият бирә. «Тәрбия – акырынлык вә тәртип белән камиллек булдыру димәктер…Тәрбиясе булмаган җирдә гүзәл ашлык җитешмәгән кебек, тиешле тәрбия бирелмәгәндә гүзәл кеше дә җитешмәс. Шулай икән, тәрбия иң кирәкле бер эш булачактыр», – дип яза ул [1:134]. Ә әдәбият дәресләре – әхлак тәрбиясе бирүдә иң әһәмиятле чара.

**Кулланылган әдәбият**


1. Гыймранова Д.Г., Гобәйдуллина Л. И., Миңнуллин Р. Х. «Ризаэддин Фәхреддин: Кәгазь өстендә калган исем – бетмәс гомердер». Казан. «Рухият» нәшрияты, 2014.
2. Ризаэддин Фәхреддин. «Җәвамигуль-кәлим» шәрехе. Казан. «Рухият» нәшрияты, 2005.
3. Ризаэддин Фәхреддин. «Балаларга үгет-нәсыйхәт». Казан, 2001.
4. Ризаэддин Фәхреддин. «Нәсыйхәт». Казан, 2004.
5. Татарның олуг улы. Мәгариф. 2009 нчы ел. 1 нче саны.


## ОСНОВЫ ВОСПИТАНИЯ ЛИЧНОСТИ И НРАВСТВЕННОСТИ В ТВОРЧЕСТВЕ РИЗАЭДДИНА ФАХРЕДДИНА


**Якупова Юлдуз Гамировна**
*МБОУ «Лицей № 188» Кировского района г. Казани*
*Учитель родного языка и литературы*


Мәгърифәтче педагоглар бай педагогик һәм методик мирас калдырганнар, ул әлегә җитәрлек өйрәнелмәгән һәм тулысынча киң җәмәгатьчелеккә таралмаган. Бу мирасның яшь буынга әхлакый тәрбия бирүдә нәтиҗәле ярдәм булып китүе өчен, аны шактый тикшерү, алга таба эшләү, анда тәкъдим ителгән идеяләрне гамәлдә куллану кирәк. Шуңа күрә үз вакыты өчен алдынгы карашлы, халыкны мәгърифәтләндерү эшенә зур өлеш кертkән татар мәгърифәтчеләре эшчәнлеген өйрәнү мөһим һәм актуаль бурыч булып тора.

Татар мәгърифәтчесе Ризаэддин Фәхреддиннең педагогик мирасы инде күпме еллар галимнәр тарафыннан өйрәнелеп килсә дә, аның тормыш юлы, эшчәнлеге белән кызыксыну тел галимнәре тарафыннан да, укытучылар тарафыннан да һаман арта гына бара.

Заманча укыту технологияләре артканнан арта барса да, алар белән бер рәттән туган тел укытучылары халыкның бай тәҗрибәсе тупланган халык педагогикасына, мәгърифәтчеләрнең хезмәтләренә еш мөрәҗәгать итә.

Галимнең хезмәтләре укучыларда халкыбызның буыннардан буыннарга күчеп килгән әхлакый сыйфатларын тәрбияләүгә юнәлдерелгән. Шул хезмәтләр аша укучыларны мөстәкыйль фикер йөртергә һәм нәтиҗә ясарга өйрәтү, миһербанлылык, игелеклелек, әйләнә-тирәгә игътибарлылык, инсафлылык кебек сыйфатлар тәрбияләргә омтылу зарур.

Бүгенге җәмгыятькә фәннәрне яхшы үзләштергән, иҗади фикерләүче һәм үз белемен мөстәкыйль рәвештә өзлексез күтәрә белүче кешеләр кирәк. Бу юнәлештә Риза Фәхреддиннең бүгенге милли мәгариф өчен дә әһәмиятен югалтмаган педагогик хезмәтләрен куллану бик дөрес булыр иде. Чөнки галимнен өйрәтүләре бүгенге заман таләпләренә дә аваздаш.

Мин бу эшемдә шушы заманча белем бирү учреждениеләре шартларында әчтәлекле һәм тәрбияви мәгълүматлы мирасны ничек куллану мөмкинлекләрен карап китәрмен. Эшемнең темасы: «Ризаэддин Фәхреддин иҗатында тәрбия-әхлак һәм шәхес тәрбияләү нигезләре».

Бүгенге көн эшчәнлегемнең төп максаты: зыялы, югары культуралы актив тормыш позициясенә ия укучы шәхесе тәрбияләү. Интеллектуаль, югары әхлакый ориентирга ия шәхес тәрбияләү максатыннан күп эш башкарылды. Нәтиҗәдә без бөек галимнең үткән юлы, иҗади хезмәтләре белән шактый таныш, ә аның тәрбия турындагы хезмәтләре безнең өчен юл күрсәткеч.

Балаларда туган (татар) телгә мәхәббәт уяту, рухи бай һәм физик яктан камил шәхес тәрбияләү, милли үзаң асылына төшендерү иң үзәктә торган мәсьәләләрдән санала. Моны гамәлгә ашыруда, без, укытучылар, күренекле фикер һәм гыйлем иясе, мәгърифәтче, әдип, журналист, җәмәгать эшлеклесе, тарихчы, галим, педагог Ризаэддин Фәхреддин хезмәтләренә таянып башкара алабыз, чөнки яшь буынны үз туган телендә сөйләшүче, халкын сөюче, аның тарихын өйрәнүче, иҗатка сәләтле буын итеп тәрбияләү эшен моннан башка күз алдына китерүе дә кыен. Бүгенге көндә укучыны тәрбияләү, баланы һәр яклап камил шәхес итеп үстерү – катлаулы һәм каршылыклы процесс. Ә шул баланы шәхес итеп тәрбияләүне нәрсәдән башларга соң?

«Алтыннан да бәһале, оҗмах җимешләреннән дә кадерле булган нәрсә – тәрбияле баладыр,» – дип яза Ризаэддин Фәхреддин. Әйе, балаларның яхшы холыклы, тәрбияле һәм тәртипле булып үсүләренең төп башлангычы – гаиләдә. Ата һәм ана – иң кадерле, иң изге кешеләр. Аларга карата мәрхәмәтле, игелекле, рәхмәтле булырга кирәклекне аңлатканда, без Ризаэддин Фәхреддиннең «Нәсыйхәт» китабының «Ата һәм ана» бүлегенә мөрәҗәгать итә алабыз. «Ата-аналарыгыз хозурында бик әдәпле булыгыз, аларның сүзләрен яхшы тыңлагыз, ишарәләрен аңлагыз, алар белән артык кычкырмыйча әдәпле итеп, ачык сөйләшегез. Кешенең итәгатьле булуы – күңеле яхшы булу галәмәтедер» – дип яза галим [2; б.22]. Бу сүзләр укучыларга тәэсир итмичә калмыйдыр, минемчә.

Язучы иҗат иткән һәр әдәби әсәрдә милләтне белемле, тәрбияле итү мәсьәләсе күтәрелә. Аның хезмәтләре укучыларыбыз күңелләрендә туган яклары белән горурлану, үткәне, чал тарихы белән кызыксыну хисләре уятырга ярдәм итәләр.

Ризаэддин Фәхреддин тәрбиягә кагылышлы 70 тән артык китап бастыра. «Балалар өчен», «Фәкать кыз балалар өчен», «Гаилә», «Нәсыйхәт – I», «Нәсыйхәт – II», «Нәсыйхәт – III», «Тәрбияле бала», «Тәрбияле ана», «Тәрбияле хатын», «Шәкертлек әдәбе», «Әдәбе – тәгълим» – турыдан-туры тәрбиягә караган хезмәтләре бербөтен тәрбия энциклопедиясен тәшкил итә.

Бөек мәгърифәтчебез халык традицияләрен, мәдәниятын саклау һәм үстерү, яңа буынга тапшыруга зур әһәмият биргән. Буыннан-буынга килгән әби-бабайларыбызның җәүһәрләре белән беррәттән, ул язып калдырган үгет– нәсыйхәтләрне истә тотсак, бер-берсенә үрелеп барган тәрбия чылбыры, һичшиксез, уңышлы нәтиҗәләргә китерер иде.

Мәктәпләрдә тел-әдәбият дәресләре укучыларны әдәп-әхлакка өйрәтү, матур әдәбият белән кызыксындыру кебек бурычларны куйса, Риза Фәхреддин әдәбиятны укучының әхлагын төзәтү коралы, фикер үсеше, тәрбия чарасы итеп бәяли.

Мин үзем рус төркемнәрендә укучы балалар белән эшлим. Рус мәктәпләренең туган тел һәм әдәби уку дәресләре программасында Р.Фәхреддин иҗатын өйрәнүгә сәгатьләр каралмаган. Шулай булуга карамастан, мәшһүр мәгърифәтчебезнең үгет-вәгазьләрен өйрәнүне Р. З. Хәйдарова дәреслегендә бирелгән тәрбияви характердагы шигырь һәм хикәяләр белән бәйләп алып барам.

Башлангыч сыйныфларда «Әдәпле сүзләр», «Кунакта», «Без йоклыйбыз» тексты буенча эш, тән әгъзаларының исемнәре, «Сәламәт бул», «Табын янында», «Шәхси гигиена», «Мин чисталык яратам», «Мин шәхси гигиена әйберләрен ничек кулланам?», «Акыллы малай», «Уңган кыз», И.Туктарның «Авыраяк», Дәрдмәнднең «Өч ул» хикәяләре буенча эшләү дәресләрендә Р.Фәхреддиннең үгет-нәсыйхәтләрен кулланам.

Бала кечкенә чактан ук өстәл артында үз-үзен тота белү кагыйдәләрен белеп үсәргә тиеш. 3 сыйныфта Бари Рәхмәтнең «Аш вакыты» шигырендә кул юу әдәбе, ашагач авызны чайкау,

ашаганда сөйләшергә ярамау кебек әдәпләргә өндәгән юллар бар. Хәләф Гардановның «Икмәк» хикәясендәге малай икмәк белән уйный, аны чәнечкегә эләктереп вертолет итеп әйләндерә һәм ахырында икмәкне идәнгә төшерә. 5 сыйныфта табын янында үзеңне тоту турында текстлар «Минем туган көнем» темасы астында берләштерелгәннәр: «Туган көн – күңелле бәйрәм», «Рөстәм», «Табын янында». Бу дәресләрдә Р.Фәхреддиннең «Тәрбияле бала» хезмәтеннән түбәндәге сүзләрне куллану урынлы: Баланың тәрбияле икәнлеге ашарга утырганда бик беленер. Тәрбияле бала зурлар күрсәткән урынга гына утырыр, бүлеп бирсәләр шуны ашар, кирәк булса, яхшы гына итеп сорар. Ашаганда һич ашыкмас, икмәк валчыкларын читкә төшермәс. Ашны ашъяулыгына вә үзенең киемнәренә түкмәс. Мондый балаларны һәркем яратып вә мактап сөйләрләр» [3, б.9].

Сәламәт яшәү рәвешенә «Йокы әдәпләре», «Ашау әдәпләре», «Эчү әдәпләре» кебек бүлекләр өйрәтә. «Көндәлек режим» белән бәйле темаларны өйрәнгәндә дә ярдәмгә Р.Фәхреддиннең хезмәтләре килә. Аның акыллы гыйбарәләре дәрестә әхлакый тәрбия бирүдә зур әһәмияткә ия.

3 сыйныфта Ш.Галиевнең «Онытылган…», М.Галләмованың «Чын иптәш», 8 сыйныфта, «Өлгерәм әле…» өзеген, Р.Вәлиеваның «Барый телевизор карый» шигырен укыгач, белем алырга теләмәгән ялкау балаларга үзебезнең киңәшләрне бирәбез. Р. Фәхреддинның «Җәвамигуль –кәлим шәрехе» китабында шундый юллар бар: «Гыйлем – ул дан күлмәге. Һәрбер фәнне үзләштер, надан булма».[5,126 б.] Бу җөмләләр әсәрдәге геройларга һәм укучыларга киңәш булып яңгырый. Шулай ук мәктәптә, дәрестә үз – үзеңне яхшы тоту өчен мәктәп әдәпләрен белү кирәк.»Мәктәп әдәпләре» хезмәтендә шундый нәсыйхәтләр бар: «Мәктәпкә баргач әдәпле генә үз урыныгызга утырыгыз, дәрес вакытында сөйләшмәгез, гыйлем өйрәнү өчен ихлас тырышыгыз, әдәп өйрәнегез, күркәм холыклы булуны олы бәхет дип белегез. Китап, кәгазь һәм башка язу әсбапларыгызны чиста тотыгыз, каләмегезне киемегезгә сөртмәгез».[3,22б.] Әлеге нәсыйхәтләрне 5 сыйныфта «Дәрестә» шигырен өйрәнгәндә дә кулланам.

Бүгенге көндә туганнар һәм күршеләр белән аралашу да кешеләргә җитеп бетми. Р. Фәхреддин бу кагыйдәләрне бик матур, аңлаешлы итеп язган. Ул мәктәптә мөгаллимнәр, мәктәптәге иптәшләр белән үз-үзеңне ничек итеп дөрес тотарга өйрәткән. Бу кагыйдәләр яңалык түгел, әмма һәркем тарафыннан үтәлергә тиешле язылмаган кануннар диясем килә. Шул нисбәттән, бу турыда еш кына сөйләшүләр алып бару, фикерләр уртаклашу да урынлы дип исәплим мин.

Эзләнеп, иҗади эшләгән укытучылар Р.Фәхреддин хезмәтләреннән үзләренә дәресләрдә куллану өчен күпме рухи азык ала алалар, чөнки галимнең өйрәтүләре бүгенге заман таләпләренә дә аваздаш. «Укытучының шундые булыр, алтын булачак бер шәкертне туфрак итеп җирдә калдырыр. Укытучының тагын шундые да булыр, туфрак булачак бер баланы алтын итә белер,» – ди галим. Укытучыдан күп нәрсә тора. Безнең кулларда балалар язмышы.

Әйе, бер гасырдан артык вакыт узуга карамастан, бөек шәхеснең мирас итеп калдырган хезмәтләре бүгенге көндә дә кулланышта.

Без бу бөек укытучы – тәрбияче, камил зат Ризаэддин Фәхреддиннең тәрбия дәресләрен буыннан – буынга дәвам итәргә тиешбез, киләчәк буыннар – безнең яшьләребез дә аның мирасын өйрәнсен, файдалансын, аның белән горурлансын иде.

# КҮРЕНЕКЛЕ ГАЛИМ ХӘСӘНГАТА ГАБӘШИҺӘМ АНЫҢ ПЕДАГОГИК ЭШЧӘНЛЕГЕ

**Гарифуллина Миләүшә Фәрит кызы**
*Биектау муниципаль районы Х.Габәши исемендәге*
*6 нчы номерлы Биектау урта гомуми*
*белем бирү мәктәбе*
*Милли эшләр буенча директор урынбасары*

Быелгы уку елында Биектауда яңа мәктәп ишекләрен ачты һәм бу белем бирү йортына күренекле галим Хәсәнгата Габәши исеме бирелде. Әлбәттә безнең өчен бу бик зур горурлык һәм җаваплылык. Мәктәбебезгә күренекле якташыбыз исеме бирелгәч. без. әлбәттә, аның биографиясен, эшчәнлеген, өйрәнә башладык.

Хәсәнгата Мөхәммәт улы Габәши – күренекле җәмәгать һәм дин эшлеклесе, тарихчы галим, педагог, җәдитчелек хәрәкәтенең мәшһүр вәкиле – Казан өязенең Кече Солабаш авылында (хәзерге Татарстан Республикасы Биектау районы) 1863 елның 11 гыйнварында указлы мулла гаиләсендә туа. Укырга-язарга өйрәнү, Коръән нигезләре һәм Көнчыгыш телләре буенча беренче дәресләрне заманасына күрә зур белемле саналган бабасы белән атасыннан ала. Бабасы Гобәйдулла бине Кәлимулла Габәш XIX йөз башында үк эпистоляр «Фатыйманәмә» поэмасы белән шөһрәт казана, атасы Мөхәммәт бине Гобәйдулла дини әдәбиятны яхшы белүче һәм татарча кулъязма китап күчереп язучы буларак танылa.

1875 елда Хәсәнгатаны атасы Казанга, Әҗем мәчете каршындагы схоластик карашлары белән мәгълүм Габделвәли Габделгафаров мәдрәсәсенә укырга җибәрә. Монда булачак галимнең, башта шәкерт сыйфатында, аннары мөгаллим буларак, унбиш ел гомере уза. Нәкъ менә шул елларда ул үзенең төп эшчәнлек даирәсен билгели: үзенең акыл һәм мәгърифәт көчен артталыкка, катып калганлыкка, искелек калдыкларына каршы көрәшкә багышларга карар кыла.

Халыкның мәдәни үсеше турындагы хыяллары, милләтнең үсеш юллары хакындагы уйланулары Х.Габәшине, татарларның гына түгел, бөтен төрки этнос тарихы буенча җитди тикшеренүләр алып баруга этәрә. Ул гарәп һәм фарсы чыганаклары белән күп эшли, Карамзин, Соловьев, Ключевский хезмәтләрен өйрәнә, К.Насыйри, В.Радлов, Н.Катанов кебек танылган замандашлары белән аралаша. Шулай да Габәшинең төп киңәшчесе, абруйлы остазы булып Ш. Мәрҗани кала. Аның фәнни хезмәтләре яшь галим өчен зур ачыш була.

1889 елда ул «Гаффария» мәдрәсәсеннән китә һәм бертуган Юнысовларның Мөселман балалар приютына дин сабагы мөгаллиме булып урнаша. Бу вакытта әлеге уку йортының мөдире булып алдынгы карашлы сәүдәгәр Мөхәммәтрәхим Исхак улы Юнысов тора, ул яшь мөгаллимгә нәтиҗәле эшләү өчен бөтен шартларны тудыра. Казанда беренчеләрдән буларак, Х. Габәши балаларны җәдитчә укыта башлый, ә ул чагында бу адым гаять авырдан бара, кырын караучылар да җитәрлек була. Кирәкле әдәбият җитешми, җәмгыятьнең иске карашлы даирәләре каршылык күрсәтә. Әмма Габәши югалып калмый, үзе үк ысулнамә әсбаплар, төрле фәннәр буенча кулланмалар яза һәм бастырып чыгара. 1889–1890 елларда ул биш китап: педагогика мәсьәләләренә һәм халык мәгарифен реформалауга багышланган «Тәрбияле бала», «Басыйрәт»; шәхси гигиена кагыйдәләре турында «Саглык» китапларын; үзенең бабасы Гобәйдулла Габәшнең «Хөласәтел бәян» дигән исем астында шигырьләр җыентыгын, шулай ук шәригать тарихы буенча «Ысул фикъһе тарихы» (1890) дигән, тикшеренүләрен бастырып чыгара. Әлеге язмалар галимнең иҗат биографиясендә мөһим урын билиләр. Шул рәвешле, Казан чоры эшчәнлеген Х.Габәши күренекле педагог-исламчы һәм талантлы галим

сыйфатында тәмамлый. Һәм аның инде исеме губернадан чит өлкәләрдә дә яхшы мәгълүм була. Тиздән аңа Казанны ташлап туган авылына кайтып китәргә туры килә. 1890 елда ул авыл мәхәлләсенең имам хатибы була, ә тагын бер елдан аның улы Солтанәхмәт (киләчәктә беренче татар композиторы) туа. Х. Габәши монда да фәнни эзләнүләрен дәвам итә – Казан арты авыллары тарихын өйрәнә, крестьян хуҗалыклары икътисады буенча мәгълүмат туплый һәм аларны берләштерә. Муллалык вазифаларын да менә дигән итеп башкара. Аны зирәк тирән әхлаклы, хезмәт сөючән кеше дип беләләр. Шуңа да 1894 елның 10 февралендә Х. Габәшинең мактаулы ахун дәрәҗәсенә күтәрелүе һәм 1895 елның 10 февралендә Ырынбур мөселманнарының Диния нәзарәте әгъзасы итеп сайлануы һәм казый итеп билгеләнүе табигый хәл. Бу үзе генә дә аны дәүләт дәрәҗәсендә тану булып тора. Өфедә дүрт ел яшәгәннән соң ул, туган авылында яңа җәдитчә мәктәп ачу нияте белән, Солабашка кайта һәм биредә күптәнге педагогик уй-хыялларын тулысынча тормышка ашырырга ниятли. Ырынбур миллионеры Әхмәт Хөсәеновның акчалата ярдәме белән Хәсәнгата хәзрәт зур һәм якты мәктәп бинасы төзи, анда эшләү өчен төпле мөгаллим яллый. Мулланың тырышлыгы бушка китми. Гадәти фәннәрдән тыш аның мәктәбендә укучыларга Шәрык халыклары тарихы, мәдәнияте, география, туган тел укытыла; сыйныф бүлмәләрендә күз явын алырлык парталар һәм кара такта белән акбур да була. Якын-тирә авыллардан шәкертләр агыла. Халык телендә бу мәктәпне «Солабаш университеты» дип тә атап йөртәләр.

1908 елда Х. Габәши янә Өфегә җыена. Ул тагын Диния нәзарәте әгъзасы итеп сайлана. Аның тормышында, ихтимал, иң мөһим дәвер – Хәсәнгата казыйны уянып килүче милләтне идея ягыннан рухландыручылар сафына чыгарган аның мәгърифәтчелек, фәнни һәм иҗтимагый эшчәнлегенең чынлап торып чәчәк ату чоры башлана.Тумыштан оештыру сәләтенә ия булып, ул аеруча кирәкле «кара» эшкә күп көч сарыф итә. Өфедә ярлы гаиләләрнең балалары өчен «Хезмәт сөю йорты» дигән һөнәрчелек мәктәбе ачуга ирешә, җирле төрмәләрдә утыручы тоткын мөселманнарга белем бирү тупланмасын җайга сала, хәйрия җәмгыятьләренең попечительләр шурасы әгъзасы булып тора, «Госмания», «Галия», мәдрәсәләренең идарә составына керә һәм аларда укыта. Ниһаять, Өфедә Х. Габәшинең дистәләрчә еллык тикшеренүләрнең җимеше булган фундаменталь хезмәте – «Мөфәссал тарих кауме төрки» («Төрки кабиләләрнең тәфсилле тарихы». 1909) дөнья күрә. Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, бу хезмәт тарихи темага галимнең беренче әсәре түгел. 1897 елда ук ул «Төрки ыруглары» дигән китап бастыра, ә 1899 елда «Мөхтәсар тарих кауме төрки» («Төрки кабиләләрнең кыскача тарихы») китабын чыгара, алар нигездә мәдрәсә мөгаллимнәренә һәм шәкертләренә багышлана.

Хакимияткә большевиклар килгәннән соң, Х. Габәши үзен тулысынча фәнни-педагогик эшчәнлеккә багышлый: Арча кантонының төрле мөгаллимлек курсларында укыта, тарихи тикшеренүләр белән шөгыльләнә.

Бүгенге көндә без укучылар белән бергә аның тормыш юлын өйрәнәбез. Киләчәктә аның турында күбрәк материаллар тупларга, аның хезмәтләрен тирәнтен өйрәнергә һәм мәктәбебездә аңа багышланган конференция оештырырга, музей булдырырга телибез.

## ГАЯЗ ИСХАКЫЙ – ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ МИЛЛИ КАҺАРМАНЫ

**Гаязова Фания Камильевна**
*ГБМБУ «117нче мәктәп»*
*Туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

Теләсә кайсы милләтне барыннан да элек аның күренекле кешеләре аша беләләр. Татар халкы да үзенең олы һәм катлаулы тарихында бөек шәхесләрне аз тудырмады. Хәзер язмамада шуларның берсенә – Г.Исхакыйның эшчәнлегенә тукталып китәм. Татар халкының бөек юлбашчысы, милләт атасы, сәясәтче, җәмәгать эшлеклесе, татар милли хәрәкәте җитәкчесе, язучы,

драматург, нәшир, мөхәррир, журналист, публицистң Мөхәммәтгаяз Исхакый 1878 елның 10 февралендә (иске стильдә) Казан губернасы, Чистай өязе, Яуширмә авылында мулла гаиләсендә дөньяга килә. Әтисе Гыйлаҗетдин хәзрәт тирә-юньдә танылган дин эшлеклесе, әнисе Камәрия абыстай шулай ук рухани гаиләдән чыккан, затлы нәселле ханым була. Гаяз 5 яшеннән үк укырга өйрәнә, әти-әнисе йортындагы татар, гарәп, фарсы китапларын укый. Башлангыч белемне туган авылы Яуширмәдә ала, ә инде 12 яшендә аны Чистай мәдрәсәсенә бирәләр. 3 ел укыганнан соң, 1893 елда Мөхәммәтгаяз әтисе рөхсәте белән мәдрәсәне ташлап китә һәм, Казанга килеп, «Күл буе» мәдрәсәсенә урнаша. Аны биредә күренекле мәгърифәтче Һади Максуди укыта. 1897 елда, мәдрәсәне тәмамлагач, аны Әмирхановлар мәдрәсәсенә хәлфә итеп чакыралар, ә Һ.Максуди монда мөдәррис булып күчә. 1898 елда Г.Исхакый Казан Татар укытучылар мәктәбенә укырга керә, аны 1902 елда тәмамлый. Бер үк вакытта Яңа Бистәдәге мөгаллимлек эшен дә дәвам иттерә. Татар укытучылар мәктәбе укучыларына балаларны рус мәдәнияты рухында тәрбияләргә, ягъни аларны руслаштырырга өйрәтә торган була, әмма Г.Исхакый милләтенә тугъры булып кала, ул 1902 елда Оренбургтагы «Хөсәения« мәдрәсәсендә эшли башлый. Ул мәдрәсәдәге шәкертләр тормышы-көнкүрешенә уку-укыту, тәрбия мәсьәләләренә дә бөтенләй башкача рух кертә, яңа фәннәр, яңа китаплар укыта. Г.Исхакый университетка керү теләге белән Казанга кайта, ләкин, ата-анасының сүзен тыңлап, туган авылында мулла булып хезмәт итәргә керешә. 1904 нче елда ул тагын Казанга килә, иҗтимагый-сәяси хәрәкәтләрдә катнаша башлый. Ул «Шәкертлек» җәмгыяте оештырып, «Тәрәкъкый» исемле кульъязма гәҗит чыгара, төрле якларга хатлар яздырып тарата, татар халкын йокыдан уяту эшендә актив катнаша.

Шул арада Г.Исхакый 1905 елның 29 октябрендә чыга башлаган «Казан мөхбире» нә эшкә чакырыла. Әмма Йосыф Акчура редакторлыгындагы бу гәзитнең юнәлеше аны бик үк канәгатьләндермәгәнлектән, ул үзе «Таң» исемендәге гәҗит чыгару эшенә керешә. Рөхсәт бирелмәгәч, «Хөррият» исемендә чыгарырга омтылыш ясый, Ахыр чиктә Гали Путиляков исеменә «Таң йолдызы» гәҗитенә рөхсәт ала. Фактик редакторы, рух бирүчесе – Гаяз Исхакый. Нибары биш ай гына яшәгән бу гәҗит битләрендә ул кискен политик чыгышлар ясый, патша хөкүмәтен төрле яклап фаш итә, азатлык проблемаларын күтәрә, халыклар дуслыгы идеяләрен пропагандалый. Татарлар кебек үк, рус халкының да изелеп яшәве турында сөйли. Бөтен халыкларның уртак дошманы булган самодержавиегә каршы бергәләп көрәшергә чакыра.

Г.Исхакый 1906 нчы елның 16–21 августында Бөтенроссия мөселманнарының Нижний Новгородта узган беренче съездында катнаша. Докладлар тыңлангач, ул берничә тапкыр сүз ала. Мондый җыелышлар үткәрү бары тик 1905 ел революциясе нәтиҗәсендә генә мөмкин булганлыгы, революция күп каннар түгелеп, зур югалтулар аша эшләнгәнлеге, азатлык өчен көрәш әле дәвам иткәнлеге турында сөйли.

Съездда Г.Исхакыйның торган юлы, кыйбласы бик ачык төсмерләнә. Бу эшне тагы да активлаштыра барып, ул төрле җыелышларда, митингларда яисә матбугатта патша самодержавиясен ачыктан-ачык фаш итәргә тотына.Турылыклыгы аркасында Г.Исхакыйга берничә төрмә капкаларын да күрергә туры килә. Шуңа да карамастан, ул революцион эшчәнлеген туктатмый. Карашлары буенча анархист булып, Казан татар революцион оешмасына кереп, хөкүмәткә каршы агитацияне татар мәдрәсәләрендә укучылар арасында алып бару белән генә чикләнмичә, Казан, Вятка, Пермь, Уфа, Самара, Оренбург губерналарындагы татар һәм рус крестьяннарын да агитацияли.

Г.Исхакыйның 1905–1907 еллар арасында сәясәт, журналистика, әдәбият өлкәсендәге эшчәнлеге үзара тыгыз бәйләнештә, бер-берсен тулыландырып бара. Ул гәҗитләрен көрәш трибунасы итеп файдалана. «Таң йолдызы» ябылгач, башлаган эшен шул ук татар эсерлары гәҗите «Тавыш» та дәвам иттерә.

1907 елның октябрь аенда аны яңадан кулга алалар, Архангельск губернасының Пинега шәһәренә сөргенгә җибәрәләр. Ләкин ул монда озак тормый, Төркиягә качып китә. 1909 елның көзендә яшертен генә Петербургка килә. Кышны башкалада, ә җәйне Финляндиядә үткәреп,

көз көне яңадан Төркиягә килә. 1911 елда ялган паспорт белән Петербургка кайта, ләкин аны тоталар һәм Архангельск губернасының Мезень шәһәренә җибәрәләр.

1913 елның 4 апрелендә азат итәләр, ләкин Казанга кайтырга рөхсәт булмый. Шулай да әдип Казанга, аннары туган авылына кайтып китә. 1913 елның 22 октябреннән Петербургта «Ил» гәҗитен чыгара башлый. Гәҗит революцион-демократик идеяләр учагы буларак мәйданга килә. Шул юнәлештә эшләп, ул бераздан Мәскәүгә күчерелә. Әмма озак та үтми, 1915 елның 27 мартында, сәяси яктан зарарлы дип, хөкүмәт тарафыннан туктатыла. Моннан соң «Ил» не Г.Исхакыйның фактик редакторлыгында шул ук Мәскәүдә башка кеше исеменнән чыгарылган «Сүз» һәм «Безнең ил» гәҗитләре алмаштыра. Болар да революцион-демократик рухлы гәҗитләр була.

1913 елдан соң Г.Исхакыйның тактикасы беркадәр үзгәрә. Ул элек сулдарак, сыйнфый көрәш позициясендә торып, ягъни җәмгыятьне байга, ярлыга бүлеп карап эш итсә, хәзер азатлыкка ирешү милләт эчендәге төрле катламнарның бердәм хәрәкәте нәтиҗәсендә тормышка ашарга тиеш дип саный. Гаяз Исхакый ике ел туктатылган «Ил» гәҗитен 1917 елда, беренче мөмкинчелек килеп чыгу белән, үз исеменнән яңадан чыгара башлый. Апрель аенда Мәскәү мөселман халкы комитеты рәисе итеп сайлана. Февраль революциясе булу белән ул татар халкының кая таба, ничек хәрәкәт итәргә тиешлеге турында бик җаваплы документлар әзерли, аларны бастырып та чыгара. Г.Исхакыйның милли-мәдәни автономия идеясе белән янып, төрки халыклар арасында аңлату-оештыру эшләре барган арада яңа революцион идеясе өлгерә. Нәтиҗәдә илдә Октябрь социалистик революциясе җиңеп, власть большевиклар кулына күчә, Совет власте урнаша. Татар милләте дип гомер буе җан аткан, эзәрлекләрдән башы чыкмаган фикер иясе, милли юлбашчы, эсер Г.Исхакыйга да җанын исән саклар өчен чит илгә китүдән башка чара калмый. Әмма Харбин, Берлин һәм Варшавада яшәгәндә дә ул «Милли юл» дип исемләнгән нәшрият булдырып, татар эмигрант язучыларын шул тирәгә туплый һәм «Милли юл», «Яңа милли юл», «Безнең байрак» дигән гәҗит-журналлар чагара. Ул мәкаләләрендә совет режимын тәнкыйтьли, татар милләтенең киләчәге өчен борчылуын белдерә, телне, милли мәдәниятне саклау проблемаларын күтәрә.

Г. Исхакый 1954 елның 22 июлендә Әнкарада вафат була. Истанбулның Әдернәкапы зыярәтенә күмелә.

Гаяз Исхакый – егерменче гасырның беренче яртысында татар, гомумән, төрки халыкларның киләчәге өчен эзлекле көрәш алып барган, шуны яшәвенең иң олы максаты итеп куйган милләт уларының иң күренеклесе**.**

## МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ – ГАЛИМ ҺӘМ ОЛУГ ОСТАЗ

**Зямилова Розалия Гарифяновна**
*Казан шәһәре ГБМБУ «71нче мәктәп»*
*Башлангыч сыйныф укытучысы*

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе академигы, тарих фәннәре докторы Миркасыйм Госманов – татар тарихын, мәдәниятен һәм әдәбиятын тирәнтен өйрәнгән сирәк галимнәребезнең берсе. Үзенең юлын дәвам итәрлек шәкертләр тәрбияләгән олуг остаз. Ярты гасырга якын фәнни-тикшеренү эшчәнлеге дәверендә чал тарихка нисбәтле төрле юнәлештәге 500 гә якын бәяләп бетергесез хезмәтләр калдырган профессор ул.

**Максат:** Миркасыйм Госмановның фәнни хезмәтенең үзенчәлеген өйрәнү

**Бурычлар:** – бүгенге көннең актуаль проблемалары белән чагыштыра белү күнекмәләре формалаштыру;

– милли үзаң, милли хисләр формалаштыру;

– укучыларда Миркасыйм Госмановның хезмәтен өйрәнүгә карата кызыксыну уяту.

**Теманың актуальлеге:** бүгенгесе катлаулы заманда татар тарихын белү, өйрәнү аеруча да бик кирәк

М.Госмановның гыйльми һәм әдәби иҗат эшчәнлеге күп өлкәләрне үз эченә ала. Төрки-татар тарихының борынгы чорларына караган җитди гыйльми тикшеренүләре һәм хезмәтләре белән үзен күренекле галим-тарихчы итеп танытткан М.Госманов мәдәният, әдәбият белеме һәм тарихы, әдәби тәнкыйть, матур әдәбият, публицистика, фольклористика өлкәләрендә дә иҗади эшчәнлеген дәвам иттерә. Шулай да әдип-галимнең иң яратып-бирелеп эшләгән өлкәсе – борынгы язма мирас. Халык арасында, аерым кешеләр кулында сакланып калган борынгы кульязмаларны, әдәби ядкәрләрне һәм фольклор текстларын эзләп табу, җыю, саклап калу һәм фәнни күзлектән өйрәнеп, әһәмиятлеләрен басмага әзерләү, дөньяга чыгару юнәлешендә ул өзлексез эш алып бара.

М.Госмановның иҗат эшчәнлегендәге тагын бер әһәмиятле тармак – татар әдәбиятының, гомумән, татар мәдәнияте һәм иҗтимагый фикер үсешенең үткәндәге тарихын эзлекле рәвештә өйрәнү.

Идел-Урал буе төрки халыкларының тарихы һәм мәдәниятенә караган XIII–XX йөз башы төрки язма чыганакларын өйрәнү – Миркасыйм Госмановның фәнни-тикшеренү өлкәсендәге төп юнәлеш. Татарстан һәм хәзерге Россия Федерациясенең төрле өлкәләренә сибелеп яшәүче татар халкы арасында татар, гарәп, фарсы телләрендә иҗат ителгән, күчерелгән язма ядкарьләрне җыю һәм тикшерү буенча оештырылган археографик экспедицияләр бу өлкәдә аерым урынны алып тора. 1963 елда Миркасыйм Госманов университетта археографик экспедиция оештыру идеясен күтәреп чыга. Моны, Казан шәркыят мәктәбенең гарәби кульязма ядкарьләрен җыю һәм өйрәнү өлкәсендәге элеккеге традицияләрен торгызу дип кабул итәргә кирәк.

Җыелган кульязмаларда VII гасырдан алып XX йөз уртасына кадәр вакыт эчендә иҗат ителгән әсәрләрнең текстлары теркәлгән. Жанр ягыннан караганда да алар гаять күптөрле. Ни генә юк алар арасында: мөселман юриспруденциясенә караган кульязмалар, ислам тарихы, астрономия, математика, география һәм фәннең башка тармакларына бәйле хезмәтләрнең күчерелмәләре, документаль чыганаклар, халык авыз иҗаты һәм матур әдәбият үрнәкләре.

Миркасыйм Госмановның «Каурый каләм эзеннән. Археограф язмалары» хезмәте галимнәр арасында гына түгел, киң җәмәгатьчелектә дә зур кызыксыну уятта. Балаларны, үсмерләрне тарих дигән кызыклы дөньяга җәлеп итүдә, фәнне популярлаштыруда җиңел тел белән катлаулы материалны бәян иткән әлеге хезмәтнең әһәмияте әйтеп бетергесез.

Галим туган телдә тарихка караган фәнни-популяр мәкаләләр һәм китаплар бастырып, әһәмиятле эш башкарып, яшь укучыларга үз халкының үткәне һәм мәдәнияте хакында бәян итә. «Серле балбал», «Таулар, үзәннәр иленә сәяхәт» китаплары – шундыйлардан. Әлеге ике китап 1984 елда бер томда басылып чыккан.

Россиянең төрле архивларында, фәнни китапханәләрендә ифрат зур тырышлык күрсәтеп, төрки халыклар тарихы һәм әдәбиятына караган документларны фәнни әйләнешкә кертүдә дә галим зур эш башкара. Идел – Урал буе төрки халыклары тарихы чыганакчылыгына багышланган «XVII–XVIII йөз татар тарихи чыганаклары» һәм «Җучи Олысының ярлыкаш актлары» исемле фундаменталь хезмәтләре дөнья күрә. Тикшеренүләрнең бай чыганакларга таянуы һәм аларны өйрәнү нигезендә ясалган нәтиҗәләрнең ышанычлылыгы Казан, Мәскәү, Баку, Тбилиси, Будапешт, Анкара һәм башка шәһәрләрдә басылган рецензияләрдә, ягъни халыкара фәнни җәмәгатьчелектә уңай яңгыраш таба.

Археографик экспедицияләрдә, архив һәм китапханәләрдә табылган кульязмалар, шулай ук 1917 елга кадәр дөнья күргән басмалар нигезендә Миркасыйм Госманов тарафыннан XIX йөз татар әдәбияты классиклары Габделҗаббар Кандалый, Мифтахетдин Акмуллаларның әдәби мираслары тикшерелеп, төп оригиналдагыча бастырып чыгарыла. Әлеге хезмәтләр әдәбият тарихында зур әһәмияткә ия дип исәпләнә.

КДУ проректоры булып эшләгән елларында студентларга гарәп язуы, соңрак шәрык телләре укытыла башлау да, киң катлам татар тарихын өйрәнердәй белгечләр үстерү максатын күздә

тотып алып барыла. Казан университетында Миркасыйм Госманов язма чыганакларны җыю, өйрәнү һәм бастыру өчен фәнни-тикшеренү археография лабораториясен, 1989 елда ачылган Татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләре факультетында тарих-филология кафедрасын, экология факультетларын оештыруда якыннан торып катнаша. Ул Казан университетында шәрык телләре бүлекчәләрен торгызуга зур өлеш кертә. Аның катнашында Казан университеты һәм чит ил (Венгрия, ГФР, Кытай, Төркия) университетлары арасында элемтәләр урнаштырыла.

Хәзерге вакытта татар халкының күпгасырлык тарихын өйрәнү Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе академигы Миркасыйм Габделәхәт улы Госманов исеме белән аерылгысыз бәйләнгән. 45 еллык фәнни-тикшеренү эшчәнлеге дәверендә аның тарафыннан чыганаклар базасын баету белән беррәттән, XIII гасырдан алып XX гасыр башына кадәрге киң тарихи чорда халык тарихына, әдәбият белеменә һәм татар мәдәниятенең тарихи мәсьәләләренә багышланган күп кенә хезмәтләр иҗат ителгән.

## МӘШҺҮР ПЕДАГОГ

**Мифтахова Гөлсинә Гомәр кызы**
*Нурлат шәһәре, 4нче урта гомуми белем мәктәбе*
*Туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

Бөек, мәшһүр галимебез К.Насыйридан соң татар теленең сафлыгы өчен көрәшүче, аның әдәби һәм фән теле була алуын исбат итүче, татар телен гамәли һәм гыйльми эшкәртү юлында кыю, зур эшчәнлек күрсәтүче, шулай ук татарларга рус телен балаларның ана телләре белән чагыштырып укытуны яклаучы, аны гамәлгә кертеп җибәрүче педагогларыбыз арасында Мөхетдин Хафизетдин улы Корбангалиев аерым урын били.

М. Корбангалиев татар теленең әдәби һәм фән теле була алуын, аның башка телләрдән артта булуын фәкать тиешле дәрәҗәдә өйрәнелмәгәнлектән генә икәнлеген исбат итә. Ул татар телен эшкәртү һәм бөтен халыкка аңлаешлы тел итү юлында татар телен бозучыларга каршы көрәштә күп көч куя. Балаларга ана телен һәм рус телен укытуны яклап чыга һәм шуны үзе эшләгән мәктәпләрдә гамәлгә кертеп җибәрә. Ул бу эшләрне, практик укыту процессында сынап, бер телне икенче тел белән чагыштыру методын куллану аркылы алып бара.

Мәшһүр педагог уку-укыту өлкәсендә яңа методларны алга сөрә, грамматикага һәм аны укытуга зур урын бирә. Ул укучыларның сүзлек запасын арттыруга аерым игътибарын юнәлтә һәм бу юнәлештә эшләү юлларын да күрсәтә; татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләр төзү эшенең әһәмияте зур, һәм алар бүгенге көндә дә үзләренең актуальлекләрен саклыйлар дияргә мөмкин. Шуңа күрә фәнни-тикшеренү эшемне бөек педагог эшчәнлеген өйрәнүгә багышладым.

Хезмәтемнең темасы: «Мәшһүр педагог».

Максаты: М.Корбангалиевның тел белеме һәм методика өлкәсендәге эшчәнлеген тикшерү.

Бурычлар:

– М.Корбангалиевнең педагогик эшчәнлеген тикшерү;
– М.Корбангалиевнең методик системасына анализ ясау.

Тикшеренү обекты – М.Корбангалиевның эшчәнлеге.

Тикшеренү предметы – М.Корбангалиевның тел белеме һәм методика өлкәсендәге хезмәтләре.

Эш барышында кулланылган методлар: эзләнү, күзәтү.

Эшнең структурасы: фәнни эшем кереш, бүлек, йомгаклау, әдәбият исемлегеннән тора.

Татар методистлары арасында аерым урын алып торган профессор М.Корбангалиевның күп еллык педагогик һәм методик хезмәтләре тикшерелмичә, өйрәнелмичә, аларга бәя бирелмичә, архивта гына ятуы зур кимчелек иде. Шушы кимчелекне бетерү максатыннан Казан дәүләт

педагогия институтының татар теле белеме кафедрасы доценты Ф. С. Валеева үз алдына М.Корбанагалиевның методика өлкәсендәге эшчәнлеген өйрәнү максаты куя. Шушы юнәлештә кандидатлык диссертациясе яклый һәм, ниһаять, 2004 нче елда «Халкына багышланган гомер» дип аталган хезмәтен бастырып чыгара. Бу хезмәттәге кайбер фикерләрне үз эшемдә мин дә файдаландым.

М.Корбангалиев үзенең хезмәтен башлангыч мәктәпләрдә ана теле һәм рус теле укыту белән башлап җибәрә. Соңга таба бу эшне урта һәм югары мәктәпләрдә дә дәвам иттерә. Шулай ук укый-яза белмәүчелекне бетерү өлкәсендә дә, ягъни зурларны укыту өлкәсендә дә, күп кенә көч куя. Шулар белән бергә, татар булмаганнарга татар теле укыту буенча да күп эш алып бара.

Укырга-язарга өйрәтү буенча М.Корбангалиев үз гомерендә өч төрле метод белән эш иткән: аваз методы, бөтен сүзләр методы һәм аналитик-синтетик аваз методы.

М.Корбангалиев, башлангыч мәктәпләр дә укырга-язарга өйрәтү методикасы өстендә эшләү белән бергә, шул ук мәктәпләрдә грамматика укытуны ничек алып бару юлларын да күрсәткән. Ул грамматика дәресләрендә грамматик тикшеренүләр ясарга кирәклекне алга сөрә. Грамматик тикшеренүләрне ул телдән дә һәм язма рәвештә дә алып барырга тәкъдим итә; дәресләрдә ул сызма тикшеренүләрнең төрле үрнәкләрен һәм төрле схемаларын да бирә.

М.Корбангалиевның дөрес язарга өйрәтү турындагы карашларына да игътибар итәргә кирәк. Бу өлкәдә дә үз вакыты өчен яхшы ук төрле фикерләр әйтә. Рус методистларыннан К. Д. Ушинский һәм Н. Кульманнар алганча, М.Корбангалиев та диктантны, күчереп язуны һәм ятлаганны күчереп язуны дөрес язарга өйрәтү чаралары итеп ала.

Педагог уку дәресләрендә аңлап укуга игътибар итәргә кирәклекне аеруча басым астына алып күрсәтә; моның өчен укыла торган материалны элек ана телендә аңлатырга, яңа сүзләргә аңлатма бирергә; ул сүзләрне укучылар дөрес әйтә алуга ирешкәч кенә аерым-аерым укытырга куша һәм укучыларның үзләренә эчтән укырга мөмкинлек бирергә кирәклекне әйтә.

Башлангыч, урта һәм югары мәктәпләрдә укуны татар булмаганнарга татар телен укыту, укырга-язарга өйрәтү, аларның татарча сөйләм телен үстерү һәм аларга грамматик белем бирү эшләрен ул югарыда күрсәтелгән алымнар белән алып барган һәм шулай алып барырга кирәклекне яклаган.

Мәшһүр педагогның эшчәнлеген тикшереп, аның метод һәм алымнар хәзер дә файдалы, кулланырга һәм үрнәк алырга яраклы булып торуына инандым. «Укытучы укучыларның тел өстендә күзәтүләрен, тәҗрибәләрен билгеле бер нәтиҗә ясый алуларына юнәлдерелергә тиеш. Шуннан инде укучы тиешле кагыйдә чыгара алуга кадәр барып җитәргә, аны кабатларга һәм үзләштерергә тиеш. Укытучы әзер кагыйдәне генә укучыларга тәкъдим итеп, ятлатудан ерак торырга тиеш». М.Корбангалиевның шушы кагыйдәләре хәзерге проблемалы укытуның нигезе булып тора бит. Ана телен башка фәннәр белән бергә бәйләп алып барырга кирәклеген ассызыклап, предмет ара бәйләнеш барлыкка китерә.

Чыннан да, М.Корбангалиев – гомерен татар халкы өчен багышлаган мәшһүр педагог. Ул халык өчен туган телнең зур әһәмияткә ия булуын һәм мәктәптә аның укыту теле булырга тиешлеген исбатлый.

**Кулланылган әдәбият**


1. Вәлиева Ф.С., Саттаров Г. Ф. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы.– Казан, «Раннур», 2000. – 455 бит.
2. Вәлиева Ф.С. «Халкына багышланган гомер». – Казан. «Мәгариф». – 2004. – 144 бит.
3. Вәлиева Ф.С. М. Х. Корбангалиевның татарларга һәм татар булмаганнарга татар телен укыту буенча методик системасы.– Казан, 1951.-286 бит.

# ЯШЬНӘП УЗГАН ГОМЕР

**Рамазанова Гөлсинә Габделбәр кызы**
*Балтач муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе Түнтәр урта гомуми белем мәктәбенең беренче квалификацион категорияле химия, биология укытучысы*

«Яшьнәп узган гомер» дип аталган фәнни тикшерү эше районыбыз тарихында тирән эз калдырган, 50 ел мәктәптә укытучы булып эшләгән, авылыбыз тарихын туплаган якташыбыз Зарипов Рәфхәт Шәкүр улы турында. Әлеге фәнни эшебез бай эчтәлекле, тарихи, кызыклы булуы белән аерылып тора.

Бик күпләрнең остазы булган Рәфхәт абыйның гадәти булмаган эш алымнарын пропагандалау әһәмиятле. Ул бервакытта да югарыдан кушылганны гына башкаручы, гадәти укытучы бурычын үтәү белән генә канәгатьләнүче булмады, ни дә булса уйлап табарга, яңалык кертергә, үзенчәлекле эшләргә омтылды. Шуңа күрә бу тема бик актуаль.

Эшемнең бурычлары: Зарипов Рәфхәт Шәкүр улының тормыш юлы белән танышу, өлкән мөгаллимнең эшчәнлеге турында башкаларга да җиткерү, авыл тарихына кызыксыну тәрбияләү.

Эш барышында Зариповлар гаиләсе турында мәгълүматлар, язмалар, истәлекләр, фотосүрәтләр, шәҗәрәләр өйрәнелде. Гаилә альбомнары белән таныштым. Безнен язма үз төбәге тарихын өйрәнүчеләр, укучылар, авыл кешеләре өчен кызыклы мәгълүмат чыганагы.

Рәфхәт Шәкүрович Балтач районының Мактаулы гражданы, РСФСРның Мәгариф отличнигы, «ТР Мәгарифтәге казанышлары өчен» билгесе, «Хезмәт ветераны» исеме һәм медалена лаек булган, мәктәп директоры һәм аның урынбасары булып эшләгән, берничә буын баласына белем биргән, сәләтле балалар белән эшләүгә зур көч сарыф иткән тәҗрибәле укытучы, остаз. Озак еллар пропагандист, лектор, агитатор, журналист, фотограф буларак авыл халкына хезмәт күрсәтте. Ул авыл тарихын өйрәнү буенча 40 ел дәвамында мәгълүмат җыйды, архивлардан материаллар туплады. Авылдашларына күптөрле шәҗәрәләр эшләде, китаплар һәм брошюралар иҗат итте. «Тирән тамырлы Түнтәрем», «Җиде бабаңны беләсеңме?», «Аллаһка якынаю юлында», «Түнтәр авылының мәчет-мәдрәсәләре тарихы», «Тарих һәм чынбарлык», «Хәтер сандыгы» «Бакыйлыкка күчкән әби-бабаларыбыз рухына БЕР ДОГА» дигән китаплар бастырып чыгарды. Алар китапханәләрдә, авыл халкында саклана, интернетка да куелган. Шәхси сайтларда соңгы 50 елдагы тормышны яктырткан бер меңнән артык, «ВКонтакте» битендә ике меңнән артык фото саклана.

Без ул бастырып чыгарган китаплар аша авыл тарихын, татар халкы язмышын, 200 еллык мәдрәсә һәм мәктәп тарихын өйрәндек, анализладык, киләчәктә дә өйрәнүне дәвам итәрбез. Туган авылым Түнтәр – Балтач районында урнашкан, элек электән мәчет мәдрәсәләре белән дан тоткан, татар милләтенә дистәләгән күренекле шәхесләр биргән, Идел Урал төбәгенә мәдәният һәм мәгърифәт нуры тараткан борынгы авыл. Түнтәр мәдрәсәсе 18–19 гасырларда Казан артындагы иң борынгы, иң данлы мөселман уку йортларының берсе булган. Борынгы мәдрәсәнен берничә корылмасы бүгенгә кадәр сакланган. Шул мәдрәсәләр янәшәсендә бүгенге көндә авылда кызлар пансионаты төзелеше башланды. Пансионат төзелеше республикакүләм зур әһәмияткә ия, биредә киләчәктә республиканың төрле районнарыннан укырга теләк белдергән яшь кыз балалар өчен ислам дине нигезләре өйрәтеләчәк. Тамырлары Түнтәр җиренә тоташкан, районда, республикада игелекле хәйрия эшләре белән танылган меценат Шамил Зарифов, авылда туып үскән алдынгы карашлы «Елмай» сөт-май комбинаты җитәкчесе Рәис Шәйхетдинов башлангыч чыгымнарны үз өсләренә алды. Төзелешкә район җитәкчелеге, дин

әһелләре фатихаларын бирде. Бу эшләргә башлангыч бирүче кеше туган авылы Түнтәрдә гомер кичерүче 83 яшьлек зыялы остасыбыз Зарипов Рәфхәт Шәкүр улы. Авылыбызның үткәнен барлаучы, бүгенгесе өчен янып көеп яшәүче, киләчәгенә зур өметләр багълаучы тынгы белмәс авылдаш – безнең горурлык.

## ҮТКӘННЕҢ ОНЫТЫЛМАС БИТЛӘРЕ

**Рахимова Альфия Валиахметовна**
*МБОУ «Татарская гимназия № 15»*
*Кировского района г. Казани*
*Учитель начальных классов*

*Бөек татар халкын, бай тарихын,*
*Гасырлардан килгән мирасын,*
*Калдырасы иде яшь буынга,*
*Һәрбер кеше барлап соклансын!*

Әлеге эш бүгенге көндә бик актуаль, чөнки үз тарихын белмәгән халыкның киләчәге юк. Моның өчен һәр бала үз гаиләсенең, туган җиренең тарихын белергә, шуның аша халыкка якынаерга тиеш. Һәр милләт үз җирлегендә барлыкка килгән һәм буыннан-буынга күчә торган гореф-гадәтләрен, кешеләрен, яшәү рәвешләрен белергә тиеш.

Туган җир… Туган авыл…Туган ягыбызның һәр сукмагы, һәр агачы һәм аның кешеләре күңелгә ифрат та якын. Шушында безнең нигезебез, тамырларыбыз һәм үткән тарихыбыз.

Туган авылыбыз Айдәргә кайчан нигез салынуы анык кына билгеле түгел. Моның буенча тарихи мәгълүматлар сакланмаган. Буыннан-буынга сөйләнә торган риваятьләргә нигезләнеп, авылыбыз бик борынгы тарихлы дип әйтергә нигез бар. Халыкны көчләп чукындыру, мәчет-мәдрәсәләрне тузгыту, алар урынына ашыгып чиркәүләр, монастырьлар салу киң җәелә. Урыслар тарафыннан көчләп чукындырылудан куркып, куе урманнар белән капланган мул сулы чишмә янына («Поварна» чишмәсе) бер кеше килеп төпләнә. Аның исеме Айдархан була. Шуннан авыл «Айдәр иле» дип атала. Бүгенге буын авылның исемен кыскартып «Айдәр» дип йөртә башлый. (Көчләп чукындырылудан качып Тәмте һәм Колбагыш авылларының хәллерәк гаиләләре Айдар авылына килеп урнаша.

Рәүф Әхмәт улы Сабиров 1894 елда Мамадыш өязенең Айдар (хәзер Теләче районы) авылында дөньяга килә. Үз авыл мәктәбендә бераз белем алгач, күрше Сатыш авылында мәдрәсәдә укый. Бераз акча юнәтү исәбе белән ул әти-әнисен калдырып, Түбән Новгород шәһәренә чыгып китә, анда бераз кара эшләрдә эшләгәннән соң, Екатеринослав шәһәрендә тоз бораулаучысы булып эшли. Озакламый Беренче Бөтендөнья сугышы башлана һәм аны солдатка алалар, ә 1915 елның башында Герман фронтына озаталар. Өч ел эчендә сугышның бар авырлыгын кичергән, салкын окопларда ятып, күп кенә иптәшләрен югалткан, гаделсезлекләрне күреп дөньяга «күзе ачыла» башлаган егетне 1918 ел башында, 170 нче пехота дивизиясе делегаты итеп, Казанга съездга җибәрәләр. Большевиклар партиясе әгъзасы булып тормаса да, Рәүф Сабиров тулысынча алар позициясен яклап чыга һәм большевиклар белән бергә съездны ташлап чыгып китә. Ул инде яңадан фронтка әйләнеп кайтмый, ә «совет» идеяләре белән канатланып, Мамадышка кайта.

Яңа тормыш, яңа үзгәрешләр аны үз эченә бөтереп алып кереп китә. Рәүф Сабиров, беренче эше итеп, шәһәрдә оешып килүче большевиклар партиясенә керә, аның җитәкчесе Александр Давыдовның уң кулына әйләнә, Өяз мөселман комитетын оештыруда катнаша. 1918–1921 елларда татар педагогик курсларында укыта. Җаны-тәне белән яңа тормышка бирелгән егетне якташлары 1919 елның апрелендә Мамадыш Өяз башкарма комитетының рәисе итеп сайлыйлар.

Бу вазыйфасында ул 1921 елның июненә кадәр тора. 1920–1921 еллар Татарстан Республикасы тарихына рәхимсез ачлык еллары булып кереп калган. Мамадыш өязендә дә ачлык хөкем сөрә. Рәүф Сабиров карары нигезендә, төнге бердән соң урамда йөргән кешеләр кулга алына һәм суд хөкеменә тапшырыла. Авырлык белән булса да, өяздә тәртип урнаша.

Бу сынауны зур сабырлык белән кичкән, кантонны ачлык хәленнән тиз арада чыгара алган Рәүф Сабировны ТАССРның Үзәк комититетында да күреп алалар һәм 1921 елның июнь аенда безнең якташыбыз ТАССР Үзәк башкарма комитеты рәисе итеп сайланыла. Бу вакытта аңа нибары 27 яшь була! Якташыбызның армый-талмый эшләве, дөрес җитәкчелек итүе нәтиҗәсендә Татарстан Республикасы ачлыкны җиңә: авыл хуҗалыгы торгызыла, вакытлыча ябылган предприятиеләр ачыла, яңа завод-фабрикалар төзелә һәм эшли башлый.

Рәүф Сабиров тарафыннан 1923 елны язылган «Татарстан Республикасы авыллары ачлыктан соң» (1922ел) дип исемләнгән китапта әлеге елларның фаҗигасе җентекләп күрсәтелә. Ул анда гаилә-гаилә белән үлүләр, исән калганнарның «бәхетле тормыш» эзләп чит өлкәләргә китүләре аркасында авылларның юкка чыгуы, мал-туар үлүе, «кеше ашаучылык»ның киң таралуы сәбәпләрен атый, чыгу юлларын билгели.

Башта ТАССР Үзәк башкарма комитеты рәисе, ә аннан инде Үзәк башкарма комитеты Президиумы рәисе булып якташыбыз 1924 елгача тора, аннан аны тагы да югарыга күтәрәләр, Мәскәүгә алалар һәм СССР Үзәк башкарма комитетында милли мәсьәләләр буенча җитәкче урынбасары итеп сайлап куялар. 20 нче еллар ахырында йөз меңнәрчә гомерне өзгән «репрессия машина»сы эшли башлый, аның тәгәрмәче астына беренчеләрдән булып «милләтчелектә» гаепләнгән күренекле татар зыялылары, галимнәре, җитәкчеләре эләгә. «Солтангалиевчелектә» гаепләп, 1929 елда Рәүф Сабировны да кулга алалар, партиядән чыгаралар. Бу хәлләрнең башында мондый тарихи вакыйга тора: 1923 елны, әле Үзәк башкарма комитеты рәисе булган вакытында, ул партия җыелышында Солтангалиевне яклап чыккан була.

Якташыбызны беренче көннән ук авыр шартларда тоталар, кеше чыдамаслык җәзаларга дучар итәләр, туктаусыз кыйныйлар, аңа «халык дошманы» исеме тагыла. Ике ел төрмәдә һәм лагерьда ябып тотканнан соң гына аны ирекә чыгаралар. Әмма ул инде үзенең җитәкчелек эшенә кайта алмый, Мәскәүнең автомобильләр эшләү заводы – «ЗИС»ка гади эшче – фрезеровщик булып урнаша, бер-ике елдан бригадир, аннан соң заводның профсоюз комитеты әгъзасы итеп сайлап куялар.

Ләкин…1937 елда яңадан югары күтәрелгән якташыбызны икенче тапкыр кулга алалар. Бу вакыттагы репрессияләр башында 1921 елда Рәүф Әхмәт улы белән бергә ТАССР өлкә комитетында эшләгән Николай Ежов тора. Алар төрле мәсьәләләр буенча еш кына бәхәскә кергән булалар һәм бу бәхәсләрдә һәрчак Рәүф Сабиров өстен чыга. Үз сүзен курыкмыйча әйтә алган татар егетеннән Н.Ежов еллар үткәч «үч ала», репрессия ачысын бер тапкыр кичергән якташыбызны кабат кулга алдыра. Яңадан сорау алулар, кыйнаулар, жәзалаулар башлана… Бу елда кулга алынган бер генә «халык дошманы» да, мөгаен, исән калмагандыр: Рәүф Сабиров та, шул елның 30 нчы декабрендә тәмам кешелектән чыгарылып, 1937нче елда атып үтерелә. Мамадыш өязенең Айдар авылында туып, мәдрәсәдә белем алган, окопларда сугыш авырлыгын кичергән, бөтен республика күләмендә ачлыкны җиңүгә ирешкән, башта Мамадыш өязе, аннан Мамадыш кантоны башкарма комитеты рәисе, ТАССР Башкарма комитеты президиумы рәисе дәрәҗәсенә ирешкән, Мәскәү Үзәк комитетында эшләгән, В. И. Ленинның Татарстандагы ышанычлы көрәштәше булган Рәүф Сабировның исеме 1989нчы елда аклана. Авылыбызда туган Рәүф абыйның нигезенә анын истәлеге итеп мемориаль такта куелачак. Соңлап булса да «исеме акланган» авылдашыбызны онытырга хакыбыз юк…

Эшемдә куйган максатка ирештем дип уйлыйм. Без туган ягыбызны яратучы һәм аның белән кызыксынучы буларак, картларның сөйләгәннәрен хәтеребездә калдырырга тырышып, авылыбызда һәм башка җирләрдә яшәүче әби-бабайларның өйләренә барып, алардан авылыбызның тарихына һәм кешеләренә кагылышлы вакыйгаларны сөйләтеп язып алдык. Без үз Туган төбәгебез тарихын ныграк өйрәнәбез икән, аның киләчәге турында да тирәнрәк уйланырбыз дигән фикергә

килдек. Үткәннәр турында мәгълүматлар табарга, тарихи фактларны ачарга һәркемнең кулыннан килә. Мәктәпләрдә Туган якны өйрәнү эшен тагын да киң җәелдерсәк, әлегә исән булган өлкән яшьтәге кешеләр белән очрашсак, аларның истәлекләрен һәм сөйләгәннәрен язып алсак, авылыбыз китапханәсенә һәм Туган якны өйрәнү музеена мөрәҗәгать итсәк, Туган ягыбыз безгә үзенең кабатланмас тарихы һәм матур үзенчәлекләре белән тагын да тирәнрәк ачылыр. Аны белү, тарихи истәлекләрне бергә туплау, саклау безгә тормышта үз урыныбызны табарга, Ватаныбызга файдалы булып үсәргә ярдәм итәр. Һәрбер яңа буынның язмышы үткән заман белән аерылгысыз бәйләнештә тора. Шушы бәйләнешнең бер өлешен без дә күрсәтәтергә тырыштык. Тарих, әлбәттә, моның белән генә чикләнми. Хатирәләргә бай туган авылым, аның шәхесләре турында әле өйрәнәсе дә өйрәнәсе…

## ТУГАН ЯГЫМ МӘГЪРИФӘТЧЕЛӘРЕ

**Садретдинова Розалия Салих кызы**
*Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы*
*Бураково урта мәктәбенең Көек авылындагы филиалы*

### Туган ягыбыз – изге Болгар җире

Спас районы Татарстанның көньяк-көнчыгышында, табигатьнең бик матур бер кочагында урнашкан. Район үзәге – Болгар шәһәре, бүгенге көндә ул тарихи мирасыбыз, сәяси, икътисади һәм мәдәни үзәгебез булып тора. X гасырда нигез салынган Болгар дәүләте халыкара сәүдә үзәгенә әверелә. Авыл хуҗалыгы да алга китә. Халык игенчелек, балыкчылык, аучылык, зәркәнчылык, тимер кою белән шөгыльләнгән. Таштан биналар төзегәннәр, зур мунчалар салганнар, хәтта үзләренең акчалары булган. Медицина бик нык алга киткән. Халык бай һәм мул тормышта яшәгән. Галимнәр, шагыйрьләр, язучылар, дин әһелләре өчен Болгар иленең башкаласы төп үзәк булып торган.

### Данлыклы якташларыбыз

### Патриот – язучы, әкиятче Абдулла Алиш

Без авылдашыбыз, патриот – язучы, әкиятче Абдулла Алиш белән бик горурланабыз. Ул 1908 елның 15 сентябрендә туа. 1922 елның сентябрендә ул, туганы Газиз Алишев белән, Спас шәһәрендәге җидееллык мәктәптә укый башлый.

Абдулла кичәләрдә, концертларда катнаша. Шулай ук укуда иптәшләренә ярдәм күрсәтә, мәктәпләргә шефлык итә, ятимнәргә ярдәм җыеша, экскурсияләргә йөри. Хәрәкәтле уеннар уйнарга, су коенырга, кышларын тимераякта, чаңгыда шуарга, Актай елгасында балык тотарга ярата. Әмма әдәбият белән кызыксынуы барсыннан да өстен була. Әдәбият түгәрәгенә дә бик теләп йөри. Җәйләрен мәктәп яны участогында да эшлиләр. 7 сыйныфка күчкәч, Абдулла, 7 сыйныф укучысы булу белән бергә, педтехникумның I курс тыңлаучысы да булып санала. Ул бик тырышып укый, алдынгылар рәтендә була. Хәтта стипендия дә алып бара. Мәктәптә һәм интернатта җәмәгать эшләрендә актив катнаша. Мәктәп күләмендә чыгып килгән «Алга» исемле пионер стена газетасының редколлегия члены һәм актив авторы була, әдәбият, драма, спорт түгәрәкләренә йөри. Комсомоллар белән төрле концертларда, кичәләрдә чыгыш ясыйлар, пионерлар арасында отряд вожатые була. Ул 1927 нче елда җир төзү техникумын тәмамлый, төрле эшләрдә эшли һәм Казан дәүләт педагогия институтының тарих-филология бүлегенә укырга керә.

1933 елдан алып 1941 елга кадәр Алиш «Пионер каләме» журналының җаваплы секретаре булып эшли. Бөек Ватан сугышы башлангач, Абдулла Алиш 1941 елның 14 июлендә фронтка китә. Орлов өлкәсендә сугышларда катнаша. Әмма октябрьдә Десна елгасы буенда барган каты бәрелештә чолганышта кала һәм фашистлар кулына әсир булып төшә. Илбасарлар башта яраткан язучыбызны төрле лагерьларда йөрткәннәр, аннан соң Берлин янындагы Вустраугa

килеп эләгә. Биредә ул шагыйрь Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре белән очраша. Бик тиз арада аралашып китәләр. Бергәләп фашистларга каршы оешмада эшлиләр. Тик 1943 елда бу оешманың эше фашистларга билгеле була. Җәлилчеләр һәм Абдулла Алиш кулга алыналар, үлем җәзасына хөкем ителәләр.

1944 елның 25 августында фашист палачлары аны гильотинада җәзалап үтерәләр. Туган илебез А.Алишны онытмый. Үлгәннән соң батырлыклары өчен аны орден һәм медальләр белән бүләкли. Аның исемен йөртүче мәктәпләр, балалар оешмалары, урамнар бар. Казан шәһәрендә, туган авылы Көектә музей эшли, һәйкәл куелган. Балалар бакчаларында, мәктәпләрдә аның әсәрләрен, әкиятләрен, хикәяләрен балалар бик яратып укыйлар, әкиятләрен сәхнәләштерәләр. Казан дәүләт курчак театры аның «Сертотмас үрдәк» әкиятен сәхнәләштерде. Шагыйрьләр аңа багышлап шигырьләр язалар. Композиторлар аның шигырьләренә җырлар иҗат итәләр.

Батыр авылдашыбызның тууына быел 116 ел булды, әмма без аны һичкайчан онытмыйбыз. Һәр ел саен аның туган көнендә Шигырь бәйрәме үткәрәбез. Язучылар белән очрашулар, Алиш премиясен тапшыру чаралары да безнең авылыбызда үтә. Без үзебезнең Алиш варислары булуыбыз белән бик горурланабыз.

**Татарстан Президентының матбугат үзәге җитәкчесе, язучы Әнәс Хәсәнов**

Озак еллар Татарстан Президентының матбугат үзәге җитәкчесе булып эшләгән, язучы Әнәс Хәсән улы Хәсәновны да якташлары бик хөрмәт итә. Ул 1935 елның 23 июнендә Спас (элекке Куйбышев) районы Көек авылында туган. Мәктәптә бик тырышып укый, гел алдынгылар рәтендә була. Шуңа күрә район пионер слетларында еш катнашырга туры килә. Әнәс Хәсәнов төрле җәмәгать эшләрендә, концерт-спектакльләрдә катнаша. Мәктәпне тәмамлаганнан соң, Спас педагогия училищесына укырга керә. 1954 елда аны уңышлы гына тәмамлый. Ә 1959 елда Казан педагогия институтын тәмамлый. Уку дәверендә өлкән пионервожатый булып та эшләргә туры килә. 1959–1972 елларда Казан телевидениесе студиясенең балалар өчен тапшырулар редакциясендә редактор, өлкән редактор, аннары иҗтимагый-сәяси тапшыруларның баш редакторы булып эшли.

1984 елга кадәр – партия өлкә комитетының мәдәният бүлегендә инструктор, 1984–1988 елларда – Татарстан китап нәшриятында баш редактор урынбасары, 1988–1990 елларда «Татарстан» («Татарстан коммунисты») журналының җаваплы секретаре булып эшли.

1991 елда Әнәс Хәсәнов ТАССР Югары Советы секретариатының өлкән консультанты, аннан соң Татарстан Президентының матбугат үзәге җитәкчесе итеп билгеләнә. Соңыннан Татарстан Президентының матбугат архивы мөдире була. Бик күп премияләр иясе, журналистлар Союзы әгъзасы.

Әнәс Хәсәнов – күпкырлы иҗатчы. Ул тәрҗемә өлкәсендә дә күп хезмәт куя. Рафаэль Мостафин белән берлектә Әнәс «Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев» исемле китап язды һәм аны үзе үк тәрҗемә дә итте.

**Педагогика фәннәре докторы, профессор Әнвәр Хуҗиәхмәтов**

Россиянең һәм Татарстанның атказанган укытучысы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, педагогика фәннәре докторы, профессор Әнвәр Нуриәхмәт улы Хуҗиәхмәтов.

Якташларыбыз арасында Татарстан Республикасының фән һәм белем үсешенә зур өлеш керткән якташларыбыз да бар. Алар арасында **Әнвәр Нуриәхмәт улы Хуҗиәхмәтов** тә бар.

Ул 1952 елның 30 июлендә Кузнечиха районы Йолдыз авылында (Хәзер Спас районы) туа. Әтисе Нуриәхмәт һәм әнисе Зөлхәбирә ун бала тәрбияләп үстергәннәр. Алар гаиләседә 5 малай һәм 5 кыз үскән. Әнвәр абый үзе 8 нче бала булып дөньяга килгән. Мәктәптә дә гел «5» ле билгеләренә укый.

Кечкенәдән үк мәкаләләр язарга яраткан бала иҗади малай булып таныла. «Ялкын», «Пионерская правда», «Яшь ленинчы» кебек балалар матбугатының актив хәбәрчесенә әйләнә. 7 класста укыганда «Пионерская правда» газетасы Бөтенроссия «Бөркеткәй» пионер лагерена җибәрә. Ә 8 сыйныфта исә ВЛКСМ ның өлкә комитеты һәм хәзерге «Сабантуй» журналы редакциясе Әнвәр абыйны «Артек»ка юллама белән бүләкли. Бала чагында булган бу күңелле мизгелләр

бер дә онытылмый, әлбәттә. Дөньяның төрле төбәгеннән килгән яшүсмерләр белән аралашу, яңа мохиткә эләгү яшүсмер күңелендә онытылмас хатирәләр калдыра.

Әнвәр абый мәктәптә төгәл фәннәр – математика, физиканы бик яхшы үзләштерә. Бу өлкәгә караган мәсьәләләрне бүген дә бернинди авырлыксыз чишеп бирә алам, – дип җавап бирә ул үзенең бер интервьюсында. Укытучылар да, туганнары да аны я математик, я физик итеп күзаллыйлар. Әти-әнисенең исә авыл хуҗалыгы институтында укытасылары килә. Әмма Әнвәр абый КДУ га журналистика юнәлеше буенча укырга керә. Югары уку йортын уңышлы гына тәмамлый үзенең туган ягына мәктәп укытучысы булып эшкә кайта. Мәктәп дөньясы шулкадәр мавыктыргыч була ки, ул үзенең бөтен көчен биреп эшли башлый.

Аннары завуч, мәктәп директоры, РОНО хезмәткәре булып та эшләргә туры килә. Алга таба тагын да югарырак дәрәҗәләргә ирешә, Казанда министрлыкта, аннары университетта Әнвәр абый үзенең педагогик эшчәнлеген дәвам иттерә.

Хәзерге вакытта Әнвәр Нуриәхмәт улы – Казан федераль (Идел буе) университетының Мәгариф һәм психология институтының укыту һәм тәрбия методологиясе кафедрасы җитәкчесе.

7 монография, педагогика буенча бик күп хезмәтләр һәм дәреслекләр авторы, Муса Җәлил, Каюм Насыйри исемендәге премияләр лауреаты, «Почет билгесе» орденына, СССР авыл хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенең бронза, көмеш, алтын медальләренә лаек.

Әнвәр Нуриәхмәт улы Хуҗиәхмәтов җитәкчелек иткәндә, Чәчәкле урта мәктәбе гөрләп тора. Укудан тыш, укучылар алма бакчасында, терлек фермасында көч куялар, умартачылык һәм урманчылык белән шөгыльләнәләр. Барысы да җиң сызганып эшлиләр: сыер да савалар, сарыклар, куяннар карыйлар, алма бакчасында төрле сортлы алмалар, җиләк-җимеш үстерәләр. Укучыларның хезмәте бушка китми. Алар ил күләмендә үткәрелә торган СССР авыл хуҗалыгы күргәзмәләрендә катнашып, күп кенә медальләр һәм грамоталар белән бүләкләнәләр.

Ә инде «Кече Артек» хезмәт һәм ял лагерының даны хәтта бөтен илгә тарала. Ул елларда лагерьда атаклы кешеләр, галимнәр, язучылар, артистлар, район җитәкчеләре дә кунак була. Алар укучылар белән очрашулар оештыралар, концертлар куялар. Укучылар да эшләп кенә тормыйлар, зур-зур шәһәрләргә экскурсияләргә баралар, кинолар, концертлар карыйлар. Чәчәкле мәктәбе укучылары ул елларны бары яхшы яктан гына искә алалар. «Күңелле, кызык вакытлар иде», – дип яшьлек хатирәләрен барлыйлар.

### Профессорның укучылары

Бүгенге көндә Әнвәр абыйның укучылары арасында остазларының эшен лаеклы дәвам итүчеләр шактый. Аларның кайберләрен атап китәсем килә.

#### *Педагогика фәннәре кандидаты, «ШАЯН ТВ» балалар каналы җитәкчесе Рамилә Әхмәтзакир кызы Сәхабетдинова*

Рамилә апа 1969 елның 12 февралендә элеккеге Куйбышев районы (Хәзерге Спас районы) Чәчәкле авылында туып үсә. Мәктәпне «5» ле билгеләренә генә тәмамлый һәм Казан Дәүләт университетының журналистика факультетына укырга керә. 1992 елда бу уку йортын уңышлы гына тәмамлый. 1986–2000 елларда режиссер ярдәмчесе, «Татарстан» Дәүләт телерадиокомпаниясендә балалар тапшырулары редакторы, 2002 елдан «Татарстан – Яңа гасыр» телерадиокомпаниясенең балалар һәм яшьләр тапшырулары иҗади берләшмәсе директоры булып эшли. «Тамчы-шоу», «Яшьләр тукталышы», «Күчтәнәч», «Син – минеке, мин – синеке», «Мәктәп» тапшырулары авторы һәм редакторы. 2004–2008 елларда Россия Федерациясе Дәүләт Думасында депутат ярдәмчесе булып тора. 2005 елда Йошкар-Ола шәһәренең Мари дәүләт университетында кандидатлык диссертациясен яклый. Республикакүләм «Алтын каләм» яшь журналистлар фестиваленең оештыручысы һәм жюри әгъзасы, Казан Дәүләт мәдәният һәм сәнгать университеты доценты, Татарстан Республикасының журналистлар Союзы әгъзасы, «Татарстан – Яңа гасыр» иҗтимагый-сәяси хәрәкәтенең лидеры. Рамилә апа 2001–2006 нчы

елларда берничә тапкыр «Бәллүр каләм» премиясенә лаек була. 2009 елда «ТЭФИ-Регион» конкурсында «Күчтәнәч» тапшыруы «Алтын Орфей» премиясенә лаек була. 2010 елда Россия телевидениесе Академиясе дипломына лаек була.

2018 нче елның 12 нче ноябрендә Татарстан Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханов инициативасы белән «ШАЯН ТВ» исемле балалар каналы гамәлгә куелды. Рамилә Әхмәтзакир кызы – бу каналның оештыручысы һәм җитәкчесе дә. Якташыбыз бер нәрсә алдында да куркып кала торганнардан тугел. Куйган максатларына һичшиксез ирешә. Милләте, аның киләчәге өчен янып-көеп яши.

***Татарстан Фән һәм мәгариф министрлыгының әйдәп баручы консультанты, төбәкара хезмәттәшлек бүлеге хезмәткәре Әлфия Гафиятулла кызы Әхәтова***

Әлфия Гафиятулла кызы күп еллар дәвамында Яр Чаллы шәһәре мәктәпләрендә балаларга белем бирде. Бүгенге көндә ул татар милли мәгарифе өчен күп хезмәт куя. Әлфия апаның әнисе Насыйбуллина Халидә Минсабир кызы да озак еллар мәктәптә математика укытучысы булып эшләде. Хәзерге көндә инде ул лаеклы ялда, әмма кызы әнисенең эшен лаеклы дәвам итә.

**Мөгаллимнәр нәселе**

Минем каенанам **Садретдинова Җария Рәхим** кызы күп еллар дәвамында авылыбыз мәктәбендә физика һәм математика укытучысы булып эшләде. Аның хезмәт стажы – 50 ел. Ул үзенең мөгаллим булып эшләгән елларын бары тик яхшы яктан гына искә ала.

Җария Рәим кызы кышның чатнама суык бер көнендә, 1941 елның 15 декабрендә дөньяга аваз сала. Нәкъ шул көнне әтисе, Миңнегулов Рәхимулла, башкалабыз Мәскәү янында барган канкойгыч бәрелешләрдә һәлак була. Әнисе Мәфтуха тугыз бала белән тол кала. «Әнигә дә җиңел булмагандыр инде, әлбәттә. Әмма ул безне барыбызны да исән-сау үстерде, акыллы, тәүфыйклы итеп тәрбияләде. Тормыш юлларында очраган авырлыкларны җиңеп, дөньяның матурлыгын тоеп яшәргә өйрәтте», – дип искә ала ул балалык елларын. Спас районы Ирек авылында туып үссә дә, укырга Иске Рәҗәп мәктәбенә йөри. Ул бик тырышып укый һәм мәктәп күләмендә үткәрелгән чараларда бик актив катнаша.

1965 елда Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлаганнннан соң, Көек мәктәбенә эшкә килә. Җария Рәим кызы укытучы булып кына эшләп калмый, өлкән пионервожатый вазифасын да алып бара. Укучылар белән бик актив эшли, күп кенә кызыклы чаралар оештыра, үзе гармунда уйнап җырлый.

Мәктәптә үткәрелгән чараларга без Җария Рәим кызын еш чакырабыз. Анда ул үзенең яшьлек хатирәләре белән уртаклаша, укучыларга үзенең үгет-нәсихәтләрен бирә. Бүгенге көндә Җария Рәим кызы лаеклы ялда.

Мин үзем дә 27 нче ел укытучы булып эшлим. Минем арттан сеңелләрем дә педагог һөнәрен сайладылар. Башлангыч сыйныфлар укытучысы һөнәрен алган Равилә сеңелемнең эш стажы – 22 ел, инглиз теле укытучысы булып эшләүче Гөлназ сеңелемнең эш стажы – 12 ел. Тагын бер туганыбыз, математика укытучысы булып эшләүче Садретдинова Нурзилә Габделәзәл кызының да хезмәт юлы 30 елга тигез. Шулай итеп, безнең нәселебезнең мөгаллимлек стажы бер гасырдан артык, барлыгы 140 елны тәшкил итә.

**Йомгаклау.** Эшемә нәтиҗә ясап, түбәндәгеләрне әйтеп китәсем килә. Якташларыбыз арасында атаклы мөгаллимнәребез бик күп! Туганнарыбыз арасында укытучы булган, бу һөнәргә тугъры калган нәселебез дәвамчылары да шактый. Алар үз эшләрен яратып башкаралар, балаларга гыйлем һәм тәрбия орлыклары чәчәләр. Мин аларның һәркайсы белән горурланам. Шундый шәхесләребез булганда, татар мәгарифе алга таба да зур уңышларга ирешәчәк әле.

**Кулланылган әдәбият:**


1. Алиш А. Г., Бикчәнтәева Ә. Ә. Тылсымлы хикәяләр. – Казан: ТаРИХ, 2003.
2. Алиш А. Г. Сайланма әсәрләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1969.

3. Сөнкишева И. Г. Язучы да Алиш, батыр да. Абдулла Алиш турында истәлекләр. – Казан: Мәгариф, 2001.
4. «Мәйдан» журналы, № 5, 2009.
5. «Яңа тормыш» газетасы, 1 март, 2019 ел.
6. «Энциклопедия города Болгара и Спасского района» – Болгар: 2017

## Р.С.ГАЗИЗОВНЫҢ БЕРЕНЧЕ БАСКЫЧ МӘКТӘПЛӘРДӘ УКУЧЫ ТАТАР БАЛАЛАРЫН УКЫРГА–ЯЗАРГА ӨЙРӘТҮДӘГЕ ЭШЧӘНЛЕГЕ

**Хуснуллина Зилина Мәгфур кызы**
*Урта белем бирү Дәүләт автономияле*
*һөнәри белем бирү учреждениясе*
*«Казан мәгълүмати технологияләр*
*һәм элемтә техникумы»*

Бүгенге көндә Р. С. Газизовның чагыштырма грамматикалары, русларга татар теле дәреслекләре, татарларга рус теле дәреслекләре, лексикография өлкәсендәге эшчәнлеге фәнни яктан җентекләп өйрәнелгән. Шуңа күрә без рус һәм татар мәктәпләренең башлангыч сыйныфларында татар теленә өйрәтүдә Р. С. Газизовның фәнни–методик эшчәнлеген өйрәнүне эшенең төп максаты итеп куйдык. Әлеге максатка ирешү өчен, түбәндәге бурычларны билгеләдек:

1. Р.С.Газизовның беренче баскыч мәктәпләрдә укучы татар балаларын укырга–язарга өйрәтү юлларын ачыклау.

2. Р.Газизовның М. Х. Корбангалиев белән берлектә язган «Русларга татар теле өйрәтү өчен кулланма һәм дәреслек», М.Сударчиков белән берлектә язган «Сборник упражнений по грамматике и развитию устной и письменной речи» дигән хезмәтләренә күзәтү ясап, телгә өйрәтүнең ысулларын һәм алымнарын, принципларын билгеләү.

3. «Руслар өчен татар теле дәреслеге»нең төзелешен өйрәнү, эчтәлеген, тематикасын ачыклау һәм бүгенге башлангыч сыйныф дәреслекләре белән чагыштыру.

Тикшерү объекты булып Р. С. Газизовның башлангыч мәктәпләрдә рус һәм татар теленә өйрәтүнең барышы тора.

Эшенең теоретик нигезендә М.Корбангалиевнең «Ана теле методикасы» (1918), А. Ш. Асадуллин, Л. З. Шакирова, М. З. Зәкиев, Ф. Ю. Юсупов, Ф. С. Сафиуллина, Р. А. Юсупов, Ф. Ф. Харисов, А. А. Леонтьев, Т. А. Вишнякова һ.б. хезмәтләр ята.

Әлеге эшнең төзелешенә килгәндә, ул керештән, төп өлештән, йомгак һәм кулланылган әдәбият исемлегеннән тора. Керештә теманың актуальлеген һәм максатларын билгеләдек, төп бурычлар ачыкланды, тикшерү объекты, теоретик нигезе күрсәтелде.

Укырга һәм язарга өйрәтүдә Ризаэтдин Сәлахетдин улы Газизовның (1894–1981) фәннияметодик эшчәнлеген карап чыккач, түбәндәге нәтиҗәләргә килдек:

1. Совет чоры мәктәбендә укырга–язарга өйрәтү барышында 1923 еллардан алып комплекс, бригада–лаборатория кебек яңа ысуллар кулланыла башлый. Әлеге ысуллар әлифба укытуга да бик нык кагыла. Америка мәктәпләрендә әлифба беренче ярты еллыкта бөтенләй кулланылмаганга күрә, Р. С. Газизов та әлифбасыз укытып була дигән фикер үткәрә, беренчеләрдән булып аның методикасын эшли. Ул әлифбасыз укырга–язарга өйрәтүдә ике чорны күз уңында тота:

– укырга–язарга өйрәтүгә хәзерлек күрү моменты,
– укырга–язарга өйрәтү моменты.

Р. С. Газизов «коллектив хикәяләр» төзү һәм язуга хәзерлек өчен рәсем эшләрен дәвам иттерү белән бергә сүзләрнең иҗекләргә бүленеше белән дә таныштыра. Автор, рәсемнәргә таянып, сөаль–җавап рәвешендә җөмләләр төзи, ныклы күнекмәләр булдыра: иҗекләр язып

һәм әйтеп уйнау, дәфтәр–альбом тутырту һ. б. эшләр тәкъдим итә. Р. С. Газизов бу юлны «табигый юл» дип саный һәм өйдә укырга өйрәнүне «балалар өчен таныш әйберләр һәм сурәтләр аркылы булуыннан килеп чыгуын» ассысыклый. Өй шартларында укырга–язарга өйрәнгән балаларны мәктәптә грамотага өйрәнгән балалар белән берничек тә чагыштырып булмый, әлбәттә. Ләкин шуның белән бергә мондый табигый юл белән һичкем тарафыннан мәҗбүр ителмичә укырга–язарга өйрәнү эше «тулы сурәтләр – балага таныш берәр әйбернең үзе яки аның сурәте (картиналары) – белән бәйләнгән сүзләр һәм җөмләләр аркылы» булуы бәхәссез.

2. Р. С. Газизов лаборатория планы буенча ана теле дәресләрен ничек алып баруның методикасын бирә. Иң элек методист укытуның максатын, сайланган материал һәм өйрәтү әмәлләрен ачыклый. Ана теле дәресләрен ул дүрт өлешкә бүлә: а) уку һәм язу, б) грамматикага өйрәтү, в) сөйләү һәм язу телләрен үстерү, г) әдәби әсәрләрне өйрәнү. Автор лаборатория планы буенча укырга өйрәтүнең гомуми юлларын да билгели: укучының берәр әсәрне үзлегеннән укуына ирешү, сүзлек эшен башкару, әсәрнең төп фикерен ачыклау, эчтәлеге буенча сораулар әзерләү, нәтиҗәләр чыгару өчен бөтен коллектив белән әңгәмә ясау һ. б.

3. Автор «Лаборатория планы буенча ана теле дәресләре» дигән мәкаләсендә укырга өйрәтүгә өлешчә генә кагылса, ә «Беренче баскыч мәктәптә уку» дигән мәкаләсендә башлангыч мәктәпләрдә укучыны ана теленнән укырга өйрәтүнең методикасын бирә. Р. С. Газизов укуның бүлекләреннән бигрәк тә тасвирлы уку һәм изахлы укуны җентекләп тикшерә. Аның фикеренчә, уку тасвирлы булсын өчен, укытучы түбәндәгеләрне истә тотарга тиеш:

1) тавышны дөрес алып бару,
2) кирәк хәтле һаваны эчкә ала һәм аны кирәк хәтле генә чыгара белү,
3) аерым сүзләрне һәм авазларны гадәттәгечә дөрес әйтә белү,
4) укыган вакытта туктальшларны дөрес ясау,
5) әкеренлек һәм тизлек,
6) басымны дөрес кую.

4. Р. С. Газизов «Табигыймы яки табигый булырга тиеш түгелме?» дигән мәкаләсендә дөрес язарга (имлага) өйрәтүнең принципларын тикшерә һәм аларга аңлатма бирә. Р. С. Газизов башлангыч сыйныфларда ук тавыш дәрәҗәсе, интонация, басымлы иҗекләр белән эшләү, тавышны үзгәртә белү, ткуталышлар һ. б. ны эшләүнең зарурлыгын ассызыклый. Башлангыч мәктәпләрдә үк баланы аңлап, тәрбияле укырга гадәтләндергәндә, һәр сүзнең тәэсир итү көченә игътибар итү, аерым–аерым фикерләр һәм әсәрнең өлешләре арасында булган бәйләнешне күрү, бөтен әсәрнең төп нәтиҗәсен әтәли күрә белүне күз уңында тота.

5. Р. С. Газизовның М. Х. Корбангалиев белән берлектә 1925 елда язган «Русларга татар теле өйрәтү өчен кулланма һәм дәреслек» шушы өлкәгә караган иң беренче дип әйтерлек хезмәтләрдән санала. Билгеле, дәреслектә җанлы сөйләм дәресләренең бер–берсе белән булган бәйләнешләренең кайвакыт өзелгән урыннарына да юлыгасың. Сөйләм авазлары белән эшләү дә игътибардан читтә калган кебек тоела. Ләкин шулай да заманы өчен бу дәреслек русларга татар телен өйрәтүдә бик мөһим роль уйнаган.

6. Уку–язуга өйрәтү дәресләрендә тәкъдим ителгән күнегүләр нигездә тәрҗемәле–грамматик ысулга нигезләнгән. Күнегүләрнең бер төре тәрҗемә белән бәйле рәвештә тәкъдим ителгән (үрнәктәге фразаларга тиешле тагылмаларны куеп тәрҗемә итегез, үрнәксез фразаларны татар теленә тәрҗемә итегез, тексны тәрҗемә итегез), ә икенче төре күбрәк грамматик материалны хәтердә ныграк калдыру максатыннан төзелгән.

7. Р. С. Газизовның М. Х. Корбангалиев белән берлектә төзегән «Русларга татар теле өйрәтү өчен кулланма һәм дәреслек» дигән хезмәтендә җанлы сөйләм дәресләре һәм уку–язуга өйрәтү дәресләреннән соң китапның яртысыннан күбесен сөйләмә һәм язма телне ныгытуга багышланган материал алып тора. Биредә тәҗрибәле методистлар зур күләмле текстлар һәм алар белән эшләү күнегүләрен тәкъдим итәләр.

8. Р. С. Газизовның 1941 елда М.Сударчиков белән берлектә язган «Сборник упражнений по грамматике и развитию устной и письменной речи» исемле укытучылар һәм укучылар өчен гамәли һәм фәнни кулланмасы игътибарга лаек. Бу җыентыкта грамматик, лексик, стилистик материал зур урын алып тора. Биредә тел материалын өйрәткәндә, орфоэпия, сүз ясалышы, исем, сыйфат, сан, алмашлык, хикәя фигыль, сыйфат фигыль, хәл фигыль, рәвешләрне үзләштерү күздә тотыла. «Сүз ясалышы»н өйрәнгәндә ныгыту характерындагы күнегүләр планлаштырылган. Биредә язма күнегүләрдән «тәрҗемә итү, сорауларга тулы җавап бирү, алмашлыкларны кулланып, җөмләләр төзү» кебек күнегүләр күбрәк кулланылса, сөйләм күнегүләреннән беренче чиратта «бирелгән сүзләр белән җөмләләр төзү яки җөмләләрне дәвам итү» күздә тотыла.

Гомумән алганда, Р. С. Газизовның татар теле дәреслекләре бик уйлап эшләнгән: текстлар белән эшләү, сүзлек эше, грамматик материалны үзләштерү, сәнгатьле уку, грамотлы итеп язу күнекмәләрен булдыру, иҗади характердагы күнегүләр белән эшләү. Галимнең методик хезмәтләрен барлап, татар теле дәреслекләренә күзәтү ясап чыккач, шундый фикергә киләсең: ул оста укытучы, методист, галим. Хезмәтләрен тикшереп чыкканнан соң, шуны әйтәсе килә: – Газизов Ризаэтдин Сәлахетдин улы чын мәгънәсендә үз эшен белеп, яратып башкаручы методист, тәҗрибәле укытучы. Аның методик кулланмалары, мәктәп дәреслекләре бүген дә үрнәк булып торырлык.

## ЯКТАШЫБЫЗ МӨХЕТДИН КОРБАНГАЛИЕВНЕҢ ПЕДАГОГИК ЭШЧӘНЛЕГЕ

**Шәйдуллина Ләйсән Малик кызы**
*ТР Әгерҗе муниципаль районы*
*МБГББУ Тирсә урта гомуми белем бирү мәктәбе,*
*Туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучысы*

Татар халкы үзенең мәшһүр шәхесләре белән мәртәбәле. Һәр төбәктә горурланырлык, аларның бай мирасын буыннан буынга тапшырырлык зыялыларыбыз бар. Әгерҗе төбәге дә бөек шәхесләргә бик бай. Тел, әдәбият, сәнгать дөньясын гына алсак та, күпме күренекле әдипләребезне санап китә алабыз. Драматург Таҗи Гыйззәт, драматург һәм язучы Юныс Әминов, мәшһүр татар фонетисты Шәехгаттар Иманаев, танылган җырлар авторы, шагыйрь, татар музыка эшлеклесе Ләбиб Айтуганов, язучы Мансур Вәлиев, шагыйрь Фазыл Шәех, шагыйрә һәм мөгаллимә Әнисә Каримова, танылган шагыйрь Чыңгыз Мусин, язучы һәм табиб Габдулла Галиев һәм башкалар. Сүзем бөек педагог Мөхетдин Корбангалиев турында барачак. Беренчедән, М.Корбангалиев – безнең мәшһүр якташыбыз, икенчедән, атаклы педагогның фикерләре бүгенге көндә дә актуальлеген югалтмаган. «Ана телендә укыту – балаларга белем бирүдә һәм аларны тәрбия итүдә бердәнбер корал», – дип, иң элек үз телеңне белүне алгы планга куйган ул. Шулай итеп, эзләнү эшемнең темасы «Якташыбыз Мөхетдин Корбангалиевнең педагогик эшчәнлеге» дип атала. Максатым – Мөхетдин Корбангалиевнең педагогик эшчәнлеген тирәнрәк өйрәнү. Максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны куйдым: М. Корбангалиевның эшчәнлеген төрле чыганаклардан файдаланып эзләнү һәм өйрәнү; бөек педагогның татар телен үстерүгә керткән өлешен өйрәнү; М.Корбангалиевнең «Мирасханә» сайтында бирелгән үрнәкләренә күзәтү ясау; аның нәсел дәвамчылары һәм аларның эшчәнлеге турында өйрәнү.

Якташыбыз Мөхетдин Корбангалиевның эшчәнлеге турында күбрәк белү өчен «Мәшһүр татар галимнәре» җыентыгын, «Әгерҗем – йөрәк җырым» җыентыгын, Интернет челтәрендә бирелгән википедияләрне өйрәндем. Шулай ук М. Корбангалиевнең авылдашы булган һәм аның эшчәнлеге белән тирәннән кызыксынган остазым, мәгариф ветераны Сибгатова Эльза белән әңгәмә оештырдым.

«Профессор Мөхетдин Хафизетдин улы Корбангалиевнең исеме республикабыз чикләреннән еракта да билгеле. М. Корбангалиев 1873 елның 26 ноябрь (7 декабрендә) Биектау авылында (хәзерге Татарстанның Әгерҗе районы) крестьян Корбангалиев Хафизитдин гаиләсендә туа. Гаиләдә Мөхетдиннән тыш ике абыйсы – Нуретдин, Сәйфетдин, шулай ук өч апасы була. Башлангыч белемне ул туган авылында ала, мәктәпкә биш яшеннән үк йөри башлый. 1887 елда авылда рус мәктәбе ачылгач, шунда рус теле һәм әдәбияты белән кызыксынып китә. Укытучылык эшенә күңеле тартыла. Бу теләгенә әтисе каршы килми, шулай итеп Мөхетдин Казандагы укытучылар мәктәбенә (учительская школа) укырга керә. Шунда укыганда беренче тапкыр К.Насыйри белән очраша, өлкән мәгърифәтче аңа татар һәм рус телләрен өйрәнү буенча практик киңәшләр бирә. Корбангалиевнең татар фольклоры белән мавыгуын белгәч, К. Насыйри аңа бу өлкәдә дә төпле фикерләрен җиткерә. М. Корбангалиев үзенең бер язмасында халык әдәбиятын җыюга карата К. Насыйриның үзенә юл күрсәтүен әйтә: «…Бу юлы авыл мәктәбендә җыйган җырларымны, бәетләрне алып барган идем. Ул аларны өстән-өстән карады да картлардан сөйләтеп җыярга кушты… Мин җәй көне, авылга кайткач, шул күрсәткән юл белән байтак нәрсәләр җыйдым».

Казанда укуын тәмамлагач, М. Корбангалиев Мамадыш өязенең бер авылына укытучы итеп җибәрелә. Аның педагоглык хезмәте шул вакыттан башлана. Авыл балаларына рус һәм татар телләрен өйрәтә, үзенең бөтен вакытын, бөтен көчен халыкны агарту эшенә бирә. 1903 елда Корбангалиев Казандагы татар приютына мөдир һәм укытучы итеп күчерелә. Биредә аңа иҗтимагыйсәяси эш өчен дә киң юл ачыла. Ул Х.Ямашев, Г.Колахмәтов белән таныша. Иҗтимагый һәм сәяси тормышта актив катнашуы белән бергә М. Корбангалиев педагоглык эше дә алып бара. Үзенең укыту тәҗрибәсенә таянып, башлангыч мәктәпләр һәм зурлар мәктәбе өчен татар әлифбалары төзи, шулай ук татар теле, математика һәм география буенча да дәреслекләр төзеп бастыра.

Бу дәреслекләрнең кайберләре «Мирасханә» сайтына урнаштырылган. Сайт Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирасы үзәге тарафыннан төзелгән. Сайтта Мөхетдин Корбангалиевнең дүрт дәреслеге урын алган: «Гамәли тел сабаклары», «Дөнья», «Татар әлифбасы» һәм «Татарча уку». Һәр дәреслекне тулысынча күрергә, йөкләтеп алырга мөмкин. Дәреслекләрнең басылу вакыты, ничә биттән икәнлеге, кемнәргә аталганы турында кыскача мәгълүмат бирелгән.

1923–1924 елларда Татарстан хөкүмәте тарафыннан Татарстан Республикасында рус һәм татар телләрен дәүләт телләре дип исәпләү һәм ул телләрне шунда яшәүче барлык кешеләр дә өйрәнергә тиешлек турында карар кабул ителә, рус мәктәпләре өчен татар телендә дәреслекләр төзергә кирәк була. Бу эш Мөхетдин Корбангалиев тарафыннан башлап җибәрелә. 1928 елда М.Корбангалиев һәм Р.Газизов тарафыннан «Русларга татар телен өйрәтү өчен кулланама һәм дәреслек» дигән китап төзеп бастыра. Үзе генә һәм Р.Газизов белән берлектә 1927–1934 елларда урта мәктәптә «Руслар өчен татар теле дәреслеге» (V–VI сыйныф) һәм «Татарлардан башкалар өчен татар теле дәресләре» китапларын төзеп бастыра. Бу дәреслекләр Наркомпрос тарафыннан хәтта техникумнар, вузлар, зурлар курслары өчен дә файдаланырга тәкъдим ителә.

Совет хөкүмәте М.Корбангалиевнең татар халкын агарту өлкәсендәге хезмәтләренә югары бәя бирә. 1928 елда аңа Хезмәт Герое исеме бирелә.1930 елда, Казан университетының 125 еллыгы уңаеннан, ул ТАССРның атказанган фән эшлеклесе дигән мактаулы исем ала. 1940 елда исә, ТАССРның 20 еллыгы уңаеннан, ул Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә. Тиздән галим РСФСРның атказанган фән эшлеклесе исеменә лаек була.

Бөек педагог М.Корбангалиев үз үрнәгендә балаларына да тиешле тәрбия биргән. Алар да, тормышта үз юлларын табып, төрле өлкәләрдә зур уңышларга ирешкәннәр. Профессор Мөхетдин Корбангалиевнең дүрт баласы була. Олы ике баласы мәшһүр табиблар: Салих Корбангалиев – профессор, медицина фәннәре докторы һәм Мөкаррәмә Корбангалиева – табиб-рентгенолог. Кечеләре Хәлимә Корбангалиева – профессор, биология фәннәре докторы, улы Рөстәм Корбангалиев – Бөек Ватан сугышы ветераны, химик.

Бөек педагог Мөхетдин Корбангалиевнең тормыш юлын һәм эшчәнлеген якташыбыз, остазым, мәгариф ветераны, Биектау авылында туып үскән, бүгенге көндә Мордывый авылында яшәүче Сибгатова Эльза Миннеәхмәт кызы җентекләп өйрәнә. Ул М. Корбангалиевнең нәсел шәҗәрәсен дә төзегән. Шулай ук М. Корбангалиев турындагы мәгълүмат Эльза Сибгатованың яңа басылып чыккан «Бөек Себер юлында Биектау» исемле әдәби-документаль җыентыгында лаеклы урын алган.

2023 елда Мөхетдин Корбангалиевнең тууына 150 ел уңаеннан районда һәм туган авылы Биектауда матур чаралар оештырылды. Әгерҗедә Укытучы һәм остаз елын ачу тантанасы, Биектауда галимне искә алу чарасы уздырылды. Татар Шаршадысы авылында Фәүзия Бәйрәмова катнашында Әгерҗе төбәге тарихчылары җыены үтте.

Телне, үз халкын яратуы, хезмәт сөюе, ташып торган энергиясе һәм түземлеге М. Корбангалиевкә барлык кыенлыкларны җиңәргә, үз юлыннан тайпылмыйча алга барырга, максатына ирешергә ярдәм итә. Ул соңгы сулышына кадәр халкыбызны яктылыкка илтү юлында армый-талмый хезмәт итте, мәгариф, мәгърифәтчелек өлкәсендә, мәктәп-мәдрәсәләр ачуда, аларда татар телен укытуны кертүдә нәтиҗәле эшләде. Шуның өчен дә Мөхетдин Хафиз улы Корбангалиевне халкыбыз дан-хөрмәт казанган галимнәрнең берсе дип саный һәм онытмый.

Бөек якташыбыз, күренекле тел белгече, педагог-профессор Мөхетдин Корбангалиевнең тормыш һәм хезмәт юлын, нәсел дәвамчыларының эшчәнлеген өйрәнүне алга таба дәвам итәргә уйлыйм. Без, укытучылар, үз төбәгебезнең тарихын, аның күренекле шәхесләрен белергә, аларны яшь буынга җиткерергә тиеш.

## МӨНИР ТАЛИПОВ ИҖАТЫНДА ТУГАН ЯК ҺӘМ МӘХӘББӘТ ТЕМАСЫНЫҢ АКТУАЛЬЛЕГЕ

**Гафурова Светлана Гарифзяновна**
*МБОУ «Школа № 2» г. Заинска*
*Учитель татарского языка и литературы*

«Яшь буынны гүзәл кеше итеп тәрбияләүдә әдәбият укытучысының җаваплылыгы, тоткан роле аеруча зур. Аның бурычы – эчке һәм тышкы яктан матур, гармонияле, бай рухлы кеше тәрбияләү», – дип яза М.Талипов.

Туган як. Туган туфрак. Туган төбәк. Бу сүзләр өлкән яшьтәге кешеләр өчен генә түгел, һәр сабый бала өчен дә газиз һәм кадерле булырга тиеш. Туган якның табигате, аңа бәйле кызыклы фактлар, аның тарихы, халыкның көнкүреше, гореф-гадәтләре, милли йолалары балаларга белем һәм тәрбия бирүдә зур роль уйный.

Без Зәй туфрагында туып үскән якташ әдипләребез, шагыйрьләребез, галимнәребез, сәнгать кешеләре белән хаклы рәвештә горурланабыз. Шуларның берсе – якташ шагыйребез, җәүһәребез – Мөнир Талипов.

Бүгенге көндә алар безнең арада булмаса да без алар турында белергә, иҗатларын өйрәнергә тиеш. Мин үземнең эзләнү эшемне Мөнир Талипов иҗатына багышлыйм. Мөнир Талипов туган ягы табигатенә гашыйк кеше була. Ул тормышны, балаларны бик ярата. Әдипнең гомер юлы кызыклы, ә әсәрләрендә бүгенге көндә дә бик актуаль темаларның берсе туган як табигатен саклап калу мәсьәләсен күтәрә. Әлеге теманың тәрбияви роле дә бик зур дип саныйм мин, чөнки Татарстан Республикасында яшәүче һәр милләт кешесе, дөнья әдәбияты һәм тарихыннан тыш, үзе яшәгән төбәкнең мәдәниятен, сәнгатен, гореф-гадәтләрен, тарихи үткәнен, бүгенгесен, киләчәген белергә тиеш.

Без бөек шагыйрьләребез иҗатын елдан-ел тирәнрәк өйрәнәбез. Ә янибызда яшәп иҗат иткән җирле язучыларыбыз турында бик аз беләбез. Шушы форсаттан файдаланып мин Зәй районы

Куш-Елга авылында яшәп иҗат иткән шагыйребез Мөнир Талипов иҗаты һәм тормыш юлына күзәтү ясыйм. Туган ягыбыз җәүһәрләрен белү безнең бурычыбыз.

Мөнир Талиповның шигырьләре укучыларда әхлаклылык, мәрхәмәтлелек, кешелеклелек, шәфкатьлелек сыйфатлары тәрбияли.

Җирле язучы Мөнир Вәли улы Талипов 1937 нче елда агачлар шартлап ярылган салкын кышның февраль аенда Әхмәтвәли һәм Бибигарифә Талиповлар гаиләсендә баш бала булып дөньяга аваз сала. Әти-әнисе гади крестьян була. Әтисе 1941нче елда сугышка китә Һәм 1943нче елда Мәскәү яны сугышында батырларча Һәлак була. Әнисе кечкенә Мөнирне һәм 4 айлык энесен кочаклап гомергә тол булып кала. Шулай итеп алар сыңар канат булып ятим үсәләр.Мөнир Талипов гомере буе Куш– Елга авылында яши. Шунда башлангыч белемне ала.Үзлегеннән бик күп укый.10 яшеннән колхоз эшенә йөри башлый. Еллар үтә Мөнир дә егет була. 17 яшендә колхоз фермасына сыерлар көтә. Көннәр буе табигать кочагында йөргәнгәме, Мөнир Талипов шул елларны шигырь яза башлый. Бик озак корылыктан соң бөтен халык зарыгып көткән җәйге җылы яңгыр явып үтә. Шушы шатлыктан соң беренче шигырь юллары туа. Беренче шигыре «Җәйге яңгыр»дип атала. Бу шигырь «Кызыл Зәй» газетасында басылып чыга. Бу 1956 нчы ел була. Шуннан аңа гүя канатлар үскәндәй була Һәм ул шигырьләре, мәкаләләре белән халыкны куандырып тора. Шигырьләре «Туган як авазы», «Төбәгем Тургае» исемле күмәк җыентыкларда дөнья күрә. Сөббух Рафиков исемендәге бүләк иясе була. 2002 нче елда хакимият ярдәме белән «Әбиләр чуагы» китабы басылып чыга. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр кулыннан каләме төшми. Язны, тормышны бик ярatканга күрә 2017 нче елның март аеда Мөнир бабай безнең арадан гомерлеккә китә. Әмма без аны онытмыйбыз, кызыклы, бай эчтәлекле шигырьләрен укып аны искә алабыз.

Әйе, бары тик авыл табигатен яратып, иртәнге сандугач сайравын тыңлап үскән кеше генә шагыйрь була ала, үз төбәгенең табигате турында үтә дә матур хисле шигырьләр яза ала торгандыр.

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ ПЕДАГОГИК КАРАШЛАРЫ

**Минвәлиева Алсинә Харис кызы**
*Казан шәһәре Авиатөзелеш районының*
*«10 нчы гимназия» гомуми белем*
*муниципаль бюджет учреждениесе*
*Башлангыч сыйныф укытучысы*

**Кереш**

**Теманың актуальлеге.** Татар халкының бөек шагыйре буларак танылган Габдулла Тукай турында һәм аның әсәрләре хакында шактый гына хезмәтләр бар. Алар татар, рус һәм башка бик күп төрле чит телләрдә дә тәкъдим ителә. Әмма шул ук вакытта, әлеге шәхеснең педагогик карашлар һәм эшчәнлеге өйрәнелмәгән булып кала бирә. Күпләр аны әлегә кадәр педагоглар исәбенә кертми. Моңа бәйле рәвештә, Г.Тукайның педагогик карашлары милли белем бирү тарихында да чагылыш тапмый диярлек. Мин исә, әлеге тикшеренү эше кысаларында, бөек татар мәгърифәтчесе тәкъдим иткән педагогик фикерләрнең кайбер эпизодларына кагылырга булдым.

**Проблема**. Габдулла Тукайның педагогик карашлары бүгенге көндә дә актуальме?

**Максат**. Габдулла Тукайның педагогик карашларын барлау.

**Бурычлар**:

1) Г. Тукай иҗат иткән әсәрләрдән педагогик фикерләрне аерып алу;
2) Г. Тукай шәхесен мәктәп һәм мәдрәсә дәреслекләре әзерләү остасы буларак ачу;
3) Гомуми нәтиҗәләр ясау.

Кулланылган **методлар**: материалны системага салу, чагыштыру, классификацияләү, гомумиләштерү.

**Төп өлеш**

Габдулла Тукайның педагогик фикерләре бүгенге көндә дә актуальлеген югалтмый. Моның шулай икәнлеген без, иң элек, аның әсәрләре нигезендә барлап китик. Г. Тукай яшь буынга патриотик тәрбия бирү юнәлешендә дә шактый зур эш башкарган шәхес. Аның педагогик юнәлештәге әлеге эшчәнлегенә якынрак килик. Әлеге шәхес үз туган җиренең чын патриоты, шуңа күрә аның күп кенә шигырьләре дә үсеп килүче буынны патриотик рухта тәрбияләүгә багышланган.

Димәк, язучы өчен кече Ватаны шулкадәр якын һәм онытылмаслык, аның балачагы авырлыкта үтсә дә, аңа бернинди дә үпкә сакламый, аның өчен барысы да яхшы, хәтта барлык тискәре персонажлар да ягымлы булып тоела. Боларның барысын да туган җирен чын күңелдән яраткан шагыйрь генә укучысына шул рәвешле сурәтләп тәкъдим итә ала, шуның нәтиҗәсендә ул бала патриотик тәрбия дә бирә. Шагыйрьнең патриотик рухтагы әсәрләре арасында «Пар ат», «Туган авыл» әсәрләре алдынгы урыннарны били. Хәзерге вакытта әлеге шигырьләр үсеп килүче буынны патриотик рухта тәрбияләү өчен алыштыргысыз материал булып хезмәт итә.

Г. Тукай яшь буынга хезмәт тәрбиясе бирү юнәлешендә дә шактый көч куйган. Аның педагогик юнәлештәге әлеге эшчәнлегенә күзәтү ясап китик. Бу өлкәдә аның «Эшкә өндәү» (1911) шигыре зур әһәмияткә ия. Әлеге әсәрендә татар мәгърифәтчесе хезмәттән тәм табу серләрен ача, аерым алганда, бәхет чын күңелдән эш башкару нәтиҗәсендә килә, дип билгели. Шул ук вакытта педагог ялкаулыкның оят, хурлык һәм кимсетүләргә китерүен ассызыклый. Билгеле булганча, мөселман кануннары нигезендә кеше бу дөньяга үзеннән соң данлы исем калдыру өчен туа. Г. Тукай фикерләренә караганда, әгәр кешенең мәңгелек дөньяга күчкәнче үз исемен данлау нияте бар икән, ул үзенә ризык таба белергә һәм, әлбәттә, бу эшкә зур тырышлык куярга тиеш.

Г. Тукай әхлак тәрбиясе бирүгә дә җитди карый. Намуслы кешене җәмгыятьнең пычрак күренешләренә каршы куеп, язучының лирик геройлары мондый чолганышта яшәгәнче җир йөзеннән юкка чыгуны хуп күрә. Димәк, яшь буын Габдулла Тукайның әсәрләре нигезендә яткан педагогик фикерләрне аңлап кабул итсә, һичшиксез, әхлак һәм тәрбия төшенчәләренең нәрсә икәнен аңлый алачак. Мәгърифәтченең логикасына нигезләнеп эш итсәк, аның әйләнә-тирәсе генә түгел, ә бөтен дөнья пычрак һәм ялган баткаклык булып санала. Әмма аннан дөрес итеп чыгу юлын табасың икән, син – җиңүче.

Г. Тукай яшь буынга эстетик тәрбия бирү юнәлешендә дә шактый зур эш башкарган шәхес. Г. Тукайның «Театр» шигыре (1907) эстетик яктан зур хәзинә булып санала. 1906 елның 22 декабрендә татар телендә беренче спектакль уйнала, шуннан соң мәгърифәтченең әлеге шигыре дөнья күрә. Беренче спектакльдән илһамланып, мәгърифәтче театрның халык өчен сабак, йоклап яткан күңелләрне уята торган гыйбрәтле үрнәк булуын билгели. Театрның гаҗәеп үзенчәлеге мәгърифәткә алып баруда. Ул кире борылырга ирек бирми, дөрес юлдан атларга булыша. Театр көлдерә, уйлата, үткән тормыш турында уйланырга мәҗбүр итә. Һәркем театрда үзен, үз тормышын күрә ала. Үз тормышын сәхнәдән күргәч, кеше үткәннәренә анализ ясый башлый: аның үткән тормышында барысы да канәгатьләнерлекме, булмаса, аңа нәрсә җитми? Театр тормышны төзәтергә һәм камилләштерергә мәҗбүр итә, шулай итеп тормыш турында белем алырга мөмкинлек бирә.

Моннан тыш, Габдулла Тукай үз заманында мәктәп һәм мәдрәсә дәреслекләре әзерләүдә дә үз өлешен керткән шәхес. Аның күп сандагы педагогик фикерләре, аерым алганда яшь буынны тәрбияләүдә мәктәпнең роле һәм бурычлары турындагы карашлары, ул төзеп чыгарган дәреслекләр, класстан тыш уку китаплары үз чорында гаять зур әһәмияткә ия булсалар, татар халкы педагогикасы фәне үсешендә дә алар зур роль уйный.

**Йомгак**

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар мәгърифәтчесе Г.Тукай үз әсәрләрендә бүгенге көндә – йөз елдан соң да актуаль булып калган тәрбия юнәлешләренә кагыла һәм шушы эшчәнлеге аны бөек татар мәгърифәтчесенә әйләндерә. Мәгърифәтченең әсәрләре хәзерге белем бирү учреждениесе дәреслекләренә һәм уку әсбапларына кертелгән, аерым китаплар, шулай ук күптомлыклар буларак та нәшер ителә. Киләчәктә мәгърифәтче иҗатында урын алган тәрбиянең башка юнәлешләрен өйрәнүне көчәйтергә һәм фәнни әйләнешкә кертергә кирәк дип саныйм. Бу исә татар халкының педагогик фикере тарихында, гомумән Россия педагогикасы тарихында булган бушлыкларны тутырырга мөмкинлек бирер иде дип уйлыйм.

Ф. Ф. Исламов искәрткәнчә, бөек фикер иясенең педагогик карашлары безнең көннәрдә дә үзләренең актуальлекләрен саклыйлар, укытучыларның методик осталыкларын үстерергә, дөньяга карашларын киңәйтергә, яшь буынны гуманистик рухта тәрбияләргә ярдәм итәләр.

**Кулланылган әдәбият**

1. Исламов Ф. Ф. Мәгърифәт, әдәбият һәм тарих сукмаклары буйлап. – Казан, 2002. – 279 б.
2. Муртазина Л. Тукай – педагог. URL: http://gabdullatukay.ru/news/tukaj-pedagog/

# КАЮМ НАСЫЙРИ: ШӘХЕС, ГАЛИМ, ОСТАЗ

## К.НАСЫЙРИ МИРАСЫ АША УКУЧЫЛАРГА РУХИ-ӘХЛАКЫЙ ТӘРБИЯ БИРҮ

**Багавиева Лилия Данисовна**
*Казан шәһәре ГБМБУ «43 нче мәктәп»*
*Туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

Каюм Насыйри – татар халкының күренекле мәгърифәтчесе, галим, язучы, педагог. Ул бөтен гомерен мәгърифәтчелек эшенә багышлый, татар әдәби телен үстерә, тарихта беренче булып татар балаларына рус телен өйрәтүгә керешә һәм, барлык киртәләргә карамастан, үз эшен ахырына кадәр җиткерә.

Ярты гасырдан артык фәнни, әдәби һәм педагогик эшчәнлеге дәвамында әдәбият, фольклор, филология, педагогика, математика, тарих, география, астрономия һәм фәннең башка тармаклары буенча кырыкка якын хезмәт бастырган. Каюм Насыйри чын галим иде, ул үз Ватанын, үз халкын бик нык яратты һәм аның үсеше өчен күп эшләр башкарды.

Бөек педагог илнең уңышын һәм чәчәк атуын халкыбызның үзара аңлашуында һәм берберсенә карата шәфкатьле булуларында күрә. Кече һәм зур халыклар юк, барлык халыклар тигез һәм бердәм, һәрберсенең кабатланмас үзенчәлекле мәдәнияте бар. Һәркем аны якларга, сакларга һәм үз нәселенә тапшырырга тиеш. Тел, мәдәният юкка чыкса, шул вакытта халык та юкка чыгачак. К.Насыйри татар халкы тарихын өйрәнүгә зур өлеш кертә. Ул тарихи документлар җыя, халыкның фольклор әсәрләрен җыя, этнографиясен өйрәнә.

Милли киртәләрне җиңүдә, рус һәм татар халыклары арасында үзара аңлашуга ирешүдә К.Насыйриның рус публикасын татарларның тарихы, мәдәнияте һәм көнкүреш традицияләре белән таныштыру эшчәнлегенең дә әһәмияте зур. Аның фикеренчә, руслар арасында татарларның мәдәнияте һәм көнкүреш традицияләре турында әдәбият таралу, аларны татар халкының тарихи үткәне белән таныштыру, алар турында алдан ук ялгыш фикер йөртүне үзгәртүгә ярдәм итәчәк.

Аның хезмәтләрендә укыту һәм тәрбия проблемалары аерым урын алып тора. Бу проблемага аның «Тәрбия китабы», «Әхлак рисаләсе» (кебек әсәрләре багышланган.

«Тәрбия – туклануга һәм тән үсеше өчен шартлар тудыруга гына кайтып калмый, – дип яза ул. Алар белән беррәттән, ул балаларда характер формалашуны, аларның гамәлләрен төзәтүне дә үз эченә ала, димәк, кешене тәрбияләү физик тәрбия белән беррәттән рухи үсешне дә үз эченә ала. Өстәвенә, соңгысы, барыннан да элек, кешенең акылын, хәтерен һәм фикерләү сәләтләрен үстерүне, әйләнә-тирәдәге чынбарлык турында белемнәр алуны һәм үз-үзеңне танып белүне үз эченә ала.К.Насыйри фикеренчә, кешегә хезмәт күнекмәләре һәм һөнәрләргә өйрәтү тәрбиянең мөһим өлеше булып тора. Ул балалар өчен хезмәтнең тәрбияви әһәмиятен ассызыклый.

Аның фикеренчә, педагог шәхесе бик мөһим. «Һәр укытучы, һәр педагог, – үзен бөек эшкә башкаручы дип санарга тиеш». Ә моның өчен ул «энциклопедик белемгә ия булырга, фәннәрне яратырга, тәрбия нигезләрен тирәнтен белергә һәм мөстәкыйль рәвештә укыту методларын табарга сәләтле булырга тиеш».

Һәр бала, педагог фикеренчә, туган телен, мәдәниятен белергә һәм өйрәнергә, өлкән буын традицияләрен сакларга, үзенең туган йортын, зур һәм кече ватанын яратырга, күршеләрен хөрмәт итәргә тиеш. Галимнең шушы тирән фикерендә кешенең тәрбия идеалын аңлау ята.

Үгет-нәсыйхәтләр, гыйбрәтле хикәяләр туплаган зур булмаган «Тәрбия китабы» нда ул яшьләрне әхлакый тәрбияләүнең безнең заманда да актуаль булган күп кенә проблемаларын күтәрә. Мәсәлән, ул болай дип ассызыклаган: «тәрбияне баланы имезү һәм үстерү мәшәкате

дип аңларга ярамый, бу баланы туендыру да, аның әхлакый камилләшүе турында кайгырту да, күркәм гадәтләр тәрбияләү дә». К.Насыйри китабында 113 үгет-нәсыйхәт бар. «Тәрбия китабында» төп геройлар – ул пәйгамбәрләр, акыл ияләре һәм гади кешеләр. Акыл ияләре һәм гади кешеләр тормышыннан мисаллар белән автор вакыйгаларны тасвирлый, ә аннары нәтиҗәләр ясый, укучыны әхлакый үгет-нәсыйхәтләр рәвешендә түгел, ә тормыш проблемасы, гади киңәш, киләчәккә үз-үзеңне тоту стратегиясе рәвешендә бәян ителгән әхлакый үгет-нәсихәтләргә китерә. Авторның укучыга мөрәҗәгате «и улым!», «Балаларым!» үзләрендә гаять зур гуманистик мәгънә йөртәләр. Автор үзен югары күтәрми, ә тигез дәрәҗәдә әңгәмә алып бара, укучыга каршы килә, аңа ярдәм кулы суза, киңәш бирә, проблемаларны хәл итәргә ярдәм итә, куркыныч турында кисәтә. Бу хезмәтнең өстенлеге шунда ки, һәр гыйбрәтле хикәягә авторның үз шәрехләрен бирүе. К.Насыйри кеше сәламәтлеген саклау проблемасына, аның туклану культурасына аерым игътибар бирә. Моңа да үгет-нәсихәтләр багышланган.

К.Насыйриның татар әдәбияты тарихындагы күренекле ролен раслаучы төп фактор-ул үз әсәрләрен киң массаларга аңлаешлы телдә беренчеләрдән булып яза башлавы һәм татар телен гарәп һәм фарсы телләре басымыннан азат итәргә тырышуы.

Каюм Насыйри татар әдәбияты тарихына берничә әдәби әсәр авторы буларак кереп кала. Аның әдәби мирасында кыска хикәяләр, новеллалар һәм шигырьләр бар. Оригиналь әсәрләр иҗат итү белән беррәттән, ул гарәп, фарсы һәм төрек телләрендә басылган иң яхшы повестьлар, хикәя һәм новеллаларны сайлап ала һәм аларны татарчага тәрҗемә итү буенча зур эш башкара. Әдәби иҗатында ул татар фольклорына да киң таяна.

К.Насыйри тәрҗемә олкәсендә дә бик хезмәтләр яза. 1868 елда «Кырык вәзир кыйссасы», «Мең дә бер кичә», 1872 елда үзенең атаклы «Әбугалисина кыйссасы», 1886 елда «Кабуснамә» әсәрләрен тәрҗемә итә һәм бастырып чыгара. Әлеге кыйссаларда кешелеклелек һәм гаделлек, хаким белән аның халкы арасындагы мөнәсәбәтләр, яхшылык һәм яманлык, йөрәк белән акыл арасындагы әхлакый сайлау мәсьәләләрен күтәрә.

К.Насыйри үзенең төп дөньяга карашларын «Фәвакиһел җөласа фил әдәбият» (әңгәмәдәшләрнең җимешләре) китабында бәян итә, аның кыскартылган варианты «Кырык бакча» (Кырык бакча) исеме белән билгеле. К.Насыйри төзегән, үгет-нәсыйхәтләр җыентыгы, күп буыннар өчен тормыш дәреслеге булган хезмәт әлегә кадәр тулы күләмдә басылмаган булып кала бирә. Үзенең структурасы һәм эчтәлеге буенча «Фәвакиһел җөласа фил әдәбият» бик кызыклы. Ул 40 бүлектән тора. Автор һәр бүлекне рауза (бакча) дип атый. К.Насыйри уйлавынча, китап бик матур җимеш бирүче бакча булып күренә. Бу бакчаларда (бүлекләрдә) кешегә хас сыйфатлар, аның гамәлләре, төрле күренешләр турында бәян ителә. Автор аларны бакчада үскән агачларның җимешләре дип атый. Китапта Каюм Насыйри, халыкны бәхетле итүне, аны мәгърифәтләндерүдә күрә. Насыйри белемне кешелекнең иң зур байлыгы дип бәяли.

Татар теле һәм тарихы буенча хезмәтләре белән К.Насыйри үз халкына тарихи үткәнне һәм мәдәни мирасны аңлауда сизелерлек ярдәм күрсәтә. Әдәби әсәрләре һәм әдәбият белеме буенча хезмәтләре белән ул хәзерге татар әдәбиятының нигезен булдыруга бәяләп бетергесез өлеш кертә. Аның фәнни һәм әдәби мирасы татар мәдәнияте тарихында лаеклы урын алып тора.

Бөтен гомерен, акылын һәм талантын ул үз халкына хезмәт итүгә багышлаган. Бүген Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы тарафыннан К.Насыйри исемендәге премия булдырылды, ул премия белән татар халкының һәм Россиянең язмышына битараф булмаган иң яхшы педагогик коллективлар, укытучылар, тәрбиячеләр, татар теле дәреслекләре авторлары бүләкләнә. Казанда Каюм Насыйриның музей-йорты ачылган, анда Россиянең барлык почмакларыннан укытучылар һәм мәктәп укучылары килә, алар монда бик көтеп алынган кунаклар. Аның барлык әсәрләре бүгенге көндә дә актуаль.

## ИСПОЛЬЗОВАНИЕ ПЕДАГОГИЧЕСКИХ ИДЕЙ ТАТАРСКОГО ПРОСВЕТИТЕЛЯ КАЮМА НАСЫРИ В ФОРМИРОВАНИИ ЕСТЕСТВЕННО-НАУЧНОЙ ГРАМОТНОСТИ СОВРЕМЕННЫХ ШКОЛЬНИКОВ НА УРОКАХ ФИЗИКИ

**Волкова Анна Анатольевна**
*ГБОУ «Васильевская КШИ им. Героя Советского Союза Н. Волостнова»*
*Учитель физики первой квалификационной категории*

Педагоги-просветители оставили богатейшее педагогическое и методическое наследие, которое еще не изучено в достаточной мере и не полностью стало достоянием широкой общественности. Актуальность данного исследования состоит в том, что особо важную роль в развитии личности человека играют педагогические ценности предшествующих поколений. Изучение наследия педагогов – просветителей раскрывает его огромное воспитательное значение для нас – потомков.

В своем исследовании я рассматриваю педагогические идеи татарского педагога, просветителя Каюма Насыри.

Цель исследования состоит в том, чтобы проанализировать и обобщить педагогические взгляды Каюма Насыри, выявить те рекомендации из его наследия, которые необходимы для формирования естественно-научной грамотности современных школьников.

Работы Каюма Насыри могут быть полезны при применении на уроках физики благодаря следующим идеям и рекомендациям:

- Связь теории с практикой;
- Последовательность и системность обучения;
- Наглядность обучения;
- Сознательное усвоение знаний;
- Сочетание обучения с физическим трудом.

Основные научно-теоретические принципы оптимизации содержания и методики преподавания гуманитарных дисциплин, разработанные К.Насыри, не потеряли значения и в настоящее время. Учителям нашего времени несомненно помогают педагогические работы Каюма Насыри в работе с учащимися.

## КАЮМ НАСЫЙРИ: ШӘХЕС, ГАЛИМ, ОСТАЗ

**Гыйзәтуллина Гөлинә Шамил кызы**
*Казан шәһәре Авиатөзелеш районның «Татар телендә белем һәм тәрбия бирүче катнаш төрдәге 366-нчы балалар бакчасы»*
*Татар теле тәрбиячесе*

Педагогик укуларның темаларын сайлаганда бу тема нишләптер бик якын һәм мавыктыргыч булып тоелды. Билгеле, мин күренекле галимә дә түгел, хезмәтем дә фән белән бәйләнмәгән. Шулай да, мәгърифәтче, галимнең исеме кечкенәдән таныш булганга К.Наыйри турындагы белемнәрне тирәнәйтергә уйладым. Шул нәүбәттән яңадан язучы турындагы истәлекләр белән таныштым. Туган авылындагы музейга сәяхәт оештырдым. К.Насыйри туган Шырдан авылында элек тә булганым, ул яратып ашаган катыктан авыз иткәнем бар иде. Ә музейда булгач галим әле генә шушы йортта яшәп, вакытлыча каядыр чыгып кына торган сыман тоелды миңа. Элек татар дөньясында күренекле урын тоткан, яңалыкка омтылучы, рус телен камил белгән, үз иленең патриоты нинди

җирлектә яшәгән шуны ачыклыйсым килеп бардым мин анда. Үз–үземә: «К. Насыйри шәхесе нинди тамырлардан формалашкан?» – дигән сорауны куйдым. Шушы җирлектә булып, тел-әдәбият галимнәренең мәкаләләре белән танышкач түбәндәге фикергә килдем. К.Насыйриның шәхес булып формалашуына нәселенең белемле, тырыш, үҗәт, алдынгы карашлы, кеше арасында сүзләре үтүләре дә йогынты ясагандыр дигән фикергә килдем. Бабасының әтисенең, рус телен белүләре, русларда ул вакытта билгеле түрәләр белән таныш булулары киләчәкне күздә тотып яшәгәннәрдер дигән уй биләде. Олы абыйсының Мәскәүдә сабын заводы тотуын, элек алар яшәгән урында хәзер кое булуы турында да яңа белдем. Әтисе хәллерәк тормышта яшәмәсә, Каюмны да Казанга җибәреп укыта алмаган булыр иде. Нәселенең белемле, кызыксынучан булуы, үзенең тырышлыгы, үҗәтлеге аны бергә укыган шәкертләрдән аерып торган. Чөнки, бу чорда ул үзлегеннән күп укыган.

Икенче кызыксынган сорау К.Насыйрины ни өчен галим дип таныйбыз? Галим дип атарга нинди нигез бар? Бу сорауга җавапны без аның хезмәтләреннән күрәбез. Духовная семинариядә эшләгәндә, үзе рмәктәпләр оештырып балаларны рус телендә укытканда татар телен рус теле белән чагыштыып, грамматикадагы якынлык һәм аермаларны күзәтеп укыта. Шулардан чыгып теоретик хезмәтләр дә калдыра. Татар теленең аңлатмалы, русча-татарча, татарча-русча сүзлекләр төзи. Татар теленең урам теле булып калмыйча, фән теле була алуын, шуңа сәләтле булуын дәлилли. К.Насыйри саллы хезмәтләрен балаларга да багышланган. Баланың зиһенен үстерү һәм әхлагын тәрбияләүне кечкенәдән башларга дигән фикерне дә ул әйтә. Язучының «Буш вакыт», «Әхлак рисаләсе», «Тәрбия китабы», «Әдәбият турындагы мәҗлесләрнең җимеше» җыентыклары шушы теманы яктырталар. Аның әсәрләре афоризмга торырлык хикмәтле сүзләр, акыллы сабак бирүләре, тапкырлык мисалы булып торалар. Китапларга иллюстрацияләр, рәсемнәр белән бизәү дә К.Насыйридан башлана. К.Насыйриның заманчалыгы музыкага мәхәббәтеннән дә күренә. Ул сәнгатьнең һәр өлкәсендә дә азмы-күпме белемле була. Графика алымы белән карталар сыза. Китапларын үзе төпләп сата, слесарьлык эшен дә белгән, зәркән эшенә дә хирыс булган. Дару үләннәрен җыеп дарулар да ясаган. Математика, география, минералогия, табигать белеме фәннәренә багышланган хезмәтләре дә бар. Гүя бөтен нәрсәгә дә өлгереп калырга тырыша ул. Тәрҗемә эше белән дә шөгыльләнә. Мондый күпкырлы хезмәтләр язган, киң мәгълуматлы кеше буларак ничек аны галим димисең иде?

Ә ни өчен К.Насыйрины остаз дибез? Галимнәр аның хезмәтләреннән, киңәшләреннән файдаланалар. Укытучылар, тәрбиячеләр өчен аның әдәби әсәрләре бик мөһим. Ә тәрбия турындагы китаплары өстәл китабына әйләнделәр. Мөгаллим нинди мөһим сыйфатларга ия булырга тиешлекне дә әйтеп калдырган ул. Үзем балаларга аның канатлы сүзләре даим рәвештә үрнәк итеп алам.

Сүземне йомгаклап, гасырлар үтсә дә К.Насыйри калдырган хезмәтләр бәясен югалтмыйча, татар дөньясында тоткан урынын, бөеклеген раслап торалар диясе килә. Язмага әзерләгәндә үземә күп төрле мәгълумат һәм белем тупладым.

## КАЮМ НАСЫЙРИ – БӨЕК ШӘХЕС

**Гирфанова Зилара Рафаиловна**
*Казан шәһәре МАГБУ «146 нчы «Ресурс» лицее»*
*Югары категорияле туган тел*
*һәм әдәбияты укытучысы*

**Кереш**

Бөтен гомере буе халыкка фидакарьләрчә хезмәт кылган, милләт мәнфәгатен үзенең яшәү кыйбласы иткән татар галимнәре һәм әдипләре шактый күп: Утыз Имәни, Габдулла Тукай, Шиһабетдин Мәрҗани, Риза Фәхреддин, Гаяз Исхакый… Болар арасында иң мөхтәрәм урыннарның берсен Каюм Насыйри алып тора.

1860 елдан башлап ярты гасыр дәвамында гаять нәтиҗәле эшчәнлек күрсәткән Каюм Насыйри татар мәгърифәтчелегенең күренекле вәкиле була. К.Насыйриның кыю фикерләре, әдәби, фәнни хезмәтләре үз чорында җитәрлек бәяләнмәгән. Әмма алар халыкның киләчәгенә нык ышанган патриот әдипне мәгърифәт эшеннән туктата алмаганнар. Ул әдәби, фәнни, педагогик хезмәтләрендә Россиягә, рус халкына мәхәббәтен, аның киләчәгенә зур өметләр баглавын күрсәтә. Башында К. Насыйри торган һәм татарлар арасында мәгърифәтчелек хәрәкәте дип исемләнергә хаклы булган хәрәкәт, халык мәнфәгатьләре белән нык бәйләнеп, үзенә үрнәкне рус мәгърифәтчеләреннән ала. Бөтен гомерен безнең халкыбызны агартып, аңа культура хезмәте, әдәби хезмәт күрсәтүгә багышлаган өлкән агабыз – бөек рус халкы ярдәмендә татар халкының да бәхетле тормышка ирешүенә чын күңелдән ышанган, татар балаларын, беренче буларак, русча укыту эшенә җиң сызганып керешеп, кагылу– сүгелүләргә, эзәрлекләүләргә карамастан, армый – талмый эшләгән К. Насыйриның хезмәтләре зур игътибар белән өйрәнелә, хөрмәт белән искә алына. Аның Ватанга мәхәббәт, халыклар арасындагы дуслык турында әйтелгән гади сүзләре бүген, тагын да тирәнрәк мәгънә алып, яңача яңгырый.

Эшебезнең максаты – олуг шәхес Каюм Насыйриның мәгърифәт өлкәсендәге эшчәнлеген өйрәнү. Әлеге максатка ирешү өчен түбәндәге бурычлар куелды:

1) галимнең педагогик эшчәнлеген өйрәнү;
2) тел, тарих, фольклор өлкәсендәге хезмәтләрен барлау һәм тикшерү;
3) язучының әдәби иҗатын өйрәнү.

Хезмәтебез Кереш, Төп һәм Йомгак өлешләрдән тора. Төп өлеш бүлекчәләрдән гыйбарәт. Соңыннан файдаланылган әдәбият исемлеге күрсәтелде.

**Төп өлеш: Каюм Насыйри – бөек шәхес**

**1. К. Насыйри – педагог һәм тел белемен үстерүгә искиткеч зур өлеш керткән галим**

К. Насыйри – тел белемен үстерүгә искиткеч зур өлеш керткән галим. Ул Шиһабетдин. Мәржани, Габдрахман.Ильяси кебек укымышлылар белән Казан университеты каршындагы Археология, тарих, этнография, җәмгыяте утырышына йөри, докладлар ясый, дәреслекләр, китаплар яза, гаризалар язып бирә, тәрҗемә итә, китаплар сата. Ул сүзлекләр төзи. Математика, география, табигать фәннәре буенча татарча терминнар сүзлеге – безгә олуг галим калдырган мирас. Татар теленең беренче фәнни грамматикасы да аның хезмәте.

Каюмның балалык вакытлары, заманы өчен, шундый мәдәниятле гаиләдә, туган авылында уза. Башлангыч белемне ул атасыннан ала. 1841 елда Каюмны Казандагы бер мәдрәсәгә укырга бирәләр. 1855 елга кадәр ул мәдрәсәдә укып, гарәп-фарсы телләрен өйрәнү өстенә, үзлегеннән татар телен дә яхшы үзләштерә. Яшерен рәвештә русча да укый.

1855 елда Насыйрины Духовное училище дип аталган мәктәбенә татар теле укытучысы итеп чакыралар. Насыйриның беренче практик эше – укытучылык хезмәте шунда башлана. Соңыннан ул Духовная семинариядә татар теле укытучысы булып эшли. Анда укытучылар белән таныша, алар белән якыннан аралаша, алардан рус телен һәм башка фәннәрне тырышып өйрәнүен дәвам иттерә.

Аннары ул, Казан университетына ирекле тыңлаучы булып йөреп, югары белем ала. Насыйриның университетта укуының әһәмияте турында Петербург университеты профессоры В. Григорьев: «Казан университетында алган гыйлеме Каюм Насыйрины исламга объектив карарлык югары дәрәҗәгә меңгерде. Ул – бу яктан безнең Россия мөселманнары арасында беренче кеше», – дип бәяләп уза.

Каюм Насыйри үз чоры өчен укымышлылыгы ягыннан иң югары баскычка күтәрелеп, татарлар арасында иң беренчеләрдән булып энциклопедик галим дәрәҗәсенә ирешә. Ул татар балаларына рус теле укытуга зур игътибар бирә. Аның семинариядә укыту эше 1870 елга кадәр, 15 еллар буенча, бара. 1871 елда Насыйри, семинариядә эшләүдән туктап, татар балаларына рус теле укытуга ныклап керешә. Бу әһәмиятле эшенең башлануы һәм нинди шартларда баруы

турында Насыйри үзенең истәлек рәвешендә язган очеркында: «Мин, мин дип мактану, эшең хак булса, урынына күрә ярый. Казан шәһәрен дә мөселман балалары русча укый торган мәдрәсәнең ибтидасы… ушбу мөгаллимнәндер. Асыл бу мәдрәсәнең ибтидасы 1871 елда булды», – ди. Монда мөгаллим дип Каюм Насыйри үзен атый.

Каюм Насыйрига бу эшне алып бару җиңел булмый. Укыту өчен урын – квартира табу, балаларны укуга тарту буенча күп тырышлыклар күрсәтергә, төрле җәфалар чигәргә туры килә.

Каюм Насыйри үзенең гыйльми эшчәнлеген мәдрәсәдә уку елларында ук башлап җибәрә. Аның узе исән вакытта ук татар һәм рус телләрендә төрле зурлыктагы 40 лап китабы дөнья курә.

Ул уку китаплары һәм дәреслекләр язган:

1. «Нәһү китабы» (татар теле синтаксисы). Русча төзелгән. Бу татар телен өйрәнүче руслар өчен.
2. «Буш вакыт Анатомия, табигать белеменнән кыскача мәгълуматлар белән таныштыра.
3. «Һавагыйде китабы» (язу кагыйдәләре).
4. «Мәҗмәгыль әхбар».
5. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге («Ләһҗәи татари Бу – татар теленең фәнни грамматикасына нигез салучы икәнлеген күрсәтә).
6. Элек гарәпчә булганнары урынына Каюм Насыйри керткән терминнар: сан, бүлү, калдык. «Кыйрәте рус», «Нәмүнә яки Әнмүзәҗ» (рус теле грамматикасы, русча-татарча сузлекләр).

Ул татар теленең әдәбият һәм фән теле була алуын һәм шуңа хаклы икәнлеген дә исбат итә. Каюм Насыйри татар теле гыйлемен үстерүдә һәм сүзлекләр төзүдә әһәмиятле эшләр башкара. Татар теленең анлатмалы сүзлеген төзи, русча-татарча, татарча-русча сүзлекләр бастырып чыгара. Математика, география, грамматика фәннәреннән киң катламга аңлаешлы терминнар булдыру өчен тырыша. Татар теленең фәнни-терминологик эшенә күп хезмәт куя. Ул татар теленең үз җирлегенә нигезләнгән терминнарны булдыру белән беррәттән, халыкара гомуми терминнарны русча кулланылганча алу ягында була. Телебездә булган бәетләр, шигырьләр, мәкальләр, табышмаклар, башваткычлар гаять төзек ритмлы һәм рифмалы итеп төзелгәннәр; мәгънәне тулы һәм матур бирүдә башка телләрдән һич тә ким тугел. Каюм Насыйри: «Без – татарлар, телебез – татар теле, мөстәкыйль һәм төзек кагыйдәле камил тел ул!» дигән.

**2. Каюм Насыйри – фольклорчы**

Каюм Насыйри – фольклорчы, чөнки борынгы кабер ташларындагы язуларны укый, авыл тарихларын язып ала, гореф-гадәтләрен йолаларын өйрәнә, җырлар, бәетләр, әкиятләр җыя. Тарихның Болгар тарихына бәйле булуын ачыклый.

Үз милләте өчен янып-көйгән Каюм Насыйри гомере буе халык авыз иҗаты әсәрләрен туплау, гыйльми өйрәнү һәм халкына җиткерү белән шөгыльләнә. Ул халык авыз иҗаты белән яшьтән үк кызыксына, аны җыя, фәнни эшкәртеп, рус һәм татар телләрендә бастырып чыгара. Үзенең календарь һәм сүзлекләрендә, дәреслек һәм башка төр хезмәтләрендә фольклор әсәрләренә шактый күп урын бирә.

Каюм Насыйри татар халык иҗатының күп жанрларын өйрәнеп, шуларны бастырып чыгару буенча зур эш алып бара. Петербург галимнәреннән халык иҗаты материалларын җыю турында киңәшләр ала. Нәтиҗәдә «Казан татарларының ышанулары һәм ырымнары» дип аталган бер хезмәте 1880 елда Петербургта рус телендә дә басылып чыга. Рус галимнәре бу әсәрне хуплап каршы алалар. Шул хезмәткә язган сүз башында Петербург университеты профессоры Григорьев Каюм Насыйри эшчәнлегенә югары бәя бирә.

1880 елдан башлап Каюм Насыйри татар халык авыз иҗатының төп жанрларыннан булган җырлар, мәкаль, әйтем һәм бәетләрне бастырып чыгару эшенә керешә. Аларны күпсанлы җыентыкларына туплап, татар һәм рус телләрендә бастырып чыгара. «Фәвакиһел җөләса филәдәбият» (1884), «Поверья и обряды казанских татар» (1880), «Образцы народной литературы казанских татар» (1886), «Сказки казанских татар» һәм башка китапларында күпләгән халык җәүһәрләре тупланган.

Каюм Насыйри фольклор әсәрләрен җыеп кына калмый, ә аларны төрләргә һәм жанрларга аерып бирә, аларга хас аерым үзенчәлекләрне күрсәтә. Татар халкының искиткеч акыллы, тапкыр булуына соклана. Ул мәкальләр, әйтемнәр, табышмаклар, читләтеп әйтелгән сүзләр, җырлар, бәетләр, такмаклар, әкиятләр, халык тәҗрибәләре (сынамышлар) жанрларын аерып алып өйрәнә. Аларның төрле вариантларын язып ала. Халык шагыйре Габдулла Тукай иҗат иткән «Шүрәле» поэмасы да Каюм Насыйри язып алган вариант нигезендә иҗат ителгән икән.

Каюм Насыйри халыктагы фольклор әсәрләрен туплап, халыкның үзенә кабат җиткерде. Моның белән ул халыкның рухи хәтере бай һәм озак яшәячәген тагын бер кат раслады. Ул – татар фольклористика фәненә нигез салучыларның берсе, һәм галим туплаган халык җәүһәрләре әдәбиятны, телебезне үстерүдә бетмәс– төкәнмәс чыганак булып кала бирә.

Каюм Насыйриның фольклор өлкәсендәге эшчәнлегенә үзе исән вакытта ук югары бәя бирәләр.

**4. Каюм Насыйри – физик хезмәт иясе**

Каюм Насыйри бөтен тормышын иҗат эшенә, гыйльми эшкә буйсындырган. Күп вакытта, утырып эшләүнең, көннәр-төннәр буена язу өстендә утыруның кешене ялыктыруын искә алып, Каюм Насыйри ял вакытларында физик хезмәт белән дә шөгыльләнә торган булган. Кул һөнәрләре, физик эш куллануы аңа тормышындагы бертөрлелектән котылырга да ярдәм иткән.

Аның кул эшләре белән шөгыльләнүе күп төрле һөнәрләр белү характерында була. Ул китап төпләү, күзге ясау, крахмал, суыргыч, лак, кара хәзерләү, электричество ярдәмендә әйберләр көмешләү һәм слесарьлык эшләрен дә яхшы белгән. Төрле ашлар хәзерләүдә дә осталыгы булган. Ул бу һөнәрләрнең теориясен китаплардан укып һәм үзенең тәҗрибәсендә сынап карап өйрәнә. Башкаларга да өйрәтү теләге белән, шул темаларга карата китаплар да яза. Ул бу һөнәрләрен үзенең практик кирәкләренә файдалана: китапларын үзе төпли, үзе өчен кирәк булган нәрсәләрнең барысын да үзе ясый. Аның физик эшләрдән иң яратканы агач эше булып, ул бу эшне ахыр гомеренә кадәр һәрвакыт һәм системалы рәвештә алып бара. Ул: «һаман утырып язу ялыктыра, каннар оеша, мин, һәр көн бер-ике сәгать эшләп, бу кораллар белән үземә кирәкле әйберләрне ясыйм», – дип әйтә торган булган.

Каюм Насыйри катлаулы һәм нечкәрәк һөнәрләрдән карта сызу, рәсем төшерү кебек эшләргә дә сәләтле була. Ул үз гомерендә төрле карталар сызып, аларны үзе чыгарып килгән календарьларында урнаштыра бара: 1878 ел өчен чыккан календаренда җир шарының көнчыгыш яртысының картасын, 1879 елда Россиянең Европа өлеше картасын һәм 1881 ел календаренда Казан губерниясенең бөтен авылларын күрсәткән картасын эшләп бастырган. Каюм Насыйриның рәсем төшерүе, төрле чәчәк һәм бизәкләр ясавы, бигрәк тә сызып ясаган кайбер эшләре аеруча игътибарга лаек булып торалар.

**5. Каюм Насыйри һәм халык медицинасы**

Халык медицинасына уңай мөнәсәбәттә була: төрле үләннәр белән дәваланган, физик хезмәт белән шөгыльләнгән. Ятып авырмаган. Гомеренең соңгы елларында аякларын жиңелчә паралич суга. Үзен-үзе электр белән дәвалый, аяклары языла, йөрерлек хәлгә килә. Каюм Насыйри дәвалану өчен төрле үләннәрдән чәй пешерү рецептлары кулланган икәне билгеле. Казанда Каюм Насыйри музеенда булган чакта без бу турыда экскурсовод ападан сораган идек, ләкин апа кеше серне ачмады. Безнең авылыбызда да төрле үлән пешерү рецептлары бар. Бәлки, аларның кайсы да булса Каюм Насыйри рецепларыннан безгә килеп җиткәндер.

Астма чире белән интегүчеләргә ул түбәндәге рецептны тәкъдим итә: «Үги-ана яфрагы, кычыткан, каен яфрагы, тырнаклы гөл чәчәге, сабагы-яфрагы белән бергә дару ромашкасы һәм бака яфрагы (бертигез алына) Хәзер шуларны термоска тутырып кайнар су агызыгыз, каплап куегыз. Өч сәгать торкач, марля аша сөзеп, алыгыз да салкын урынга куегыз. Көненә өч тапкыр яртышар стакан эчегез. Сәламәт булыгыз!»

Шулай ук Каюм Насыйри игенчелек, ботаника, аш-су әзерләү буенча китаплар чыгара, үзе сызган карталарын календаренда бастыра.

**6. Каюм Насыйри – тарихчы**

Тарих фәне буенча төрле мәкаләләре, махсус китаплары бар. Казан тарихы хакындагы язмалары кызыклы. Шулай ук куп кенә татар авылларының тарихы хакында да мәкаләләр яза. Ул буш вакытында халык телендәге материалларны, каберташ язмаларын, төрле шәҗәрәләрне, кулъязма һәм басма китапларны ныкпып өйрәнә. К.Насыйри тарихи хезмәтләрендә төп игътибарын татар тарихына мөнәсәбәтле материалларны туплауга һәм өйрәнүгә юнәлтә. Бу яктан аның Казан тарихы хакындагы язмалары аеруча кызыклы. Мәсәлән, бер риваятендә ул XVI йөзнең беренче яртыларында яшәгән Шаһгали ханның, Мәскәүгә сатылып, Казан мәмләкәтенә, үз халкына хыянәт итүче, ахыр чиктә татарларның, дәүләтчелектән мәхрүм ителеп, коллыкка төшүе турында яза. Каюм Насыйриның Пугачев хакындагы риваятьләре дә тел стиленең үтемлелеге, факт-мәгълүматларга байлыгы белән сыйфатлана.

Тарихка караган хезмәтеннән Зөя каласының алынуы.

Элгәре Зөя каласы урынында җимеш, йөзем, алмагач бакчасы булган. Иван Васильевич килеп шул урынга кала сала башлагач күрде: Казан ерак түгел; ихтимал, Казан ханы бу эшне сизеп, эшебезне туктатыр дип, әмер кылды: кала салганда, Казан ханы күрмәсен дип, Казан ягына чаршау кордылар. Бу хәйләнең файдасы озакка бармады. Казан ханы манара башыннан подзорный труба белән карап күрде: Зөя тавындагы бакчасында бер төрле галәмәт бар. Инде моны Казан ханы белсә дә, ни вакыйгалар булгандыр, һәрничек Зөя каласы – чаршау арты каласы – бар да бер, каланы салып тәмам иткәннәрдер.

**Йомгак. Каюм Насыйри эшчәнлегенең әһәмияте**

Күргәнебезчә, К. Насыйриның мәгърифәтчелек эшчәнлеге күпкырлы. Аның хезмәтләре татар халкын белемле, тәрбияле итүдә үзенә күрә бер мәктәп, университет булырлык. Татарны татар итеп танытуда, аның милли үзаңын, рухи хәтерен үстерүдә Каюм бабаның эшчәнлеге искиткеч зур. Ул шәрык, рус, Европа казанышларын һәм тәҗрибәсен күрә, алардан иҗади файдалануның матур үрнәкләрен бирә. Әмма К. Насыйри өчен барыннан да элек татарның үз җирлегендә, үзенең рухи мирасына таянып үсүе кыйммәт һәм шуңа күрә дә ул төп игътибарын татарның телен, тарихын, гореф-гадәтләрен, сүз сәнгатен өйрәтүгә юнәлтә, таралып, сибелеп яткан күп кенә хәзинәләрне замандашларына һәм киләчәк буын укучыларына җиткерүгә ирешә.

«Бармыни бездә гомумән чын кеше кадерен белү?! Без аны кайдин белик, мискин үлеп аңламагач?!» Тукайның бу юллары Хөсәен Ямашев үлеме уңае белән язылган, әмма аларны Каюм бабага карата да кулланырга мөмкин. Чөнки ул, ярты гасырдан артык, ат кебек эшләсә дә, үзе исән вакытта кадер – хөрмәт тә, юньле тормыш та күрмәгән. Әмма аның иҗат мирасы еллар узган саен кыйммәтен арттыра бара. «Олуг мөгаллим» хакында төрле телләрдә күп санлы мәкалә-хезмәтләр язылуы, китапларның кат-кат басылуы ачык билгесе. К. Насыйри шәхесе әдәби әсәрләрдә дә гәүдәләнеш токкан. Аның хакында М. Галинең документаль повесте һәм шушы ук авторның Х.Уразиков белән берлектә язган «Каюм Насыйри» дигән тарихи пьесасы да бар.

Каюм бабаның эшчәнлеге – милләткә фидакарьләрчә хәзмәт итүнең бөек үрнәге. Аның китаплары – хәзерге милли тормышыбыз өчен дә аваздаш булган бай хәзинә.

**Кулланылган әдәбият:**


1. Каюм Насыйри. Әсәрләр. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1971–142 б.
2. Каюм Насыйри. Әбүгалисина. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1975–63 б.
3. Каюм Насыйри. Сайланма әсәрләр. Таткнигоиздат, 1956–417 б.
4. Каюм Насыйри. Сайланма әсәрләр. 4 томда, 1 том. – Казан: Татар. кит. нәшрияты, 2003–368 б.
5. Татар әдәбияты тарихы. 6 томда, 2 том. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1985–73 б.
6. Әдәбият, 9 класс. Казан, «Мәгариф» 1994 Х. Миңнегулов, Ш. Садретдинов

# КАЮМ НАСЫЙРИ – КИҢКЫРЛЫ ШӘХЕС

**Закирова Гөлназ Нурулла кызы**
*Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Катнаш төрдәге Балтач 5 нче балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, өлкән тәрбияче*

Каюм Насыйри – татар мәдәнияте һәм фәне тарихында күренекле шәхес. Ул мәгърифәтче, галим – этнограф, язучы, педагог һәм җәмәгать эшлеклесе була. Менә аның тормышының һәм эшчәнлегенең төп аспектлары да шушы.

Шәхес:

Мәгърифәтче һәм гуманист: Каюм Насыйри гомере буе татар халкын белемле итүгә омтылган. Ул белемнең тормышны яхшырту көченә ия дип ышанган.

Энциклопедист: тарих һәм географиядән алып, астрономиядән медицинага кадәр төрле өлкәләрдә энциклопедик белемгә ия булган. Бу аңа комплекслы һәм күпкырлы хезмәтләр тудырырга мөмкинлек бирә.

Ватанпәрвәр: үз халкын һәм мәдәниятен яраткан, гомерен татар халык йолаларын, телен һәм тарихын өйрәнүгә һәм саклауга багышлаган.

Тыйнак һәм хезмәт сөючән: тыйнак яшәү рәвеше алып баруы һәм армый-талмый хезмәт итү белән билгеле. Ул үз эшенә нык бирелгән булган һәм гомеренең соңгы көннәренә кадәр үзенең тикшеренүләре һәм дәреслекләре өстендә эшләгән.

Илһамландыручы: аның идеяләре һәм хезмәтләре киләчәк буын татар мәгърифәтчеләре һәм галимнәренә зур йогынты ясады. Ул татар халкы өчен мәгърифәтчелек һәм прогресс символына әверелде.

Галим:

– Этнограф: татар халкы турында гаять зур этнографик материал туплаган һәм системага салган: гореф-гадәтләр, йолалар, фольклор, халык белемнәре. Аның хезмәтләре XIX гасыр татарларының тормышы һәм мәдәнияте турында кыйммәтле мәгълүмат чыганагы булып тора.

– Тел белгече: татар телен өйрәнгән, сүзлекләр һәм грамматика төзегән. Ул татар әдәби телен үстерүгә һәм стандартлаштыруга омтылган.

Тарихчы: Татар халкы тарихын өйрәнгән, тарихи очерклар һәм тикшеренү эшләре язган.

Географ һәм астроном: география һәм астрономия фәннәре белән кызыксынган һәм шул юнәлештә фәнни-популяр мәкаләләр һәм дәреслекләр язган.

Фольклор җыючы: К.Насыйри татар фольклоры үрнәкләрен: әкиятләр, риваятьләр, мәкальләр, җырларны җыйган һәм бастырып чыгарган.

Остаз:

– Педагог-новатор: күрсәтмәлелек һәм тормыш чынбарлыгы принципларына нигезләнеп укытуның яңа методларын уйлап тапкан. Ул укыту укучылар өчен кызыклы һәм файдалы булырга тиеш дип санаган.

– Дәреслекләр авторы: татар телендә төрле фәннәр буенча бик күп дәреслекләр язган, бу исә татарлар арасында белем таралуга этәргеч булган. Аның дәреслекләре һәркем файдалана алырлык һәм гамәли юнәлешле булуы белән аерылып торган.

– Мәктәпкә нигез салучы: үз мәктәбен ачкан, анда балаларны үз методикасы буенча укыткан.

– Укучыларны илһамландыручы: үзенең үрнәгендә һәм идеяләре белән укучыларны белемгә һәм үз халкына хезмәт итүгә омтылырга рухландырган. Ул бер төркем күренекле татар мәгърифәтчеләрен һәм галимнәрен тәрбияләп үстергән.

Мәдәнияткә һәм фәнгә керткән өлеше:

– Татар теле һәм әдәбияты үсеше: аның хезмәтләре татар әдәби теле һәм милли әдәбияты үсешенә ярдәм иткән.

– Татар мәдәниятен саклау: аның этнографик тикшеренүләре татар мәдәнияте һәм традицияләре турында кыйммәтле мәгълүматларны сакларга һәм киләчәк буыннарга тапшырырга ярдәм иткән.

Белем таралу: аның дәреслекләре һәм педагогик эшчәнлеге татар халкын белемле итүгә ярдәм иткән.

Татар мәдәниятен фәнни өйрәнү: аның хезмәтләре татар мәдәниятен һәм тарихын фәнни өйрәнү өчен нигез салды.

Каюм Насыйриның тормышы һәм эшчәнлеге үз халкына тугрылыклы хезмәт итү һәм прогресска омтылу үрнәге булып тора. Аның мирасы кыйммәтле.

## КАЮМ НАСЫЙРИ – БӨЕК ШӘХЕС

**Зиннатуллина Гюзель Габдулхаевна**
*Муниципальное бюджетное образовательное учреждение*
*«Печищинская основная общеобразовательная школа»*
*Учитель родного (татарского) языка и литературы*

Галим, язучы, педагог Каюм Насыйри– татар мәгърифәтчеләренең күренекле вәкиле. Матур әдәбият, халык авыз иҗаты, филология, педагогика, математика, тарих, география, биология, астрономия һәм башка фәннәрдән 40 тан артык хезмзт иҗат иткән. Ул бөтен тормышын һәм талантын халыкка хезмәт итүгә, халкыбызның аң-белемен, мәдәниятен үстерүгә багышланган. Аның бүгенге мәгърифәтебез өчен зур әһәмияткә ия булган киң колачны хезмәтләре татар халкының иҗтимагый уяну тарихында мактаулы урын ала.Татар телен гыйльми калыпларга салуы, русча укытырга керешүе, кагылу, сүгелүләргә карамыйча, татар телен, фәнне үстерү эшендә армый-талмый эшләве К.Насыйрины фидакарь галим, энциклопедист-мәгърифәтче итеп танытты. Аның Ватанга мәхәббәт, халыклар арасында дуслык, туганлык турындагы зирәк сүзләре бүген тагын да тирәнрәк мәгънәгә ия.

Габделкаюм Габденнасыйр улы Насыйров 1825 елның 2(14) февралендә элекке Казан губернасы Зөя өязе Югары Ширдан авылында укымышлы мулла гаиләсендә туа. Башлангыч белемне әтисеннән ала. 1841–1855 елларда Казанның бишенче мәхәлләсендәге мәдрәсәдә укый. Бу мәдрәсәдә ул 1855 елга кадәр унбиш ел укый. Гарәп, фарсы телләрен өйрәнә. Аннан соң Духовное училищеда, соңрак шул училищеның дәвамы булган Духовное семинариядә татар теле укыта. Семинариядә ул 15 ел эшли. Соңыннан Казан университетына ирекле тыңлаучы булып керә.

1879 елдан башлап К.Насыйри рәсми рәвештә бер җирдә дә хезмәт итми. Бар гомерен язучылык эшенә, фәнгә багышлый. Һәр язны туган авылы Ширданга кайта, кыр эшләрендә катнаша, җәйләрен Зөя өязе авылларына чыгып, халыкның телен, гореф – гадәтләрен өйрәнә, тарихи истәлекләр, фольклор әсәрләрен җыя. Әдип бар көчен, сәләтен китаплар, дәреслекләр язуга сарыф итә, аларны үз акчасына бастыра. 1885 елда К.Насыйри Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте әгъзасы итеп сайлана. К. Насыйри сабак бирә торган предметларның берсе һәм мөһиме – тарих. Аның бу фән буенча төрле мәкаләләре, махсус китаплары бар. К.Насыйри тарихи хезмәтләрендә төп игътибарын татар тарихына мөнәсәбәтле материалларны туплауга һәм өйрәнүгә юнәлтә. Бу яктан аның Казан тарихы хакындагы язмалары аеруча кызыклы. Мәсәлән, бер риваятендә ул XVI йөзнең беренче яртыларында яшәгән Шаһгали ханның, Мәскәүгә сатылып, Казан мәмләкәтенә, үз халкына хыянәт итүе, ахыр чиктә татарларның, дәүләтчелектән мәхрүм ителеп, коллыкка төшүе хакында яза. К.Насыйриның Пугачев хакындагы риваятьләре дә тел-стиленең үтемлелеге, факт-мәгълүматларга байлыгы белән сыйфатлана.

К.Насыйри күбрәк Казанда яши. Берничә тапкыр агасы Габделхәй янына Мәскәүгә, Мәкәрҗә ярминкәсенә һәм имтихан тотар өчен Уфага барып кайта. 1893 елның җәендә Оренбург янындагы Каргалы авылында була.

К.Насыйри китапларын үзе төпләгән, көнкүреш әйберләре ясаган. «Һаман утырып язу ялыктыра, каннар оеше, мин һәр көн бер – ике сәгать эшләп, бу кораллар белән үземә кирәкле әйберләр ясыйм», – дип әйтә торган булган. Ул рәсем ясаган, географик карталар сызып, календарьларына урнаштырган.

К.Насыйри халык медицинасыннан файдаланган, төрле үләннәр белән дәваланган, физик хезмәт белән шөгыльләнгән. Шуның нәтиҗәсе буларак, бөтенләй диярлек ятып авырмаган. Бары тик гомеренең соңгы елларында гына аякларын җиңелчә паралич суга. Электр ярдәмендә дәвалану, туктаусыз хәрәкәтләнү нәтиҗәсендә генә ул йөрерлек хәлгә килә. К.Насыйри 1902 елның 20 августында (2 сентябрендә) 77 яшендә вафат була, Казанда Яңа бистә ягындагы каберлеккә күмелә.

Бөек мәгърифәтче, әдип Каюм Насыйри татар халкының рухи үсешенә ярты гасыр буена фидакарь хезмәт итеп килде. Ул фәннең барлык тармаклары буенча диярлек җиңел аңлаешлы, мисалларга, иллюстрацияләргә бай мавыктыргыч кулланмалар язды. Татар теленең сүзлекләрен, грамматикасын төзеде. Тәрҗемә итеп, фольклор әсәрләрен кертеп һәм оригиналь әсәрләр иҗат итеп «Кырык вәзир кыйссасы», «Фәвакиһел җөләса фил – әдәбият» («Әдәбият турындагы мәҗлесләрнең җимеше»), «Кырык бакча» җыентыкларын төзеп бастырды. Халык авыз иҗаты әсәрләрен язып алып укучыларга тәкъдим итте, халыкның күзен ачуга, аң – белемен, мәдәниятен үстерүгә зур өлеш кертте. Язучының китапларын күздән кичергәч, аны берүзе берничә фәнне укыткан «олуг мөгаллим, милләт педагогы» дип атарга мөмкин булыр иде. Аның укучылары – бөтен татар дөньясы. Каюм баба әйтерсең гомер буе тырыша-тырыша сабак бирә, үз халкын белемле, тәрбияле итәргә омтыла.

Мәгърифәтченең «Әхлак рисаләсе» дигән китапчыгы бар. Күләме зур түгел. Әмма ул анда баланы ничек тәрбияләү, укыту һ.б. турында ата-аналарга үзенең нәсихәтләре белән мөрәҗәгать итә. Ә инде 113 тәрбияне үз эченә алган «Тәрбия китабы», тормыштан алынган мисалларга бәйле, һәрбер очрак буенча ата-аналарга киңәш булып яңгырый. Әйтик, яшь вакытта ук балага тиешле тәрбия бирү кирәклеге, үскәч кешене тәрбияләп булмавын искәртү, халык педагогикасына таяну. К.Насыйри кешеләрне физик һәм рухи яктан сәламәт, тәрбияле итү ярдәмендә милләтне үстерергә, күркәм итәргә омтыла. Эчүчелек, тәмәке тарту кебек эш-гамәлләрне ул халык өчен агу, һәлакәт, кайгы-хәсрәт чыганагы дип саный. «Эчемлек эчә торган кеше һәрбер чәркәне эчкән саен үзен генә үтермәмдер, бәлки бөтен нәселен үтерәдер…» – ди ул.

Шунысы мөһим: К. Насыйри тәрбияви сабакларын еш кына гыйбрәтле мисаллар, җанлы сюжетлар ярдәмендә бирә. Бу исә үгет-нәсыйхәтләрнең үтемлелеген, тәэсирлелеген тагын да арттыра. Ул тәрбия эшендә музыка һәм сүз сәнгатенең әһәмиятенә басым ясый. Җыр-музыка, – ди ул, – «уй-фикерне саф кылыр, зиһенне нечкәртер, табигатьне (холыкны) йомшартыр, мәрхәмәтлене мактатыр, куркакны баһадирландырыр, саранны юмартландырыр …» Икенче бер урында болай дип яза: «Көйләп укымак яки шигырь әйтмәк гүзәлләрдән янә гүзәл нәрсәдер».

Каюм Насыйри, халыкны агарту максатында, гәзит чыгару хакында хыяллана. Исеме дә әле нинди символик: «Таң йолдызы»! Әмма патша Хөкүмәте аңа бу изге ниятен гамәлгә ашырырга рөхсәт бирми. Әйтеләсе күпме сүзләр, күпме теләкләр әйтелмичә кала.

Шулай да К. Насыйри халыкка сабак бирүнең, белем-мәгърифәт таратуның янә бер ысулын таба. Ул да булса – еллык өстәл календаре (горрәнамә) чыгару. Аның беренче саны 1870, ә соңгысы 1896 елда дөнья күрә.

К.Насыйри календарьлары (аларның уртача күләме – 40–70 бит) төрле характердагы материалларга гаять бай. Анда без, табигать турындагы белешмәләрдән тыш, фәнни мәгълүматлар, әдәби әсәрләр, тарихи хәбәрләр; тормыш яңалыклары һәм башкалар белән очрашабыз. Каюм бабаның чирек гасыр буена чыгарган календарьлары – билгеле бер дәрәҗәдә татар тормышының елъязмасы да ул.

Күргәнебезчә, К.Насыйри катлаулы тормыш юлы үткән. Шул кыска гомер эчендә күп әсәрләр иҗат итеп, безгә бай мирас калдыра. Шулай итеп, К. Насыйриның күпьяклы әдәби хезмәте, халык мәнфәгатьләрен күздә тоткан мәгърифәтчелек эшчәнлеге көннән-көн үсә барган. Каюм Насыйри соңгы көннәренә кадәр укуын һәм язуын ташламый. «Үзегез карт, күзләрегез зәгыйфь булса да, язуыгызны дәвам итәсез икән», – дигән кешегә ул: «Алла мине язар өчен яраткан, бу көннән язмый утыру аның хөкеменә каршылык булыр дип куркам», – дип җавап бирә торган була.

Каюм Насыйри бик гади гомер кичерә. Кызганыч, гаилә тормышы уңышсыз була: хатыны бала тапканда вафат була. Башка өйләнмичә, ялгыз гомер белемне ана телендә бирүне, укымышлы кеше булу өчен үз телен белүне хуплый.

«Бармыни бездә гомумән чын кеше кадерен белү?! Без аны кайдин белик, мискин үлеп аңламагач?!» Тукайның бу юллары Хөсәен Ямашев үлеме уңае белән язылган, әмма аларны Каюм Насыйрига карата да кулланырга мөмкин. Чөнки ул, ярты гасырдан артык, ат кебек эшләсә дә, үзе исән вакытта кадер – хөрмәт тә, юньле тормыш та күрмәгән. Гади халык арасында аны «Каюм бабай», «сукыр Каюм» дип йөрткәннәр. Кызганыч, 1902 елда вафат булгач, бу татар халкының яңарышка йөз белән борылган вакыты булса да, Каюм Насыйрины соңгы юлга озатучылар иң якын кешеләре һәм «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкертләре генә була. Ә инде зыялы шәхесләребезнең, гомумән киң җәмәгатьчелекнең аны соңгы юлга озатуда катнашулары турында мәгълүмат юк. Үлеменнән соң гына әлеге бай мирасның әһәмияте, кыйммәте таныла башлый. Ә бит хезмәтләре белән үз чоры укучысына гаять зур йогынты ясаган һәм чын мәгънәсендә энциклопедик галим буларак үсеп җиткәнлеген күрәбез.

Әмма аның иҗат мирасы еллар узган саен кыйммәтен арттыра бара. «Олуг мөгаллим» хакында төрле телләрдә күп санлы мәкалә-хезмәтләр язылуы, китапларның кат-кат басылуы ачык билгесе. К. Насыйри шәхесе әдәби әсәрләрдә дә гәүдәләнеш тоткан. Аның хакында М.Галинең документаль повесте һәм шушы ук авторның Х. Уразиков белән берлектә язган «Каюм Насыйри» дигән тарихи пьесасы да бар.

Әдип күптән вафат булса да, аның үлемсез әсәрләре яши. Без шул әсәрләрне укып үзебезгә рухи көч алабыз, алар белән сокланабыз.

**Кулланылган әдәбият.**


1. Ахунов А. «… Ят яраткан раббысы». // Татарстан.– 2005, № 1.
2. Каюм Насыйри. Сайланма әсәрләр (2 басмасы). Таткнигоиздат. Матур әдәбият редакциясе, 1956 ел.


## ТУГАН ТЕЛ ҺӘМ ӘДӘБИЯТ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ КАЮМ НАСЫЙРИ ХЕЗМӘТЛӘРЕН КУЛЛАНУ («КИТАБ-ӘТ-ТӘРБИЯ»)


**Кәримова Зөлфия Илдар кызы**
**Әхмәтгалиева Алсу Асхадулла кызы**
*ТР Казан шәһәре Совет районы «171нче ГБББУ»*
*Туган тел һәм әдәбияты укытучылары*


Бүгенге көндә тәрбия, әдәп-әхлак мәсьәләләре күпләребезне борчый. Чөнки җәмгыятьтә барган тотрыксызлык, гаделсезлек, әхлаксызлык, җинаятьчелек кебек күренешләрне яшь буын күреп, ишетеп үсә. Балаларны илдә барган шушы аяныч хәлләрдән саклап калып, алар күңелендә әдәп, әхлак, шәфкать, изгелек, кешелеклелек, намус, яхшылык һәм башка шундый сыйфатлар тәрбияләү – һәрбер тәрбияче һәм укытучының төп максаты дип саныйбыз. Шушы сыйфатларны тәрбияләү һәм тормышка ашыру максатыннан, эшчәнлегебездә татар халкының тәрбия тәҗрибәсен, педагогикасын һәрьяклап тирәнтен өйрәнгән һәм туплаган галим-мәгърифәтче, педагог һәм язучы

Каюм Насыйри хезмәтләренә таянабыз. Мәгърифәтче галимнең үзе җыйган фольклор әсәрләрен «Кырык бакча» (1880), «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият» (1884), «Әхлак рисаләсе», «Китаб-эт-тәрбия» һ.б. хезмәтләренең әһәмияте әйтеп бетергесез зур. Бу хезмәтләр балага белем һәм тәрбия бирүдә укытучы, тәрбияче һәм ата-аналар өчен иң кирәкле ярдәмлекләр булып торалар. Без дә дәресләребезне К.Насыйри хезмәтләренә таянып алып барырга тырышабыз.

**Эшебезнен максаты:** туган тел һәм әдәбият дәресләрендә К.Насыйриның «Китаб-эт-тәрбия» хезмәтеннән файдалануны күрсәтү.

Мәгърифәтче балаларның тәрбияле, белемле, гыйлемле һәм сәламәт булып үсүенә булышуны иң изге эш итеп саный. Белем алырга омтылу, гыйлемле булу, үзеңдә булган белемең белән уртаклашу, халыкка хезмәт итүнең өстенлеген күрсәтә.

Гыйлемле булу белән бергә, К.Насыйри балаларны һөнәргә өйрәнергә чакыра, вакытлы гына була торган милек-байлык белән мавыгып, кәсеп үзләштерү гамәлен үз итмәсә, киләчәге ышанычсыз булуын искәртә. Бу уңайдан «Китаб-эт-тәрбия» дә ул болай яза: «Әй җаннарым-угланнарым, нәсихәтне ишетегез – һөнәр үгрәнегез. Дөньяның милкене вә дәүләтенә ышанырга ярамас… Һөнәр – бер агым судыр, вә ышанычлы дәүләттер, һөнәр иясе әгәр дәүләттән төшсә дә кайгы юк… Әй угыл, син дә һөнәр үгрән, тәрбия үгрән, гыйлем үгрән (1 нче тәрбия).

Каюм Насыйри балаларны акыллы, әдәпле булырга өнди. Аның бик күп сандагы әдәби әсәрләре шушы карашларын образларда чагылдыралар. «Олуглык гакыл белән, әдәп белән, әмма нәсел белән, нәсәп белән түгелдер». «Әгәр дә бер адәм белән мөсәхабәт кылсаң, аның гакылына кара, диненә карама. Чөнки аның дине үзенә фәкать, әмма гакылы үзенә һәм сиңадыр»

Галим-мәгърифәтче К.Насыйриның тәрбия турындагы фикер-карашлары, халык тәрбиясе тәҗрибәсеннән туплаган тәгъбир-нәсихәтләре татар халкын, аеруча яшьләрне рухи-әхлакый саф итеп тәрбияләргә, әйләнә-тирәдәге тискәре, җинаятьчел күренешләрдән гыйбрәт ала белергә, сәләтле шәхес итеп формалаштырырга ярдәм итәләр.

Укучыларда милли үзаң тәрбияләүдә, милләтебез белән горурлану хисләре уятуда һәм балаларга әдәп-әхлак тәрбиясе бирүдә К.Насыйри хезмәтләре, аның тормыш юлы безнең өчен үрнәк булып тора. Без, укытучылар, укучыларыбызны К.Насыйри хезмәтләренә таянып, алар үрнәгендә тәрбияләсәк, киләчәк буын һичшиксез әхлаклы, миһербанлы булып үсәр.

## КАЮМ НАСЫЙРИНЫҢ ТАТАР ХАЛКЫНА КАЛДЫРГАН МАТЕМАТИК МИРАСЫ

**Фазлыева Лейсан Мирфаязовна**
*МБОУ «Старокурмашевская ООШ»*
*Актанышского муниципального района*
*Республики Татарстан*
*Учитель математики*

Каюм Насыйри – XIX гасырда яшәгән татар милләте тарихында күренекле шәхес, математик. Аның фәнни эшчәнлегенең төп юнәлеше булып математика фәнен популярлаштыру һәм аны татар телендә укыту тора. Насыйриның математиканы гади һәм аңлаешлы итеп тәкъдим итүе күп кенә укучыларның бу фәнгә кызыксынуын арттыра. Аның хезмәтләре математика укыту системасын яхшырту, фәнни фикерләүне үстерү һәм татар мәдәниятендә фән һәм белемнең әһәмиятен күрсәтүдә зур роль уйный. Насыйриның математика өлкәсендәге хезмәтләре татар мәдәниятенең заман таләпләренә җавап бирүендә әһәмиятле булып тора.

Мәгариф җәмгыять үсешен һәм аның мәдәни традицияләрен билгеләүче төп факторларның берсе булып тора. Гасырлар буена төрле сынаулар һәм үзгәрешләр белән очрашкан татар халкы тормышында мәгариф мәсьәләсе аеруча әһәмияткә ия. Монда күренекле педагог һәм мәгърифәтче

Каюм Насыйри үзәк урынны алып тора. Аның татар халкына математик белем бирүгә керткән өлеше яшьләр арасында белем дәрәҗәсен күтәрүгә генә түгел, ә алдагы буыннарга йогынты ясаган яңа белем бирү парадигмасын формалаштыру өчен нигез дә булды.

Әлеге эшнең актуальлеге булып Каюм Насыйриның гамәлгә ашырган тарихи тәҗрибәсе һәм педагогик инициативалары тора. Мәгариф социаль һәм мәдәни прогрессның мөһим коралы булып кала барган заманча җәмгыять шартларында Насыйри кебек шәхесләрнең керткән өлешен өйрәнү, үткәндәге казанышларны бәяләргә генә түгел, ә мәгариф системаларын алга таба үстерү юлларын да ачыкларга мөмкинлек бирә. Аерым алганда, аның укытуга якын килүе, яңа методлар кертүе һәм туган телдә уку материаллары булдыруы – кыйммәтле тәҗрибә булып тора, аны заманча белем бирү инициативаларында кулланырга мөмкин.

Бу хезмәттә Каюм Насыйриның татар халкын математикага өйрәтүгә керткән өлешен тирәнрәк аңларга ярдәм итәчәк берничә төп тема яктыртылачак. Беренче чиратта, татар халкы белеменең тарихи контексты каралачак, ул Насыйриның үз эшчәнлегендә нинди шартларда һәм нинди сынаулар белән очрашканын билгеләргә мөмкинлек бирәчәк. Бу аның Казанда рус-татар мәктәбен булдыру инициативасының ни өчен шулкадәр әһәмиятле булуын аңларга ярдәм итәчәк.

К.Насыйриның рус-татар мәктәбен төзүе, татар яшьләренә белем бирү өчен яңа офыклар ача. Бу тема кысаларында Насыйриның уку процессын ничек оештыруы, уку планына нинди фәннәр кертүе һәм аның белем бирү программасының максатлары турында анализланачак.

К.Насыйри иҗат иткән дәреслекләрне һәм аларның мәгарифкә йогынтысын өйрәнү дә мөһим. Аның татар телендәге арифметика буенча беренче дәреслеге чын алгарыш була, ул математикага өйрәтүгә генә түгел, ә бәлки татар теленең мәгариф өлкәсендәге позициясен дә ныгыта. Бу контекстта Насыйриның уку материалларының укучыларның белем һәм күнекмәләр дәрәҗәсенә, шулай ук татар халкы арасында математик грамоталылык үсешенә ничек йогынты ясавы каралачак, бу бигрәк тә хәзерге заман шартларына туры килә.

К.Насыйриның педагогик карашы да аерым игътибарга лаек. Аның аңлаешлылык һәм практик юнәлеш принципларына нигезләнгән укыту методлары укытуның яңа стилен формалаштыру өчен нигез булды, ул заманга хас булган традицион алымнарны алыштырды. Бу тема кысаларында Насыйриның белем бирү методикаларын үз укучыларының ихтыяҗларына ничек җайлаштыруы һәм бу аларның уңышлы белем алуына ничек ярдәм итүе анализланачак.

К.Насыйри мирасы да хәзерге контекстта анализ предметы булачак. Глобальләшү һәм технологияләрнең бик тиз үсүе шартларында аның белем бирүгә карашлары яңадан уйланылырга һәм заманча чынбарлыкка яраклаштырылырга мөмкин. Насыйри идеяләренең бүген мәгариф өлкәсендәге актуаль проблемаларны хәл итүдә ничек файдаланылуын аңлау мөһим.

Ниһаять, Каюм Насыйриның мәгариф инициативаларында мәдәниятнең роле каралачак. Мәгариф вакуумда яши алмый, һәм мәдәни традицияләр, тел һәм кыйммәтләр белем бирү процессын формалаштыруда мөһим роль уйный. Бу җәһәттән Насыйриның мәдәни аспектларны үзенең белем бирү практикасына ничек интеграцияләве һәм бу аның укучыларының белемнәрен тирәнрәк кабул итүенә ничек ярдәм итүе анализланачак.

Шулай итеп, әлеге эш Каюм Насыйриның татар халкына математик белем бирүгә керткән өлешен һәрьяклап өйрәнүгә юнәлдерелгән, бу аның казанышларын бәяләргә генә түгел, ә аның мирасының хәзерге белем бирү процессы өчен әһәмиятен дә ачыкларга мөмкинлек бирәчәк.

Әлеге эшнең ахырында Каюм Насыйриның татар халкын математикага өйрәтүгә керткән өлеше әһәмиятле генә түгел, ә күпкырлы да булуын ассызыклап үтәргә кирәк. Аның тарихи контекст шартларында белем бирү өлкәсендәге эшчәнлеге, татар халкы мәдәнияте бәйле таләпләргә юлыкканда, укытуга яңача якын килүне формалаштыруда төп роль уйнады. Казанда Беренче рус-татар мәктәбен төзү татар халкын Россия империясенең киңрәк мәгариф һәм мәдәни контекстына интеграцияләү юнәлешендә мөһим адым булды. Бу учреждение татар халкы балаларына рус телен өйрәнү мөмкинлеге генә биреп калмыйча, математика белеменә дә ишек ачты, бу исә яшьләрдә тәнкыйди фикерләү һәм аналитик күнекмәләр үсешенә ярдәм итте.

К.Насыйри иҗат иткән дәреслекләр, аерым алганда, татар телендәге арифметика буенча беренче дәреслек белем бирү практикасында чын алгарыш була. Алар туган телдә белем алуны тәэмин итеп кенә калмадылар, ә яңа белем бирү мохитен формалаштыруга да ярдәм иттеләр, анда татар теле һәм мәдәнияте сакланып кына калмады, ә үсеп тә китте. Дини текстларга һәм белемнәрне телдән тапшыруга нигезләнгән традицион укыту методлары тиз Үзгәрүче җәмгыять ихтыяҗларын канәгатьләндерә алмаган шартларда бу аеруча мөһим иде. Насыйри, мулланың традицион ролен укытучылыкка алыштырып, белем бирү инициативалары өчен яңа офыклар ача, бу исә татар халкы арасында прогрессив мәдәният формалашуга ярдәм итә.

К.Насыйриның һәркем файдалана алырлык һәм гамәли принципларга нигезләнгән педагогик якын килүе белем бирү программаларын алга таба үстерү өчен нигез булып тора. Ул белемнең теоретик кына түгел, ә практик булырга тиешлеген аңлый, бу аның укучыларына алган белемнәрен реаль тормышта кулланырга мөмкинлек бирә. Бу, үз чиратында, яшьләр арасында белем дәрәҗәсен күтәрүгә һәм актив гражданлык позициясен формалаштыруга ярдәм итте. Аның эш нәтиҗәләрен татар мәдәниятен һәм фәнен үстерүгә үз өлешләрен кертеп, иҗтимагый тормышта актив катнашкан укучыларының уңышларында күрергә була

Шулай итеп, К.Насыйриның татар халкына математик белем бирүгә керткән өлеше мәгариф тарихында мөһим этап булып тора, ул татар мәдәнияте һәм фәне үсешенә сизелерлек йогынты ясый. Аның идеяләре һәм алымнары, белем бирүнең социаль һәм мәдәни прогресс өчен корал буларак әһәмиятен ассызыклап, Яңа буыннарны илһамландыруны дәвам итә. Аның мирасын истә тотарга һәм хәзерге дөньяда татар халкының һәм мәдәниятенең алга таба үсешенә ярдәм итәчәк мәгариф инициативаларын үстерүне дәвам итәргә кирәк.

## КАЮМ НАСЫЙРИ ХЕЗМӘТЛӘРЕНДӘ ТӘРБИЯ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

**Шәйдуллина Дания Рафик кызы**
*Татарстан Республикасы*
*Яңа Чишмә муниципаль районы*
*МБОУ «Яңа Чишмә гимназиясе»нең*
*Туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучысы*

Бүгенге көндә җәмгыятьтә әхлак, тәрбия мәсьәләсе җитди тора. Кызганычка каршы, акча, байлык, мал артыннан куып, буыннардан килгән тәрбия кагыйдәләрен онытып җибәрәбез шикелле. Без, укытучыларның бурычы – яшь буынны югары әхлак сыйфатларына ия булган мәдәниятле кешеләр итеп тәрбияләү, олы тормыш юлына әзерләү. Шуңа күрә Каюм Насыйриның эшчәнлеге белән тирәнрәк танышу, аның хезмәтләрендәге әхлак темасының бирелешен өйрәнүне һәм ртаклашуны максат итеп куйдым.

Татар халкының педагогик культурасын үстерүдә бөтен белемен, көчен халыкка аң-белем таратуга биргән шәхесләрнең роле зур. Шундый шәхесләрнең берсе – Каюм Насыйри. Каюм Насыйри – күренекле мәгърифәтче, галим, язучы, педагог. Бу могтәбәр затның эшчәнлеге күпкырлы: аның әдәбият, тел белеме, математика, медицина, педагогика, тарих, география өлкәләренә караган фәнни хезмәтләре билгеле. Галимнең педагогик карашларына күз салсак, ул зирәк һәм акыллы кешеләрдән тәрбиягә өйрәнүне дөрес санаган. «Акыл иясен тыңлаучыга рәхәтлек бирә, әмма белмәгән һәм явыз кеше белән сөйләшеп вакыт әрәм итмәскә кирәк, » – ди.

Һәр укытучы тәрбия эшендә югары нәтиҗәләргә ирешергә омтыла. Шул уңайдан бөек мәгърифәтчеләр, педагогларның карашларына таяна. К.Насыйриның тәрбия һәм педагогика өлкәсендәге фикерләре гаять әһәмиятле. Аның хезмәтләрен укыту-тәрбия системасында куллану

бик нәтиҗәле дип саныйм. Шуңа күрә әлеге чыгышымда К.Насыйри хезмәтләрендәге тәрбия мәсьәләләренә тукталасым килә. Педагог бөтен яктан да килгән шәхес тәрбияләү проблемасына зур игътибар бирә, яшь буынның тәрбияле, белемле һәм сәламәт булып үсүен тели. Аның «Тәрбия китабы», «Этика турында кыскартылма китап», «Этика турында зур китап», «Кабуснамә», «Кырык бакча», «Кырык вәзир кыйссасы», «Китаб-әт тәрбия», «Әхлак рисаләсе» китаплары һәм башка мәкаләләре тәрбиянең аерым якларына багышланган. Күренекле мәгърифәтче К. Насыйри яшьләрдә туган илгә, туган телгә мәхәббәт; кыюлык, батырлык, тапкырлык, хезмәт сөючәнлек, дөреслек, тугрылык, гуманлылык кебек әхлак сыйфатларын тәрбияләргә киңәш итә. «Фавакиһел-җөләсә фил-әдәбият» («Әдәбият турындагы мәҗлесләрнең җимеше») исемле хезмәтендә К.Насыйри өйрәнелергә һәм сакланырга тиешле гадәтләр турында гыйбрәтле мисаллар китерә. Бу җыентыкны педагогик энциклопедия, тәрбияви хрестоматия дип тә атарга мөмкин. Анда кеше табигате өчен хас булган бик күп сыйфатлар, эш-гамәлләр, күренешләр хакында сүз бара. Автор аларны бакчада үскән төрле җимешләр дип атый. «Тәмен белгән кеше ашар, белмәсә төкереп ташлар», – ди ул.

Педагог фикеренчә, һәр бала туган телен, мәдәниятен белергә һәм өйрәнергә, өлкән буын традицияләрен сакларга, үзенең туган йортын, зур һәм кече Ватанын яратырга, күршеләрен хөрмәт итәргә тиеш. Үгет-нәсыйхәтләр, гыйбрәтле хикәяләр тупланган зур булмаган «Тәрбия китабы» нда ул яшьләрне әхлакый тәрбияләүнең безнең заманда да актуаль булган күп кенә проблемаларын күтәрә. К.Насыйри китабында 113 үгет-нәсыйхәт бар. «Тәрбия китабы» нда катнашучылар булып пәйгамбәрләр, тәкъвалар, зирәкләр тора. Автор вакыйгаларны акыл ияләре һәм гади кешеләр тормышыннан мисаллар белән тасвирлый, ә аннары нәтиҗәләр ясый, укучыны әхлакый яктан үстерә. Язучы укучыга «Әй угыл!», «Балаларым!» дип мөрәҗәгать итә, үзен югары күтәрми, ә тигез дәрәҗәдә әңгәмә алып бара, укучыга ярдәм кулы суза, киңәш бирә, проблемаларны хәл итәргә ярдәм итә.

«Кырык вәзир кыйссасы» әсәренә кергән хикәяләрдә дә гаделлек, намуслылык, батырлык һәм хыянәт итәргә ярамау турында сөйләнә.

«Этика турында кыскартылма китап»та педагог «Ашаган, эчкән, йоклаган кеше түгел, ә әдәпле итеп сөйләшә, уйлый, эш итә белгән кеше генә чын кеше була ала», – дип яза. К.Насыйри балаларда яхшы холык формалаштыруга зур әһәмият бирә. Гаделлек, намуслылык, киң күңеллелек сыйфатлары үстерелергә тиеш дип саный. «Этика турындагы китапта» да һәм башка әсәрләрендә дә «Дөреслекне яраткан кеше җәмгыятьтә зур хөрмәткә ия була». «Барлык кешеләр белән дә яхшы мөгамәләдә бул, алар белән ягымлы сөйләш, яхшылык эшлә», дигән фикерләрне җиткерә.

Аның педагогик хезмәтләрендә тәртип мәсьәләсе дә үзәккә куела. Өлкәннәрне хөрмәт итү, кечкенәләргә игътибарлы булу, әдәплелек, кунакчыллык сыйфатлары мактала. «Ахмак сүзләр әйтмә, әйтәсең икән, башкалардан да шуны ишетерсең», дип кисәтә ул. К.Насыйриның «Тәрбия китабы»ндагы тагын бер балалар һәм яшьләр өчен бик гыйбрәтле нәсихәткә тукталыйк. Чөнки мондый тәрбия эшәке теллелек киң таралган, сөйләмдә оятсыз, сүгенү сүзләре еш кулланылган хәзерге чорда аеруча тансык. 89 нчы тәрбиядә болай диелә: «Әй угыл, кешенең күңеленә хилаф килә торган сүзне теленә китермә. Кеше күңелен рәнҗетүдән бик саклан».

Әхлак тәрбиясенең төп нигезе итеп галим хезмәт тәрбиясен алган. «Әгәр тормышта канәгатьләнү хисе кичерәсең килсә, үз хезмәтең белән яшә, чөнки хезмәттән башка канәгатьләнү хисе тумый», – дип искәртә автор «Кабуснамә» китабында. «Китаб-әт-тәрбия»дә ул болай яза: «Әй җаннарым-угланнарым, нәсихәтне ишетегез – һөнәр үгрәнегез. Һөнәр – бер агым судыр, вә ышанычлы дәүләттер». К.Насыйри үзе үк хезмәт сөючәнлеге белән башкаларга үрнәк булып торган. Акыл хезмәте белән физик хезмәтне оста чиратлаштыра белгән. Утырып эшләүдән кан тамырлары оеша дип, көн саен физик эш белән дә шөгыльләнгән: столяр, слесарь эшләрен башкарган, китаплар тышлаган, пешергән, хуҗалык эшләрен дә башкарган. Бер язмасында ул: «35 ел Казанда яшәгәч, ниһаять, Туган авылым Шырданга кайттым. Монда каләм түгел, күбрәк чалгы, сука төзәтергә туры килде», –ди.

К.Насыйри төрле һөнәрләр үзләштерү җиңел булсын өчен, мәктәпләрдә хезмәт укытуны таләп иткән. «Ювелирлык һәм слесарьлык эше турында», «Җирчелек фәне турында», «Кулинария буенча кулланма» китапларын язган.

«Этика турындагы китапта» К.Насыйри бала өчен иң әһәмиятле хезмәт итеп белем алуны атаган. «Белем алу өчен ялкауланма. Ялкаулыкны җиңәргә кирәк, чөнки ул башка кимчелекләрне дә китереп чыгара», – ди ул. Шулай ук моңа мисал итеп, «Әдәбият турындагы мәҗлесләрнең җимеше» китабыннан балалар өчен файдалы булган әрлән белән бака турындагы мәсәлне китерергә мөмкин. «Әхлак рисаләсе» китабында, балаларга мөрәҗәгать итеп, болай ди: «И газиз бала!.. Адәмгә бигрәк кирәк вә бигрәк лязем нәрсә – гыйлемдер. Гыйлем үгрәнмәгә, укымага, язмага вә һөнәр вә мәгърифәт хасил итмәгә иҗтиһад кыл, чөнки гыйлем вә мәгърифәт иясе һәр йирдә хөрмәтле булып, халык арасында кадере зур булыр». Педагог патриотик тәрбиягә дә зур урын биргән. Туган илне дошманнардан саклау өчен, батыр, кыю булып үсү зарур. «Куркак булма, сугышта үлем турында уйлама, үзеңнең көчсезлегеңне башкаларга күрсәтмә»,– ди ул «Кырык бакча» китабында. Бу уңайдан яшьләрнең физик үсешенә әһәмият бирү кирәклегенә басым ясый. К.Насыйри үзе дә халкын, ватанын сөйгән, анда яшәүче халыкларның дуслыгын, туганлыгын теләгән, бөтен гомерен халыкка хезмәт итүгә багышлаган. Ул үз иленең, халкының алдынгы улы, ялкынлы патриоты. Аның өчен батырлык, булдыклылык – беренче планда. Каюм Насыйри балаларны да шул рухта – илнең көчле батырлары, ялкынлы патриотлары итеп тәрбияләүне алга сөреп эшли.

К.Насыйри яшәгән чорда эстетик тәрбия бирү бөтенләй диярлек булмаган. Ислам дине музыка тыңлауны да тыйган. Шундый шартларда К.Насыйри эстетик тәрбия бирүне, мәктәпләрдә рәсем, җыр, музыка укытырга кирәклеген күтәреп чыккан. Яшьләрне төрле уен коралларында уйнарга өйрәнергә чакырган. Истәлекләрдән күренгәнчә, үзе дә музыканы бик яраткан, берничә уен коралында (курай, кубыз, скрипка, балалайка) уйный белгән.

К.Насыйри милләтләр арасында дуслыкны ныгытуга да зур игътибар биргән. Бөек педагог фикеренчә, кече һәм зур халыклар юк, барлык халыклар тигез һәм бердәм, һәркемнең үз кабатланмас үзенчәлекле мәдәнияте бар, аны якларга, сакларга һәм киләчәк буынга тапшырырга кирәк. Чөнки тел, мәдәният юкка чыкса, халык та юкка чыгачак. К. Насыйри рус халкын, аның мәдәниятен хөрмәт иткән. Ике арада дуслык элемтәләрен ныгыту өчен, русларны үз халкының мәдәнияте белән таныштырган. Шул максаттан «Образцы народной литературы казанских татар», «Поверья и обряды казанских татар» һәм башка китапларын язган. Бу хезмәтләр үз вакытында рус галимнәре тарафыннан уңай бәя алган.

К.Насыйри җыйнап бастырган мәкальләрдә дә акыл, белем, тырышлык, уңганлык, пөхтәлек кебек күркәм сыйфатлар мактала һәм, киресенчә, наданлык, саранлык, ялкаулык, көнчелек ише тискәре сыйфатлар кискен гаепләнә. К.Насыйри әкиятләргә дә шундый ук вазифаны йөкли.

Шулай итеп, К.Насыйри балаларны тәрбияләү өлкәсендә зур хезмәт куйган. Вакытлар, еллар үткән саен, аның халыкка күрсәткән хезмәте, фәнгә, педагогикага, мәдәниятка керткән өлеше тагын да ачыла бара. Аның китаплары – укытучыларның һәм ата-аналарның өстәл китабы булырлык кыйммәтле мирас.

Һәр укытучы, һәр педагог укучыларын тәрбияләргә әзер булырга тиеш. Ә моның өчен ул энциклопедик белемгә ия булырга, фәннәрне яратырга, тәрбия нигезләрен тирәнтен белергә тиеш. Шуны да онытмаска кирәк: тәрбия бер көн эчендә генә бирелми. Ул – кеше туганнан алып, соңгы көненә кадәр дәвам итәргә тиешле процесс. Шуңа күрә тәрбия дә бала тугач ук, гаиләдә башланырга тиеш, бары шунда гына ул уңышка илтәчәк.

# КАЮМ НАСЫЙРИ ШӘХЕСЕ ҮРНӘГЕНДӘ ТУГАН ТЕЛНЕ ӨЙРӘНҮДӘ ЗАМАНЧА АЛЫМНАР

**Шакирова Ләйлә Миннемулла кызы**
*«79 нчы номерлы экология-технология лицее» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе Китапханә мөдире*

Һәр халыкның тарихта тирән эз калдырган күпкырлы шәхес ияләре була. Алар аң-белем бирүдә, милләтне тәрбияләүдә аеруча зур эш башкаралар. Үз тормышын мәгърифәткә һәм туган телне үстерүгә багышлаган, үз халкы турында кайгыртып, бөтен көчен халыкны гыйлемле итүгә юнәлдергән Каюм Насыйри шәхесе, аның мирасы, эшчәнлеге бүгенге көндә аеруча әһәмияткә ия һәм яшь буын тарафыннан тирәнтен өйрәнелергә тиеш.

Каюм Насыйри – төрле фән нигезләре белән татар халкын ана телендә таныштыручы. Математика фәне буенча «Хисаплык», геометрия буенча «Гыйльме Һәндәсә» дәреслекләрен язучы. Тарих фәне буенча төрле мәкаләләре, махсус китаплары бар. Казан тарихы хакындагы язмалары кызыклы. Шулай ук күп кенә татар авылларының тарихы хакында да мәкаләләр яза. Ул бу эш вакытында халык телендәге материалларны, каберташ язмаларын, төрле шәҗәрәләрне, кульязма һәм басма китапларны ныклап өйрәнә. Зур күләмле география китабын әзерли. Шулай ук игенчелек, ботаника буенча китаплар чыгара, үзе сызган карталарын календаренда бастыра.

Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле, аның әсәрләреннән өзекләр, әлбәттә, мәктәп дәреслекләренә кертелә, укытучылар тарафыннан өйрәтелә. Мондый традицион укыту ысулын **китапханәдәге махсус дәресләр** белән тулыландыру, **матбугатта сәхифәләр уйлап табу**, «Апуш» татар балалар театры тарафыннан махсус тәкъдим ителүче **спектакльне карау** кебек **заманча алымнар** татар халкының бөек шәхесләрен өйрәнүдә **нәтиҗәле чара** булып тора.

Милләткә фидакарьләрчә хезмәт итүнең бөек бер үрнәге булган Каюм Насыйри эшчәнлеген яшь буынга шундый нәтиҗәле, үтемле чаралар аша җиткерү максатыннан китапханәнең эш планына «**Каюм Насыйри мирасы: шифалы үләннәр**» **дигән дәрес** кертелде. Экология юнәлешендә эшли торган лицеебызда «Сабантуй» журналы хезмәткәрләре белән очрашу оештырылып, **экосәхифә уйлап** табылды. Һәм журналга мәкаләләр язган саен Каюм Насыйриның табигать фәннәре, шифалы үләннәр хакындагы мәгълүматларын искә алып, бөек шәхеснең эшчәнлеген буыннан-буынга түкми-чәчми тапшыру минем төп бурыч булып тора.

Каюм Насыйриның тәрҗемәче икәне дә яхшы мәгълүм. Тәрҗемә өлкәсендә гыйлем иясе иҗат иткән әсәрләрнең иң күренеклесе – «Әбүгалисина кыйссасы». Әбүгалисина – реаль шәхес, танылган Шәрык галиме, медицина өлкәсендә зур белгеч. Каюм Насыйри аны хыялый җирлеккә күчереп, белемнең көчен раслауны максат итеп куя. Укучыларны әлеге әсәр белән таныштыруда да **яңалык табарга** – бөек татар мәгърифәтчесе Каюм Насыйриның тууына 200 ел тулуга багышлап «Апуш» татар балалар театр студиясе тәкъдим иткән «Әбүгалисина» мюзиклын карарга була. Гарәп язулары белән чуарланган декорацияләрнең сәхнә утлары белән төрле төсләрдә балкуы, Әбүгалисинаның фантастик машинасы, кételмәгән киемнәр, җыр-бию – барысы берләшкән әлеге матур әкият – укучы күңелендә истәлекле бер хатирә, татар телен театр сәнгате аша яшүсмерләр арасында популярлаштыруның гүзәл бер үрнәге була ала дип саныйм мин.

Туган телебезне хөрмәтләгән, милли тәрбия тәҗрибәсен, педагогикасын һәрьяклап киң масштабта өйрәнгән һәм туплаган галим-мәгърифәтче, педагог, язучы К.Насыйри шәхесен яшь буынга үрнәк зат итеп күрсәтү, аның эшчәнлеген өлге итеп укучыларда кызыксынучанлык, максатчанлык, тырышлык, иҗадилык, бүгенге вәзгыятьтә телгә карата тирән ихтирам тәрбияләү – милли мәгариф системасының төп бурычы!

# КАЮМ НАСЫЙРИ ҺӘМ МАТЕМАТИКА

**Гайсина Алсу Шагизяновна**
*Казан шәһәре Яңа-Савин районының*
*«Татар телендә белем бирүче 155 нче гимназия»*
*гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе*
*Математика укытучысы*

Бөтен гомере буе халыкка фидакарьләрчә хезмәт кылган, милләт мәнфәгатен үзенең яшәү кыйбласы иткән татар галимнәре һәм әдипләре арасында иң лаеклы урыннарның берсен Каюм Насыйри алып тора. Татар мәгърифәтчесе Каюм Насыйри үз вакытында халыкка күпьяклы белем бирергә тырышкан, дәреслекләр, методик ярдәмлекләр төзегән. Аның күп кенә фикер-киңәшләре әле бүген дә үз актуальлеген югалтмаган.

Каюм Насыйри бөтен тормышын, әдәби талантын халыкка хезмәт итүгә багышлаган, татар халкының аң-белемен күтәрү, агарту юлында гаять әһәмиятле эшләр башкарган.

Каюм Насыйриның күп яклы фәнни хезмәтләренең әһәмияте, үз заманының яктылыгында алып караганда, тагын да ачыграк күренә. Ислам һәм мөселман тәэсире астында яшәгән иске татар дөньясыннан чыгып, ул әкрен генә, ләкин ышанычлы адымнар белән яңа юлга аяк баскан…

Каюм Насыйри күп кенә әсәрләрендә ул вакытларда мәдрәсәләрдә балаларның зиһенен ача торган кирәкле гыйлемнәр укытылмавын ассызыклаган. «Казан халкына мөрәҗәгате» әсеренең хәзерге әдәби телгә күчермәсе буенча өченче мөрәҗәгатендә менә нәрсә дип язган ул: «Мәдрәсәдә бер хәлфә кебек нәрсәгә бирәсез дә, ул үзе дә сезнең балаларыгыздан түбән, балаларга нәрсә укытырга кирәклеген белми, хәтта нәрсә укытканын үзе дә белми. Көтмәгәндә балаларыгыздан: «Энем, нәрсә укыйсың?» – дип сорасаң: «Фәзаилешшөһүр», «Бакырган» яки «Йосыф китабы» дип җавап бирерләр һәм шуның белән мәдрәсәдән чыгаралар. Ул баладан нинди белем өмет итәргә кирәк? Иң зиһенне ача торган фәннәрдән: философия, математика, астрономия һәм этика шикелле фәннәр укытылмыйлар» [5, 40 бит]. «Әлхитабес-самин»да исә Каюм Насыйри болай дип язган (хәзерге әдәби телгә күчермәсе): «Гыйлем коралы булган нәрсәгә ун ел гомерне әрәм иткәннән соң, мулла булып киткәч, бер логикадан гына эш чыкмый. Монда этика да кирәк, шәригать законнары да, география дә, геометрия дә кирәк була һәм астрономиядән дә беләсе килә башлый. Шул ук вакытта һөнәр һәм промышленностьны һәм администраторлык кагыйдәләрен белү дә кирәк була. Бу фәннәрнең нигезе – математика һәм табигать гыйлемнәре булып, аннан хәбәрегез юк. Ләкин мәктәптән чыккач, математиканы өйрәнү читен». [5, 43 бит] «Әлхитабет– тәсигъ»тә ул болай дип язган (хәзерге әдәби телгә күчермәсе): «Гимназиянең баштагы дүрт класс фәннәре: хисап, география, геометрия һәм рус тарихы. Ул фәннәрне ун яшьлек балалар укыйлар. Җитмешенче елда администрациянең баштагы күрсәтмәләрендә: «Фәннәр башлап мөселманнарның үз телендә укытылыр», – дигәннән соң, 73нче елда «Хисаплык» исемле бер китап чыкты» [5, 44 бит].

«Әлхитабе-әлхади-гашәр» дә болай дип язылган (хәзерге әдәби телгә күчермәсе): «Сез балаларыгызның, букчага күп китап тутырып, сабакка йөрүләрен белем алу дип уйлыйсыз. Хәзердә белем алу – алай түгел, сез аны аңламыйсыз. Хисап, география, геометрия һәм табигать фәннәре – математиканың бүлекләре. Боларны күрмәгән кеше – кеше түгел. Мәдрәсәдә укыган балаларыгызның зиһеннәре шул дәрәҗәдә катып калгандыр ки, аларныэшкә китерү читен. Хисаптан, географиядән, геометриядән, табигатьтән, химиядән, һөнәр һәм сәнгатьтән – һәркайсыннан балаларыгызга бераз-бераз белем бирү тиеш иде» [5, 47 бит].

Төрле табигать фәннәренең нигезләре белән татар халкын ана телендә беренче буларак таныштыручы да К. Насыйри булган. География дәреслекләрен язганда да К.Насыйри шул принцибыннан чыгып эш итә. «Үз телебезгә килешә торган сүзләрне табып, җәгърафия терминнарын белдердем», – ди. Алардан да элекке китаплардагы киң күпчелеккә аңлаешсыз терминнар урынына татар теленнән ала. Мәсәлән: *төн ягы, төшлек тарафы, кояш чыгышы тарафы, кояш батышы*

*тарафы, атау, ярты атау, ут тавы, елга, диңгез, тамак* һәм башкалар. Бу терминнарны буржуаз язучылар Каюм Насыйридан соң да әле гарәпчә йөртергә аз тырышмаганнар. Ләкин алар берсе дә халык сөйләменә кереп китә алмаганнар. Гомумхалык теленә таянып эш иткән Каюм Насыйри принцибы җиңеп чыккан, ул кертә башлаган терминнар аныклана һәм камилләшә барган.

Каюм Насыйри, тегe яки бу фән хакында мәгълүмат биргәндә, аны тормышта файдалану якларына да нык игътибар иткән.Каюм Насыйриның математика турындагы кульязмалары – моңа бик ачык дәлил. Нәкъ менә аның хезмәтләре арасында математика фәне үсешенә багышланганнары да шактый.

Каюм Насыйри – татар телендә фәнни терминология булдыруга күп хезмәт керткән галим. Ул бу юлда гаять кыю тәҗрибәләр ясаган һәм зур нәтиҗәләргә ирешкән, беренче чиратта, гарәпчәдән алынган, авыр әйтелешле терминнар урынына аңлаешлы татар сүзләрен термин итеп беркетү юлын тапкан.

Ул математика фәне буенча «Хисаплык» (1873 ел), «Истилахаты гыйльме һәндәсә» (геометрия фәне, 1895 ел) дәреслекләре язып чыккан.Арифметика буенча «Хисаплык» исеме белән язган дәреслегенең сүз башында Каюм Насыйри үзенең шул теләкләрен түбәндәгечә аңлатып биргән:»Бу вакыткача гыйльме хисап фәнендә безнең үз телебез белән бер дә язылган китап юклык сәбәпле, истилах (термин) сүзләре юк иде. Имди бу «Хисаплык» дигән китабыбызда истилах сүзләре өчен мөмкин кадәр үз телебездәге сүзләрне сайладык. Мәсәлән, «Хисаплык» дидек. Бу гәрчә гарәпчә сүз булса да, аны белмәгән кеше юктыр. Бу «Хисаплык» дигәнебез «гыйльме хисап» дигән сүз булсын. Вә янә *сан* дидек-гарәп телендә «исме гадәд» дигән сүз урынына булсын. Вә янә гыйльме хисапның бер кагыйдәсен *җыю* дип әйттек, гарәпчә «җәмгы» дип әйтәләр. Вә янә гыйльме хисапның икенче кагыйдәсен*аеру* дип атадык, гарәпчә «тәфрикъ» диярләр. Янә тагы гыйльме хисапның өченче кагыйдәсенә *сугу* дип исем бирелде, гарәпчә»зарып» дияләр. Вә янә тагы дүртенче кагыйдәсе *бүлү* аталыр, гарәпчә исеме «тәкъсимдер» [4, 28 бит],[5, 102–103 бит].

Каюм Насыйри, дәреслекләр язганда, математика терминнарының балаларга аңлаешлы булуына омтылган. Ул арифметикадагы дүрт гамәл мәсьәләләрен чишүгә бәйләнешле барлык төшенчәләрне дә татарча исәпләп чыгарган. Шулардан *сан, бүлү, сумма, калдык, аерма, сугу тапкырлау, сугылмыш сан, суккыч, бүлгеч, өлеш* һәм башкатерминнарның кайберләре хәзерге көндә дә шул ук төшенчәдә йөртеләләр. Мәсәлән:1нче сыйныфның математика дәреслегенең 1нче кисәгендә *сумма* [6, 86 нчы бит], 2нче кисәгендә *аерма* [6, 29 нчы бит], 2нче сыйныфның математика дәреслегендә *тапкырлау* [7, 48 нче бит], *бүлү* [7, 58 нче бит], *өлеш* [7, 62 нче бит], 3 нче сыйныфның математика дәреслегенең 2 нче кисәгендә *калдык* [8, 26 нчы бит] атамалары өйрәнелә.

Мәгърифәтченең 1878 елда язылган «Һәндәсә мәсьәләләре» («Геометрия мәсьәләләре») дигән икенче кульязмасы иллюстрацияләргә бай булган. Текст эчендә һәм битләр читендә төрле геомертик фигураларның (почмак һәм өчпочмаклар, мәчет манаралары, биналар, елга һәм күлләр) сызымнары китерелгән. «Истилахате гыйльме һәндәсе» («Геометрия фәне терминнары») дигән китабында мәгърифәтче гарәпчә һәм татарча терминнарны янәшә кулланган: «*хатты мөстәкыйм – туры сызык* мәгънәсендәдер», «*хатты мөстәдир – түгәрәк сызык* димәкдер»; «*завия яки почмак* дип әйтәләр», «*мәсәлләс – һәндәсә истилахында өчпочмак* димәкдер» һ.б. Ул кулланган бу терминнар кайберләре хәзерге дәреслекләрдә дә сакланып калган. Мәсәлән:1нче сыйныфның математика дәреслегенең 1 нче кисәгендә*туры сызык*, [6, 40 нчы бит], 2нче сыйныфның математика дәреслегендә *почмак* [7, 8 нче бит], 5нче сыйныфның математика дәреслегендә *туры сызык* [3,10 нчы бит], *түгәрәк сызык (әйләнә)*[3, 133 нче бит], 7–9нчы сыйныфлар өчен геометрия дәреслегендә *почмак*[1, 8 нче бит], өчпочмак [1, 28 нче бит] өйрәнелә.

Мәгърифәтче үзе язган математика дәреслекләрендә үлчәү эшләрендә кулланыла торган түбәндәге терминнардан файдаланган: *сатых* (өслек), *сатхи мөстәви* (тигез өслек), *сатхи мөнхәни* (тигезсез өслек), *хатты* (сызык), *хатты офыкый* (горизонталь сызык), *хатты гомуди* (вертикаль сызык), *хатты мөтавази* (параллель сызык), *хатты мәфруз* (уйланма сызык), *мәркәзи хатты* (сызык уртасы), *мөсафә* (билгесез ераклык), *тул* (озынлык), *мәсәлләс* (өчпочмак), *мәсәлләскаимеззавия* (турыпочмаклы өчпочмак), *мәсәлләс мөтәсавиеззавия* (тигезьяклы өчпочмак), *завия* (почмак), *рәэсзавия* (түбә, оч), *кабырга* (як), *завияи каимә* (туры

почмак), *гомуми* (перпендикуляр), *мөсәви* (тигез), *мөнәсбәт* (чагыштырма), *сан* (охшашлык), *вәтәд* (казык), *мөсаһә зәнҗиры* (үлчәү чылбыры), *согмар гуниясы* (эккер), *сажин, сурәт* (рәсем).

Геометрия буенча К.Насыйри тарафыннан кулланылган, менеп булмый торган биеклекне үлчәү ысулы ярдәмендә, мәчет манарасының биеклеген үлчәү буенча практик эш эшләдем.

Охшаш өчпочмакларның үзлекләрен җир өстендә төрле үлчәү эшләре башкару өчен файдаланырга мөмкин. Хәзерге геометрия дәреслегендә мондый төр мәсьәләләр чишү үрнәге күрсәтелгән[1, 150 нче бит]. Укучыларга чишү өчен бирелгән 579, 580, 581 нче мәсьәләләр шушы ысул буенча эшләнә [1, 154 нче бит].

Каюм Насыйрины чын мәгънәсендә, «олуг мөгаллим, милләт педагогы» дип атарга мөмкин. Аның укучылары – бөтен татар дөньясы. Каюм Насыйри, әйтерсең, гомер буе тырыша-тырыша сабак бирә, үз халкын белемле, тәрбияле итәргә омтыла. Шулай итеп, К. Насыйри үзенең арифметика һәм геометрия дәреслекләре белән татар яшьләренә дөньяви белемгә рөхсәт кенә ачмаган, ә алга таба арифметика һәм геометрия дәреслекләрен чыгару өчен ныклы нигез булдырган.

Хәзерге көндә дә Каюм Насыйриның хезмәтләре гасырлар тузаны астында югалып калмаган. Татар мәктәпләрендә укытыла торган дәреслекләрдә үсеш алган, тормыш-көнкүрештә дә киң кулланылыш тапкан.

**Кулланылган әдәбият**


1. Л. С. Атанасян, В. Ф. Бутузов, С. В. Кадомцев «Геометрия», татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 7–9нчы сыйныфлары өчен дәреслек, Казан, «Мәгариф» нәшрияты, 2013 ел.
2. В. Беркутов «Каюм Насыйри һәм математика», «Мәгариф», 2008 ел, № 7.
3. Н. Я. Виленкин, В. И. Жохов «Математика», 5нчесыйныфдәреслеге, Казан, «Мәгариф» нәшрияты, 2005 ел.
4. Каюм Насыйри «Сайланма әсәрләр», Таткингоиздат матур әдәбият редакциясе, 1956 ел.
5. Каюм Насыйри «Сайланма әсәрләр», 1 том, Казан, Татарсан китап нәшрияты, 1974 ел.
6. М. И. Моро, С. И. Волкова»Математика», 1нче сыйныф, татар телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе өчен дәреслек, 2 кисәктә, Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2011 ел.
7. М. И. Моро, С. И. Волкова «Математика», 2 нче сыйныф, татар телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе өчен дәреслек, 2 кисәктә, Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2011 ел.
8. М. И. Моро, С. И. Волкова «Математика», 3 нче сыйныф, татар телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе өчен дәреслек, 2 кисәктә, Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2013 ел.


## БУЫННАН БУЫНГА КҮЧКӘН ҮГЕТ-НӘСЫЙХӘТЛӘР


**Хәйруллина Айсылу Расим кызы**

*Казан шәһәре «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 71нче татар-рус урта гомуми белем мәктәбе» Туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучысы*


Һәр халыкның тарихи үсешендә тирән эз калдырган данлыклы уллары, кешелек бәхете өчен көрәшкә зур өлеш керткән галим һәм әдипләре була. Каюм Насыйри – татар халкының әнә шундый олы хөрмәтенә лаек булган күренекле мәгърифәтче галиме. Каюм Насыйриның эшчәнлеге – милләткә фидакарьләрчә хезмәт итүнең бөек бер үрнәге. Аның китаплары – хәзерге милли тормышыбыз өчен дә аваздаш булган бай хәзинә. Февраль аенда без аның тууына 200 еллыгын билгеләп уздык. Мәктәбебездә 9 нчы тапкыр халкыбызның бөек мәгърифәтчеләренә багышлап уздырылучы конференциядә мәгърифәтче, галим, фикер иясе, тәрҗемәче, язучы, фольклорчы Каюм Насыйрига багышлануы очраклы түгел. Шул нисбәттән мин «Буыннан буынга күчкән үгет-нәсыйхәтләр» дип исемләнгән фәнни – эзләнү эше башкарырга булдым.

Бөек мәгърифәтченең «Кырык бакча» әсәрендәге үгет-нәсыйхәтләре, педагогик өйрәтүләре яшәү өлгесе булырга тиешлеген күрсәтүне максат итеп куйдым. Аның һәр бакчадагы нәсыйхәтләре безнең буын кешесе өчен дә зур әһәмияткә ия. Минем хезмәтемнең актуальлеге дә шунда.

Эзләнү эшемне башкарганда, мин төрле чыганаклардан файдаландым. Үземә кирәкле материалны мәктәп, шәһәр китапханәләреннән алдым. Иң беренче эш итеп Каюм Насыйриның Казан китап нәшриятында 2003 нче елда дөнья күргән сайланма әсәрләре белән таныштым.

Тикшеренүнең методологик нигезен күренекле галимнәребезнең фәнни хезмәтләре тәшкил итә. Эш барышында Ләйлә Минһаҗева, Фәнис Исламовның фәнни карашлары киң файдаланылды.

Каюм Насыйриның көчле шәхес, зур галим буларак өлгерүендә ата– бабасының тәэсире, туган йортта алган тәрбиясе мөһим роль уйнаган. Галим үзе язганча, эш сөчәнлек һәм максатка ирешүдә тырышлык күрсәтү этисе биргән тәрбиясенең нәтиҗәсе булган: «Һәр бәндәгә итҗиһад лазем эш, дип балаларына даим ирештерер иде».

Каюм Насыйриның әдәби мирасы киң колачлы һәм күпкырлы, һәр әсәрен саный китсәң, озын бер исемлек булыр иде. Шуңа да әдәби хезмәтләрен ким дигәндә өч зур төркемгә бүлеп карасак дөрес булыр.

1.Мәшһүр Шәрык романнарының иҗади тәрҗемәләре: «Кырык вәзир» (1868), «Әбүгалисина кыйссасы» (1872), «Кабуснамә» (1882), «Җәваһирел-хикәят» (1884), «Әфсанаи Гөлрух вә Камәрҗан» (1896).

2.Төрле Шәрык чыганакларына нигезләнеп үзе төзегән ктаплар: «Мәҗмәгыль-әхбар» (1960), «Кырык бакча» (1880), «Фәвакиһел-җөләса фил әдәбият» (1884), «Китаб әт– тәрбия» (1891)

3.Үзенең шәхси иҗат җимешләре: «Сәфәр» (1895) сәяхәтнамәсе, публицистик нәсер, этнографик һәм библиографик язмалар, әдәби тәнкыйть материаллары, күпсанлы географик һәм тарихи очерклар.

«Кырык бакча»ның тулыландырылган варианты буларак «Фәвакиһел җөләса фил-әдәбият» («Әдәбият турындагы мәҗлесләрнең җимешләре») әсәре язылa. 1884 елда бастырылып чыккан китапта шәрыктән кергән гыйбрәтле, афористик яңгырашлы фикерләр «хаким» исеме белән китерелә. Алар туган як, татар халкына хас әйтемнәр, мәкальләр, гыйбарәләр белән баетып, тулыландырыла.

Сүзебезне «Кырык бакча» исемле китабыннан башлыйк. «Кырык бакча»ның башлам өлешеннән үк үзгә китап булуын чамаларга була. Әдәп гыйлеменә багышланган бу китап мәсьәләне бик тирәннән, «орлык, күзәнәк»халәтеннән башлап җибәрә. Кереш бүлегендә автор, күрәсең медицина чыганакларына таянып, адәм баласының орлык, бер тамчы халәтеннән ана карынында ничек яралуын, тугыз ай дәвамында нинди үсеш дәрәҗәләре кичерүен җентекле, әмма гаять аңлаешлы рәвештә бәян итеп бирә. Инде бала тугач, җиң сызганып бакчачылык – тәрбия эшенә күчәргә була ди, ягъни инде җан «үсентесен» мәдәният туфрагына утыртырга вакыт килеп җитә. Күрәбез ки, кеше җаны бакчадагы агач кебек – ничек итеп һәм нинди җимеш бирүе тәрбиягә бәйле. «Кырык бакча» китабы исеменә туры килерлек рәвештә кырык бүлектән тора, һәр бүлек бакча буларак күрсәтелгән, һәр бакчаның үз нәүбәтендә үзенең аерым исеме бар. Әйтик: «Акыл», «Гыйлем», «Әдәп», «Турылык», «Наданлык», «Ахмаклык», «Куркаклык» һ.б. Шул рәвешле бакчадан бакчага йортеп, әле үрнәк булырдай өлге күрсәтеп, әле гыйбрәт-сабак биреп, укучысының аңында «Әдәп иясе – камил шәхес» образын формалаштырырга омтыла.

Әсәрдә нәсыйхәт кенә түгел, бәлки укучының кызыксынуын үстереп җибәрерлек, көлкеле рухтагы әсәрләр, сатира, ирония дә уңышлы кулланыла, унынчы, ундүртенче, егерме дүртенче бакчаларда бу аеруча күренә.

Каюм Насыйриның мирасы – утта янмас, суда батмас, мәңге тутыкмас могҗизалы бер гәүһәр. Аның исеме бүгенге көн укучысына яхшы таныш. Шул ук вакытта, минемчә, аның шәхесен, иҗатын, алдагы буыннарга йогынтысын – бөтен тирәнлектә аңлап бетерү җитми кебек. Бу очракта мин әлеге бөек шәхеснең иҗат мирасын барлау, аңа даими мөрәҗәгать итеп тору һәм алдагы буыннарга да җиткерү кирәклеген тагын бер кат искәртәсем килә.

# ПЕДАГОГИЧЕСКОЕ НАСЛЕДИЕ ВЕЛИКИХ ТАТАРСКИХ ПРОСВЕТИТЕЛЕЙ И ПЕДАГОГОВ. КАЮМ НАСЫРИ

**Чичканова Гузель Раисовна**
*МБОУ «Гимназия № 184» г. Казань*
*Учитель изобразительного искусства*

Объект исследования: Педагогическое наследие Каюма Насыри, выдающегося татарского просветителя и педагога XIX века, включает в себя его идеи, методы и подходы к обучению, а также влияние на развитие татарского образования и культуры. Насыри акцентировал внимание на важности светского образования, стремился к обновлению традиционных методов преподавания и внедрению новых образовательных технологий. Его работы способствовали формированию национального самосознания и культурной идентичности татарского народа, а также развитию педагогической мысли в контексте исламской и светской традиций. Исследование его наследия позволяет понять, как идеи Насыри повлияли на образовательные процессы и социальные изменения в татарском обществе.

Актуальность исследования: Актуальность исследования педагогического наследия великих татарских просветителей, в частности Каюма Насыри, обусловлена несколькими ключевыми факторами, которые подчеркивают важность данной темы в контексте современного образовательного процесса и культурного наследия.

Во-первых, в условиях глобализации и стремительного изменения образовательных стандартов, особое внимание к национальным образовательным традициям становится необходимым. Каюм Насыри, как один из ведущих татарских педагогов XIX века, внес значительный вклад в развитие национального образования и просвещения. Его идеи о важности родного языка в обучении, а также о необходимости сочетания традиционных и современных методов преподавания, остаются актуальными и в современном образовательном контексте. Статистические данные показывают, что в России, по состоянию на 2021 год, более 5 миллионов человек являются носителями татарского языка, что подчеркивает необходимость сохранения и развития татарского образования.

Во-вторых, наследие Каюма Насыри актуально в свете современных вызовов, связанных с идентичностью и культурной самобытностью. В условиях глобализации, когда происходит размывание культурных границ, изучение и внедрение педагогических принципов Насыри может способствовать укреплению национальной идентичности среди молодежи. Исследования показывают, что молодежь, имеющая доступ к культурным и образовательным традициям своего народа, демонстрирует более высокий уровень патриотизма и социальной ответственности.

В-третьих, современные образовательные системы все чаще обращаются к инклюзивным методам обучения и индивидуализации образовательного процесса. Идеи Насыри о необходимости учитывать индивидуальные особенности учащихся и их культурный контекст могут служить основой для разработки новых подходов в педагогике. В 2020 году более 60% образовательных учреждений в России начали внедрять инклюзивные практики, что подчеркивает необходимость изучения исторического опыта в этой области.

Цели исследования: Исследовать идеи и методы Каюма Насыри в контексте светского образования, выявить их влияние на развитие педагогической мысли и культурной идентичности татарского народа, а также обосновать его подходы к обновлению традиционных методов преподавания и внедрению новых образовательных технологий.

Задачи исследования: Изучить основные идеи и методы Каюма Насыри, анализируя его работы и педагогическую деятельность в контексте светского образования и культурной идентичности татарского народа.

Таким образом, исследование педагогического наследия Каюма Насыри не только актуально, но и необходимо для понимания современных образовательных процессов, сохранения куль-

турной идентичности и разработки эффективных методов преподавания, что подчеркивает его значимость в контексте сегодняшнего дня.

Каюм Насыри, выдающийся татарский педагог, философ и просветитель XIX века, оставил значительное наследие в области образования и воспитания. Его основные идеи сосредоточены на необходимости гармоничного развития личности, где важное место занимает как интеллектуальное, так и нравственное воспитание. Насыри подчеркивал важность образования для всех слоев населения, считая, что доступ к знаниям должен быть равным, независимо от социального статуса или происхождения. Он выступал за внедрение светского образования, которое бы сочетало в себе как традиционные исламские знания, так и современные научные дисциплины.

Методы, которые использовал Насыри, включали активное вовлечение учащихся в процесс обучения, использование наглядных материалов и практических занятий, что способствовало лучшему усвоению знаний. Он также акцентировал внимание на необходимости критического мышления и самостоятельного анализа информации, что было новаторским подходом для его времени. Важным аспектом его педагогической философии было воспитание в учащихся чувства ответственности и патриотизма, что, по его мнению, способствовало формированию сознательных граждан.

Каюм Насыри также акцентировал внимание на роли учителя как наставника и guide, который не только передает знания, но и формирует личность ученика. Он считал, что учитель должен быть примером для своих учеников, демонстрируя высокие моральные и этические стандарты. В его работах можно найти идеи о необходимости постоянного саморазвития и повышения квалификации педагогов, что подчеркивало его стремление к качественному образованию.

Таким образом, педагогическое наследие Каюма Насыри включает в себя не только теоретические идеи, но и практические методы, которые остаются актуальными и в современном образовательном процессе. Его подходы к обучению и воспитанию продолжают вдохновлять педагогов, стремящихся создать более инклюзивную и эффективную образовательную среду. Каюм Насыри также поднимал вопросы о важности культурной идентичности и сохранения языка как основного средства передачи знаний и традиций. Он считал, что язык является неотъемлемой частью воспитания, и его использование в образовательном процессе способствует формированию национального самосознания. Насыри активно выступал за развитие татарского языка и литературы, что способствовало укреплению культурной основы народа.

В своих работах он обращал внимание на необходимость интеграции различных образовательных подходов, что позволило бы создать более разнообразную и многогранную образовательную систему. Насыри предлагал использовать элементы народной педагогики, адаптируя их к современным условиям, что делало обучение более доступным и понятным для учащихся.

Кроме того, он подчеркивал значимость сотрудничества между школами и обществом, считая, что образовательные учреждения должны активно взаимодействовать с родителями и местными сообществами. Это взаимодействие, по его мнению, способствовало бы не только улучшению качества образования, но и укреплению социальных связей в обществе.

Таким образом, влияние Каюма Насыри на светское образование и культурную идентичность татарского народа проявилось не только в его педагогических методах, но и в широкой культурной и социальной деятельности, направленной на просвещение и развитие татарского общества. Его наследие продолжает жить и по сей день, являясь важным элементом в формировании татарской идентичности и культурного наследия.Каюм Насыри не только внедрил новые подходы в образование, но и стал символом стремления татарского народа к самосознанию и культурной автономии. Его идеи о необходимости светского образования как инструмента для социального и культурного прогресса оказали глубокое влияние на последующие поколения. Он понимал, что образование – это не просто передача знаний, но и способ формирования личности, способной к критическому мышлению и активному участию в жизни общества.

# ТУГАН ТЕЛ ҺӘМ ӘДӘБИЯТНЫ ӨЙРӘНГӘНДӘ ЗАМАНЧА ТЕХНОЛОГИЯЛӘРНЕ КУЛЛАНУ

## БАШЛАНГЫЧ КЛАССЛАРДА ТУГАН ТЕЛ (ТАТАР ТЕЛЕ) ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ЗАМАНЧА ТЕХНОЛОГИЯЛӘР КУЛЛАНУ

**Әүхәдиева Сөмбелә Салих кызы**
*Казан шәһәре «Татар телендә белем бирүче 155 нче гимназия»*
*Югары квалификацион категорияле башлангыч класслар укытучысы*

Заман укыту-тәрбия эшчәнлегенең барлык тармагына да үзгәрешләр кертә. Бүгенге җәмгыятькә фәннәрне яхшы үзләштергән, иҗади фикерләүче һәм үз белемен мөстәкыйль рәвештә өзлексез күтәрә белүче, киләчәген алдан күргән, планлаштыра алган, тормышка ашыру юлларын ачык төсмерләгән, көндәшлеккә сәләтле кешеләр кирәк. Мәктәпләрдә шундый шәхес тәрбияләүгә укучыга юнәлдерелгән яңа педагогик технологияләр куллану ярдәм итә. Бөтендөнья белем бирү процессының мөһим һәм тотрыклы тармагы – белем бирүдә заманча информацион технологияләр куллану. Соңгы елларда илебезнең мәктәпләрендә күп кенә предметлардан белем бирүдә компьютер техникасы һәм башка информацион технологияләр ешрак кулланыла.

Теманың максаты: белем бирү сыйфатын күтәрүдә заманча технологияләр куллануны ачыклау.

Максатка ирешү өчен, түбәндәге бурычларны куйдым:

– фәнни-методик әдәбият белән танышу;
– заманча технологияләрне куллану мөмкинлекләрен ачыклау;
– компьютер технологиясенең практикада куллануның нәтиҗәлелеген билгеләү.

Бу эшемне язар алдыннан, мин А. З. Рәхимов, Ф. Ф. Харисов, К. С. Фәтхуллова һ.б. хезмәтләрен өйрәндем.

Бүгенге көндә уку-укыту эшчәнлеге заманча технологияләрдән башка була алмый. Татар теленә, әдәби әсәрләргә карата кызыксыну уяту кече яшьтән үк, балалар бакчасыннан, гаиләдән башланса, ныклы эшчәнлек башлангыч сыйныфлардан башлана.

Башлангыч класларда укучыларны татар теленә өйрәткәндә, заманча технологияләрне файдалануның мөһим бурычлары булып түбәндәгеләр санала:

– укучыда өйрәнелә торган фәнгә карата кызыксыну уяту;
– укучының танып– белү активлыгын арттыру;
– тел өйрәнү өчен уңайлы шартлар булдыру, аралашу вакытында үзара ярдәмләшү мохите тудыру;
– укучының иҗади мөмкинлекләрен тулырак ачу, алган белемнәрен тирәнәйтү инициативасын тагын да үстерү.

Мин, башлангыч класслар укытучысы, үземнең эш тәҗрибәмдә түбәндәге заманча технологияләрне, аларның элеменларын кулланам:

1) уен технологиясе;
2) компьютер технологияләре.
3) мәгълүмати-коммуникатив технологияләр;
4) проект технологиясе;
5) үстерешле укыту технологияләре;
6) сәламәтлекне саклауга юнәлтелгән технологияләр;
7) проблемалы укыту технологиясе;
8) иҗади үсеш технологиясе.

2005 нче елда миңа профессор Әхмәт Зәки улы Рәхимов уткәргән семинарда катнашырга туры килде, һәм аның белән бергә семинарда катнашучылар өчен ачык дәрес күрсәттем. Шул коннән мин Рәхимов технологиясе, «Укучыларның иҗади фикерләвен үстерү технологиясе» элементларын да эш тәҗрибәмдә кулланам.

Дәресләр өчен ясалган презентацияләр проблемалы ситуацияләр тудыруда, белемнәрне актуальләштерү, яңа белемнәрне ачуда, зур экранда сурәтләнгән күрсәтмә материал башлангыч класс укучылары өчен яңа дәресне тиз үзләштерергә ярдәм итә.

Шулай ук балаларның иҗади сәләтләрен, туган телдә язма һәм телдән сөйләм телләрен үстерү максаты белән татар теле һәм уку дәресләрендә «Сабантуй» журналыннан алынган шигырь, мәкаләләр өстендә төрле күнегүләр үткәрәм.

Белем бирүдә заманча технологияләрне куллану ул – әхлаклы кеше тәрбияләү, педагогик технологияләр булдыруда фәннең роле арту, өйрәнгәнне тормышта куллана белү һәм башкалар.

Дәресләремдә заманча технологияләрне кулланып мин түбәндәге нәтиҗәләргә ирешә алдым дип уйлыйм: укучыларның сөйләм теле яхшыра, сүзлек запасы байый; компьютер технологияләре куллану уку эшчәнлеген тагын да баетты; укучыларның иҗади эшчәнлеге артты.

Эшемнең нәтиҗәсе буларак укыткан укучыларым дәрескә кызыксынып, теләп йөриләр, ачык дәресләрдә, шигырь сөйләүчеләр бәйгеләрендә, конференцияләрдә актив катнашалар, призлы урыннар алалар. Быелгы уку елында да ике укучым татар телендә проект эшләп, «Россия династиясе» бәйгесендә катнашып, 1нче һәм 2 нче урыннарны алдылар. Йолдыз Шәрапова иҗаты буенча уздырылган «Тәмле сүзләр» шигырь бәйгесендә җиңүчеләр булдылар. Һәр елны шәһәр олимпиада үзәге оештырган «Без булдырабыз» дигән татар теленнән олимпиадада, республикакүләм оештырылган «Тукай безнең күңелләрдә» иҗат бәйгесендә катнашып, призлы урыннарга ия булалар. Укучыларым гимназиядә уткәрелгән барлык чараларда саф татар телендә чыгыш ясыйлар, класс белән җыр түгәрәгенә йориләр, татарча җырлар ойрәнәләр. Билгеле, бу эштә әти-әниләрнең дә ярдәме зур. Алар да гаиләдә татарча сөйләшергә тырышалар, татар теле белән кызыксыналар.

Киләчәккә дә төп бурычым – яңа технологияләрне дәрестә куллану, иҗади үсешне тәэмин итүче методик әдәбиятны өйрәнү, эзләнү эшчәнлеген дәвам итү.

## ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ КРЕАТИВ ҺӘМ ТӘНКЫЙДИ ФИКЕРЛӘҮНЕ ҮСТЕРҮДӘ НӘТИҖӘЛЕ АЛЫМНАР

**Гарифуллина Дилбәр Рафак кызы**
**Нәҗмиева Гөлнар Ленар кызы**
*Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы*
*муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*«Күбәк урта гомуми белем бирү мәктәбе» нең*
*Югары квалификация категорияле*
*татар теле һәм әдәбияты укытучылары*

Бүген җәмгыятьтә укыту һәм тәрбиянең яңа төрләрен эзләү, аларны куллану зарурлыгы бик нык сизелә. Заманча укытучыдан бүген югары креативлык, иҗади активлык һәм технологик әзерлек сорала. Чөнки заманча фикерләүгә омтылган укытучы гына укучысын үз фикере, бәясе, үзенә генә хас тормыш тәҗрибәсе булган, иҗади сәләткә ия шәхес итеп тәрбияли ала. Укытучы бүген, эш стилен үзгәртеп, яңача эшләргә омтылырга, төрле фәннәрне укытуда кулланыла торган алымнарны үз фәненә яраклаштырып куллана белергә дә тиеш.

Креатив фикер йөртү һәм тәнкыйди фикерләү – бу ике мөһим процесс, алар шәхеснең иҗади һәм аналитик сәләтләрен үстерү өчен кирәк. Аларның һәрберсе үзенчәлекле, ләкин бер-берсен тулыландыра.

Креатив фикер йөртү һәм тәнкыйди фикерләүне берләштерү проблемаларны чишүдә эффективлыкны арттыра. Мәсәлән, креатив фикер йөртү аша табылган идеяләрне тәнкыйди фикерләү ярдәмендә анализлап, аларның гамәли мөмкинлекләрен бәяләү; иҗади чишелешләр уйлап табу һәм аларны тәнкыйди анализлау ярдәмендә иң яхшы вариантны сайлау.

Хәзерге укучыны нәрсә белән кызыксындырырга? Бүген укытучы алдында, төп сорау булып, менә шушы сорау тора. Укытучының бурычы – яңалыклар агымында югалып калмыйча, дәрес юнәлеш алу, укытуның һәр этабы өчен уку материалын аңлатуның иң уңышлы вариантын табу. Һәм ул методик вариантлар һәр укытучының педагогик биштәрендә күптөрле.

Теләгән нәтиҗәгә килү өчен, нинди кызыклы алымнарны кулланырга мөмкин?

**1. Парадоксаль бәйләнешләр.**

ТРИЗ – методикасы мастеры Г. И. Ивановның «Связи» – «Бәйләнешләр» универсаль алымы нәрсә формалаштыра: системадагы объектлар арасында бәйләнеш таба белү; бер-берсенә бәйле булмаган объектлар чылбырын төзү юлы белән объектлар арасында бәйләнеш урнаштыра белү; теләсә нинди объект арасында элемтә урнаштыра белү.

Бу алым ничек эшли? Укытучы беренче карашка үзара берничек тә бәйләнмәгән ике объект бирә (яки укучылар сайлый) (вариант буларак, объектлар очраклы рәвештә, мәсәлән, кубик ярдәмендә сайлана). Балалар объектлар һәм алар арасындагы үзара бәйләнешләр чылбырын беренче үзара бәйләнеш башлангыч объектларның берсеннән башланып, соңгысы икенче объект белән тәмамланырлык итеп төзиләр.

Бу алым укыту – тәрбия мәсьәләләрен хәл итүгә юнәлтелгән, конкрет төзелеше, реаль һәм уйлап табылган кызыклы герое булган иҗади уңыш техникасы. Шул ук вакытта, укучының креатив фикер үсешенә тәэсир итүче көчле иструмент. Шуны да әйтү ассызыкларга кирәк: парадоксаль бәйләнешләр алымы Дэвид Армстронгның коммуникатив компетенцияне формалаштыру чарасы булган сторителлинг алымына якын тора.

**2. Инновацион технологияләрнең берсе – үзлектән танышу өчен дәрес материалын алдан биреп укыту (русча варианты «Перевернутый урок (класс)».**

Укучы белән укытучы арасында аралашу шәхси сайт, шәхси блог, «ВКонтакте» социаль челтәре, электрон почталар, белем бирү процессында катнашучылар белән аралашу һәм видеоконференц-элемтә (онлайн-дәресләр, онлайн-җыелышлар, онлайн-трансляцияләр, онлайн-класс сәгатьләре һәм башка чаралар) уздыру өчен түләүсез «Сферум» платформасы аша башкарыла.

«ВКонтакте» социаль челтәре, «Сферум» платформасы аша укучылар белән эшләү укытучы өчен күпкә кулай. Интерактив эш битләре (ИРЛ) кулланып та бу эшне бик җиңел башкарырга мөмкин.

***«ВКонтакте» да язучы яисә әдәби герой бите» алымы.***

Бу алым укучыларның уку компетенциясен формалаштыру өчен шартлар тудырып кына калмый, бәлки аларны гадәти булган аралашу өлкәсен куллану аша татар телен һәм әдәбиятын өйрәнүгә кызыксыну уятырга, уртак коллектив проектлар эшләргә, шулай ук иҗади потенциалны цифрлы форматта үстерергә мөмкинлек бирә.

«Сферум» платформасы аша өй эше бирү.

«Дөрес марафон» ул – укучылар үзләре тудыра торган видео – дәресләр сериясе. Укучылар үзләрен укытучы ролендә сынап карый, дәрестә үтелгән материалны сөйли, өстәмә чыганаклардан алынган мәгълүматларны китерә. Мондый марафон гаять зур материалны искә төшерергә һәм системалаштырырга мөмкинлек бирә. Иң мөһиме – бу алым укучыларның коммуникатив күнекмәләрен һәм креатив фикерләүләрен камилләштерә.

«Әдәби әсәрне табып бир».

Табышмаклар – өй эше биргәндә, аны төрлеләндерүнең гади һәм креатив ысулларының берсе.

«Сферум» VK мессенджерында укучылар өчен ачылган чатта укучыларга дәрестә үтелгән яки дәрестән тыш вакытта укылган әдәби әсәрне шифрлар ярдәмендә бирергә кушыла. Укучы теләсә нинди ысулны да куллана ала. Мәсәлән, шигырь, сүз болыты, мемнар аша, смайликлар эзлеклелеге, инфографика – монда чикләүләр юк. Бу бирем бигрәк тә уку елы яки яртыеллык ахырында актуаль.

«Бер минутлык сөйләм».

Укучыларга тема буенча кызыклы факт, кызыклы һәм өстәмә мәгълүматны сыйдырган бер минутлык сөйләм төзергә кушыла. Мондый биремне аудиохәбәр форматында яисә «Сферум» чатындагы видеотүгәрәк аша башкарырга мөмкин. Видеотүгәрәк – ул өч минутка кадәрге кыска видео, аны төрле формаларда төшерергә мөмкин. Мәсәлән, түгәрәк, йөрәк, йолдыз яки квадрат рәвешендә.

Мондый формат, бер яктан, укучыга фән нигезләрен теләп үзләштерергә һәм кызыксынуын, мотивациясен, сөйләмне үстерергә мөмкинлек бирә; икенче яктан укучы камера алдында үзен тотарга өйрәнә.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, баланың фәнне кызыксынып өйрәнүе укытучы шәхесенә бәйле. Укытучы үз фәнен никадәр яратса, белсә, ул аны укучыларына тапшыру юлларын эзли һәм нәтиҗәле юллар, алымнар таба. Татар теле һәм әдәбиятын укытуны камилләштерүнең чиге юк, фәкать эзләнергә, яңалыкка омтылырга, билгеләнгән максатка кыю барырга гына кирәк. Йомгак итеп, шуны әйтәсе килә: мөстәкыйль фикер йөртергә, коллективта үз фикерен әйтә белгән бала беркайда да югалып калмый. Укучылар эшчәнлеген оештырганда, без дә һәр дәрестә креатив һәм тәнкыйди фикерләүне үстерүгә зур игътибар бирергә омтылабыз.

Дәрестә генә түгел, дәрестән тыш чараларда да бу юнәлештә эшләүнең мөмкинлекләре күп. Алардан уңышлы файдалану гына кирәк! Эзләнүләр көчле булса, табышы да була… «Кешене гомер буе өйрәтеп булмый, аны гомер буе өйрәнергә өйрәтергә кирәк», – дигән К. Д. Ушинский. Һәм без шушы принциптан чыгып эш йөрттек тә!

## БӨЕК ТАТАП ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ ПЕДАГОГИК КАРАШЛАРЫ

**Зәбирова Эльмира Шафигулла кызы**
*МБОУ Арча икенче урта мәктәбе*
*Туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучысы*

Мин Арчаның икенче мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты дәресләрен алып барам. Үземнең эш тәҗрибәмнән чыгып шундый нәтиҗәләргә килдем:

– Әгәр балагыз ике тел белүен телисез икән, кечкенәдән авыр була дигән сүзләр белән икеләнмәгез. Бала кечерәк булган саен телне җиңелрәк өйрәнә, бу аның өчен бернинди кыенлык та тудырмый. Сөйләшә башлаган гына балага икенче телне өйрәтү ярый гына түгел, ә кирәк тә. Чөнки ул яшендә бала авазларны ишетеп, үзе дә шуларны кабатларга, аларга ошатырга тырыша, ягъни анда аваздашлык процессы бара. Телне өйрәнүнең иң табигый юлы-аваздашлык. Ә бу аваздашлык балаларга гына хас күренеш.

– Бала үз телен дә, чит телне дә тигез дәрәҗәдә белсен дисәгез, аның ике телдә дә бер үк күләмдә аралашуын тәэмин итегез. Балачакта тел өйрәнү җиңел, ләкин кабатламаган очракта белгән дә тиз онытыла. Телне өйрәнү генә түгел, саклый белергә дә кирәк.

– Балагызны мәҗбүриләмәгез, телләргә карата нәфрәт уятмагыз, киресенчә, кызыксындырыгыз.Тел белән беррәттән халыкның мәдәнияте белән таныштырыгыз.

Тел өйрәнүне нәрсәдән башларга?

– Балагызга чит телдә җырлар тыңлатыгыз!

– Рәсемле сүзлекләр белән кызыксындырыгыз. Китапның битендә берничә рәсем булса, тагын да әйбәтрәк.

– Чит телдә мультфильмнар карагыз.

– Туганнарыгыз, дусларыгыз белән сезгә кунакка килгәч, бала белән чит телдә сөйләшүләрен сорагыз.

# ПРИМЕНЕНИЕ ИННОВАЦИОННЫХ ТЕХНОЛОГИЙ ДЛЯ РАЗВИТИЯ КОММУНИКАТИВНЫХ СПОСОБНОСТЕЙ У УЧАЩИХСЯ НА УРОКАХ РОДНОГО (ТАТАРСКОГО) ЯЗЫКА И ЛИТЕРАТУРЫ

**Звягина Мадина Абдулхаевна**
*МБОУ «Гимназия № 7 имени Героя России А. В. Козина»*
*Ново-Савиновского района г. Казани*
*Учитель родного (татарского) языка и литературы*

В настоящее время школа, как и все образование в целом, повернулась к личности ученика и пытается создать все условия для становления его как субъекта жизни.

При изучении любого языка мира человек старается научиться его коммуникативной деятельности. Поэтому, я работаю над методической темой «Применение инновационных технологий для развития коммуникативных способностей у учащихся на уроках татарского языка и литературы».

В последние годы все чаще поднимается вопрос о применении новых технологий в средней школе. Это не только технические средства, но и методы преподавания, новый подход к процессу обучения. Основной целью обучения татарскому языку как иностранному, является формирование, развитие коммуникативной деятельности школьников и обучение практическому овладению языком.

В современном мире слово «инновация» глубоко укоренилась в нашей повседневной жизни. Рассмотрим значение, термин «инновация» относительно молод и, соответственно, существуют разные подходы к определению данного понятия.

В широком смысле слова под инновационной деятельностью понимается деятельность, направленная на поиск и реализацию чего-то нового в целях совершенствования чего-либо.

Применительно к педагогическому процессу инновация означает введение нового в цели, содержание, формы и методы обучения студентов.

- интерактивные уроки с использованием компьютерных технологий;
- проектное обучение;
- виртуальная реальность;
- смешанное обучен;
- проблемно-ориентированное обучение и другие.

Эффективность применения информационных технологий на уроках татарского языка не подлежит сомнению. В числе преимуществ их использования в качестве средств обучения можно назвать субъектную ориентацию, гибкость и вариативность. Компьютерные технологии помогают повысить уровень преподавания, обеспечивая наглядность, контроль, большой объем информации, являясь, наконец, стимулом в обучении.

Освоение компьютерных технологий позволяет реально индивидуализировать учебный процесс, сделать его более гуманным по отношению к учащемуся, усилить положительную мотивацию обучения, активизировать познавательную деятельность, усилить творческую составляющую работы как ученика, так и учителя.

Можно сказать, что внедрение современных технологий в процесс обучения языков не только положительно влияет на образовательный процесс, но и является необходимостью современного мира при том, что смартфоны на сегодняшний день являются частью нашей жизни.

В современном процессе образования также широко используется метод проектов, который был введен в Россию в 20–30-х годах прошлого столетия. Этот метод используется нами при изучении татарского языка.

Проект – замысел переустройства того или иного участка действительности согласно определенным правилам. Проектная деятельность осуществляется на учебном и внеклассном материале.

Подытоживая вышесказанное, можно сделать вывод крылатым выражением: «Человек, который почувствовал ветер перемен, должен строить не щит от ветра, а ветряную мельницу». Эти слова стали нашим педагогическим девизом. «Ветер перемен» коснулся и образования. В эпоху стремительного развития высоких технологий, расширения информационного пространства формируется новый тип мышления, меняются требования к личности. Соответственно меняется и учебно-воспитательный процесс. Современному ученику, уже недостаточно и неинтересно, когда единственными источниками информации являются учебники и учитель. Учителя смогут решить эту задачу, используя в своей педагогической деятельности инновационные технологии, каждый из которых несет в себе огромный потенциал.

## ТУГАН ТЕЛ УКЫТУЧЫСЫНЫҢҺӨНӘРИ ПОРТРЕТЫ ҺӘМ КОМПЕТЕНТЛЫЛЫГЫ

**Касыймова Зөһрә Габбас кызы**
*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының*
*«Утар-Аты төп гомуми белем мәктәбе»*
*муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе*
*Югары категорияле туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучысы*

Кешелек дөньясы яңа меңьеллыкның – XXI гасырның беренче чиреген тәмамлап килә. Хәзерге заман мәктәбенең иң зур бурычы – дөньякүләм мәсьәләләр хакында фикер йөртерлек шәхес тәрбияләү. Туган тел укытучылары бу бурычны тагын да киңәйтеп, югары әхлаклы, үз халкының тарихын, мәдәниятен белүче, хөрмәт итүче иҗади шәхес тәрбияләү дип дәвам итә.

«Укытучының һөнәри үсеше» дигән милли система нигезендә, укучыларның белем дәрәҗәсен күрсәтүче фактор булып, мәктәп укытучысының һөнәри сыйфатлары һәм осталыгы тора. Таләпләрне барыбыз да бик яхшы беләбез, алар бик югары. Шушы урында бер сорау куясы килә: без нинди буынга белем һәм тәрбия бирәбез дә, хәзерге заман укучысы башка чор укучысыннан нәрсәсе белән аерыла? Шул ук күзләр, аяк-куллар бит, югыйсә! Юк икән шул, иң кадерлесен-рухи кыйммәтләрне – югалта барабыз түгелме? Әллә нигә бер киеп куйган чигүле күлмәк, калфак-кәләпүш белән генә милли кыйммәтләребезне саклап кала алырбызмы? Сүз дә юк, алары да безнең милли йөзебезне күрсәтеп торучы бизәкләр. Ә баланың күңеленә халкыбызның иң кадерле, иң югары әхлаклылык үрнәге булган рухи кыйммәтләребезне салучылар да без бит-туган тел укытучылары! Яңа буын укытучысы дигән дигән сүз артында, син аның тәрбиячесе дә дигән фикер ята. Мин үземнең төп максатымны әнә шунда күрәм: белем бирүем аша, милләтен, телен, динен-иманын, гореф-гадәтләрен, традицияләрен белгән, хөрмәт иткән буын тәрбияләү. Безгә – туган тел укытучыларына– бик зур вазыйфа салынган. Шуны аңлап эш итсәк иде. Тагын кайсы һөнәр иясе бала күңеленә шулай тәэсир итә ала? Җавап таба алмыйм…

Бүгенге замана укытучысы, минем фикеремчә, холкы белән бик дипломант булырга тиеш. Әйе, без инде күптәннән рәсми булмаган артист, прокурор, табиб, тегүче яки пешерүче… Ләкин укытучы иң элек бала күңелен аңлый белергә тиеш, дип саныйм мин. Каршысында утырган укучының фикерен бернинди югары технологияләр укый алмый, бары тик укытучы гына баланың күзенә, йөзенә туры карап, аның фикеренә юнәлеш бирә ала. Ничек итеп? Үзенең белеме, холык-фигыле, сөйләме, киенүе белән… Әгәр мин: «Мәктәптә иң яраткан фәнегез нинди иде?» – дип сорасам, иң элек Сезнең күз алдыгызга шушы фәнне укыткан укытучы килеп басар. Бу сүзләр бик күпне аңлата…

Яңа буын… Нинди сон ул? Нәрсә белән кызыксына, кем тәрбияли, ничек тәрбияләнә ул? Әхлаклымы, мәдәниятлеме? Туган як, туган тел, милли, дини, гаилә кыйммәтләре турында

фикерләре бармы аның? Дөрес тукланамы, киенү зәвыгы бармы? Рәхмәтле була беләме? Туган тел укытучысы үз укучысының бар ягын күз алдында тотарга бурычлы. Без булмасак, кем соң? Иң беренче чиратта, үзебез укучыга үрнәк булырга тиешбез. Нинди юллар белән бу максатларга ирешеп була, монысын укытучы үз тәҗрибәсенә таянып эшли. Юллар бик күп төрле, омтылыш-максатыбыз уртак безнең!

Иң зур максатыбыз – туган телебезне саклап калу. Иң беренче чиратта безгә ялганнан арынырга кирәк. Үзебезне ялганлаудан, бары тик кемгәдер күрсәтер өчен эшләүдән… Беребезгә дә яшерен түгел, бүген татар авылларында да, балалар бакчасыннан ук, укучыларыбыз рус телендә сөйләшеп, мәктәпләребезгә килеп керәләр. Белем бирүнең бу этабында без нindидер мөһим бер буынны югалттык түгелме? 1–9 сыйныфларда, кисәтү ясый-ясый, без укучыларыбызны телебезгә якынайтабыз, 10–11сыйныфта, техникум-көллиятләрдә фәннәрне укытуга яңадан рус теленә күчәбез. Татар мәктәпләрендә әти-әниләр, Бердәм Дәүләт Имтиханын бирүне сәбәп итеп, русча дәреслекләр белән, белем бирүне русча алып баруны сорыйлар. Безнең бу очракта бер генә дәлилебез бар: телгә ихтыяҗ һәм телне куллану мохите булырга тиеш! Бүгенге көндә әти-әниләр белән элемтә, хәтта, әйтер идем, аңлату эшләре алып бару бик мөһим. Ике телдә сөйләшә белүче баланың акыл эшчәнлеге яхшы формалаша. Туган теленә өйрәнү мөмкинлеге аның генетикасына салынган булуны да әйтә галимнәр.

Федераль белем бирү стандартлары буенча да белем бирү процессында җәмгыять өчен төрле яклап үскән, интеграль шәхесләр тәрбияләү күздә тотыла. Әлеге стандартлар буенча, дәресләрнең структурасы тамырдан үзгәрә, педагогларга карата да зур таләпләр куела. Фән иясе буларак укытучыларның да, укучыларның да компетентлылыгы турында аларның шәхси сыйфаты буларак сөйләшәбез.

Татар теле һәм әдәбияты укытучылары җәмгыятьтә барган үзгәрешләрне авырыксынуларсыз кабул итеп, заман белән бергә атларга тырышалар, заманча укыту технологияләреннән киң файдаланып эш итәләр. Белем һәм тәрбия бирүдә информацион технологияләрнең өстенлек булуы бәхәссез. Дәресләрдә укучыларны өстәмә мәгълүмат белән эшләргә, үзлектән белем алырга өйрәтүгә әһәмият бирелә. Болар барысы да укучының компетентлылык дәрәҗәсен үстерү өчен башкарыла.

Бүген без вакыт бик тиз уза, дөнья аннан да тизрәк үзгәрә, дибез. Минем уйлавымча, шул үзгәрешләргә яраклашу өчен тормыш белән бергә укытучы да үзгәрергә тиеш. Без 5 елдан соң дөнья ничек үзгәрсен, кайсы профессияләрнең юкка чыгып, нинди яңа һөнәрләр барлыкка киләсен белә алмыйбыз. Белем алу юллары да үзгәрә. Бары тик үзе укырга, яңалыкны өйрәнергә яратучы белгеч кенә үз укучыларында гыйлемгә карата мәхәббәт тәрбияли һәм аларның да кызыксынып китеп өйрәнергә керешүләренә ирешә ала. Гыйлемнәрне тирән белү укытучыга үз хезмәтен үтәр өчен кирәк. Гыйлем бирү, укыту эчтәлегенең төп өлеше даими бер төрле булса да, укыту ысуллары заман, мәгърифәт һәм мәдәният таләп иткәнчә тулылана, камилләшә, үсә бара.

Фикеремне йомгаклап, шуны әйтәсем килә: укытучы һөнәре ул – җиһанга яктылык, җылылык иңдерүче кояш нурлары кебек. Мәктәп еллары сизелмичә үтә дә китә, әмма күңелдә укытучыдан иңгән җылылык, мәрхәмәтлелек кала. Җирдә кешеләргә гамьле тормыш алып барыр өчен тәүге адымнарны укытучы өйрәтә, галәмнәрне колачлар өчен канатларны да укытучы куя. Укытучының ялгышырга хакы юк, уйламыйча сүз дә әйтә алмый, чөнки ул һәрвакыт күз өстендә. Күп вакытта артистланырга да туры килә: борчу-кайгыларыңны мәктәпнең тышкы ягында калдырып керәсең, йөрәгеңә бар хәсрәтеңне туплыйсың… Укучылар үз остазларында бары тик ямьлелек, җылылык, яктылык, мәрхәмәтлелек, дөньяны, туган илеңне ярату гына күрергә, шуларны синнән үзләренең чиста, керсез күңелләренә күчерергә тиеш.

# УКУЧЫЛАРНЫ ТАТАР ТЕЛЕНӘ ӨЙРӘТҮ ҺӘМ БЕЛЕМ БИРҮ СЫЙФАТЫН АРТТЫРУ ӨЧЕН ЦИФРЛЫ БЕЛЕМ БИРҮ РЕСУРСЛАРЫН КУЛЛАНУ

**Мөбарәкшина Гөлшат Талиповна**
**Сафиуллина Гольфия Рауфовна**
*Казан шәһәре Совет районы*
*МБББУ «174 нче гимназиянең» нең*
*1 нче категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучылары*

Туган телләрне саклау һәм өйрәнү белән кызыксынуның үсүенә һәм барлыкка килүенә йогынты ясый торган факторлар арасында татар телендә электрон белем бирү ресурсларын (белешмә-мәгълүмати, мәдәни-агарту, фәнни, фәнни-популяр, укыту-методик характердагы) кертүне билгеләп үтәргә кирәк.

Татар телен өйрәнүгә мотивацияне арттыру өчен укытучыга дәресләрне кызыклы, белемле итеп төзергә кирәк. Методик эш өчен укытучы «Мәгърифәт» һәм «Гаилә һәм мәктәп» журналларының берләштерелгән электрон порталын куллана ала. «Мәгариф» журналының электрон версиясе мәктәп укучыларын укыту һәм тәрбияләү процессын оештыру, мәктәптә укыту-тәрбия эшенең сыйфатын күтәрү мәсьәләләрен һәрьяклап яктырта. «Укытучыга ярдәмгә», «Методик кабинет» бүлегендә татар теле укытучысы дәресләрнең, сыйныфтан тыш дәресләрнең, сыйныф сәгатьләренең әзер сценарийларын, методик мәкаләләрне таба ала.

Шулай ук татар теле һәм әдәбияты укытучысының эш нәтиҗәлелеген арттыру, квалификация тәҗрибәсен, белем бирү сыйфатын арттыру өчен татар мәгариф порталы булдырылды: **http://belem.ru/**. Бу порталда укытучы эш өчен материаллар гына түгел, ә дөнья яңалыклары белән дә таныша ала.

Татар әдәбияты дәресләре өчен бай материал түбәндәге адрес буенча урнашкан татар электрон китапханәсендә тәкъдим ителгән: **kitap.net.ru.** Бу халык авыз иҗатыннан алып бүгенге көнгә кадәр булган проза һәм шигъри әсәрләренең иң зур электрон җыентыкларының берсе. Бирелгән тарих, дин, психология, фантастика, тюркология һ. б. материаллар бирелгән. Материал татар һәм рус телләрендә тәкъдим ителгән.

Татар теле укытучысына Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең электрон версиясе дә ярдәмгә килә **(http://kitaphane.tatarstan.ru/)**..

Татар теле дәресендә инновацияле технологияләрне куллану югары нәтиҗәләргә китерә, укучыларда телне өйрәнүгә этәргеч була, мөстәкыйль эшчәнлек күнекмәләрен булдырырга һәм һәр баланың шәхси мөмкинлекләрен ачарга, өлкән сыйныфларда укыячак профильне сайларга ярдәм итә. Эшебезнең **актуальлеге** татар теле дәресләрендә компьютер технологиясе кулланып, укучыларның әлеге предметтан белем сыйфатларын үстерү, татар телендә дөрес һәм иркен аралаша алучы, әхлакый яктан өлгергән шәхес һәм конкурентлыкка сәләтле укучылар тәрбияләүдән гыйбарәт.

Эшнең максаты: Мәктәпнең төп белем программасына, гомуми белем бирү стандартларына нигезләнеп, **компьютер** технологияләре ярдәмендә, татар теле һәм әдәбияты буенча теоретик һәм практик белемнәр бирү

Бирелгән максатка ирешү юлында түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк дип табылды:

– мәктәпнең төп белем программасына, гомуми белем бирү стандартларына нигезләнеп, рус телле укучыларның язма һәм телдән сөйләм күнекмәләре үстерү;

– укучылар белән эшчәнлекне киңәйтү һәм контрольдә тоту максатыннан, виртуаль факультатив һәм шәхси сайт белән эшне алып бару;

– балаларның логик фикерләү сәләтен үстерү.

Укытучының бурычы – яңалыклар агымында югалып калмыйча, дөрес юнәлеш алу, укытучының һәр этабы өчен уку материалын аңлатуның иң уңышлы вариантын табу.

Ләкин шуны да әйтәсебез килә: иң мөһиме баланың компьютердагы эшчәнлегенең максатын ачыкларга; компьютерда эшләү вакытын, интернетны максатчан куллануын контрольдә тотарга кирәк!

Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты белән берлектә татар теле укытучыларына ярдәмгә бала.рф сайты булдырылды.

Мәгариф сыйфатын үстерү максатын алга куеп эшләнгән «БАЛА» дип аталучы мультимедиалы интерактив китапханә туган телне һәм татар әдәбиятын өйрәнүгә юнәлтелгән. Туган тел һәм әдәбияты укытучылары өчен әлеге китапханә татар телен үзләштерү, татар әкиятләрен өйрәнү өчен ярдәмлек, татар телендә эшләнгән мультфильмнар иленә юл күрсәтүче. Әлеге сайтта урнаштырылган татарча мультфильмнарны дәресләрдә дә, сыйныфтан тыш чараларда да нәтиҗәле файдаланабыз.

**http://www.rusedu.ru/, http://metodisty.ru/, http://nsportal.ru/** төрле презентацияләрне шул сайтлардан алырга була. **http://www.openclass.ru/node/224468** сайтында кроссвордлар.

**http://ras2203.narod.ru/** – Татарча мультфильмнар, спектакльләр.

**http://ras2203.narod.ru/shubino-karaoke.htm** – сыйныфтан тыш чаралар үткәргәндә куллану өчен татарча караоке урнаштырылган. Информацион технологияләр укыту-тәрбия эшен оештырганда текстлы, тавышлы, график, видео мәгълүматны яңача кулланырга мөмкинлек бирә. Ә бу үзе укучыларда иҗади эшкә кызыксыну уята һәм активлыгын үстерүгә этәргеч булып тора. Өлкән сыйныфларда презентацияләрне укучылар үзләре дә бик теләп ясый.

Күп куллана торган сайт– *«Ана теле»* ***(http://anatele.ef.com/).***

Шулай ук программада татар сүзләрен диктор укуында тыңлау, әйтеп карау һәм чагыштыру мөмкинлеге бирелгән.

«**Гыйлем**» ***(http://giylem.tatar)*** – татар телендә фән, белем һәм мәгърифәт тарата торган проект. Ул төрле өлкәләргә караган белемне татар телендә яктырта, белем бирү сыйфатын күтәрү өчен, тиешле шартлар тудыра. Монда табигый, техник һәм гуманитар фәннәр буенча мәкаләләр, видеодәресләр, мультфильмнар, аудиоязмалар, плакатлар таба аласыз.

Без укучыларыбызга мобиль җайланмалар өчен чыгарылган кушымталарны (приложения) тәкъдим итәбез. **«Сүзлек»** кушымтасы – русча-татарча һәм татарча-русча сүзлек. Бушка йөкләү һәм урнаштыру каралган.

Смартфон өчен татарча клавиатуралар да бар, аларны **«Татарча яз», «Татар клавиатурасы»** кебек кушымталар аша урнаштырып була.

Интернет безгә күптөрле мөмкинлекләр тудыра. Күңелендә хәерле максатлары булган кешеләр, әлбәттә, дөнья пәрәвезенең файдасын күрер, белем алыр, мәгърифәт атар.

Төрле темага күрсәтмә материаллар һәм укыту ресурсларын бик күп табарга һәм аларны кабат-кабат файдаланырга мөмкин. Бу алым укучыларның белем сыйфатын үстерергә ярдәм итә. Яңа материалны һәр укучыга җиңел, аңлаешлы итеп җиткерергә дә ярдәм итә.

Татар теле һәм уку дәресләрендә Интернет ресурсларны куллану уку, язу күнекмәләрен булдыру һәм үстерү, кирәкле материал табу, укучыларның сүзлек запасын баету, татар телен өйрәнүгә мотив формалаштыру кебек дидактик бурычларны үтәргә мөмкинлек бирә.

Шулай итеп, заманча цифрлы технологияләр татар теле укытучысына нәтиҗәле белем бирү процессы, мотивацияне арттыру, татар телен һәм әдәбиятын өйрәнү белән кызыксыну өчен зур мөмкинлек бирде. Алар ярдәмендә туган телне өйрәнү укучыны тагын да активлаштыра, мөстәкыйльлек тәрбияли, фәнне югары дәрәҗәдә үзләштерү, максатка омтылучанлык, информацион технологияләр дөньясында яңалыклар белән кызыксыну теләге уята.

## ТУГАН ТЕЛ ҺӘМ ӘДӘБИЯТ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ЗАМАНЧА ПРОДУКТИВ ТЕХНОЛОГИЯЛӘР КУЛЛАНУ

**Мөкминова Әлфия Дамир кызы**
*Казан шәһәре МББУ «8 нче гимназия – Мәгариф үзәге»*
*Югары квалификация категорияле туган (татар) тел һәм әдәбияты укытучысы*

Туган тел – милләтнең рухи мирасын саклаучы, аның киләчәген билгеләүче мөһим фактор. Хәзерге заман укытучысы беркайчан да ирешелгәннәргә генә канәгатьләнеп калырга тиеш түгел, ул һәрвакыт алга карарга, заман белән бер сафта барып, гел эзләнеп яшәргә тиеш. XXI гасырда белем бирү системасы тиз үсеш кичерә, шуңа күрә туган телне укытуда инновацион технологияләр куллану бик мөһим. Бу – замана таләбе.

Бу технологияләр уку процессын кызыклырак һәм заманча итәргә, белем бирү өлкәсендә югары сыйфатка ирешергә, өйрәнгән теманы җиңел юл белән үзләштерергә ярдәм итә, укучыларның иҗади сәләтен үстерүгә булыша.

Заманча продуктив технологияләр куллануның өстенлекләре:

– Уку процессын активлаштыра: интерактив такталар, компьютерлар, планшетлар, виртуаль реальлек технологияләре укучыларны актив катнаштыруга, үз алдына эшләүгә, мөстәкыйль фикер йөртүгә өйрәтә.

– Белем бирүне индивидуальләштерә: онлайн платформалар, электрон дәреслекләр һәр укучының үзенчәлекләренә туры китереп белем алу мөмкинлеген бирә. Укучылар үз темпларында эшли ала, катлаулы темаларны кабатлап карарга мөмкинлек ала.

– Уку материалына кызыксынуны арттыра: видеороликлар, аудиоязмалар, анимация, интерактив уеннар уку материалының нәтиҗәлерәк кабул ителүен тәэмин итә.

– Иҗади сәләтне үстерә: компьютер графикасы, видеомонтаж, презентация ясау кебек программалар ярдәмендә укучылар үзләренең иҗади потенциалын ача алалар.

– Мәгълүматка тиз керә: интернет ресурслары ярдәмендә укучылар кирәкле мәгълүматны тиз арада таба алалар.

Белем бирү өлкәсендә югары сыйфатка ирешү, өйрәнгән теманы җиңел юл белән үзләштерергә ярдәм итү, укучыларның иҗади сәләтен үстерүгә булышу максатыннан, үз практикамда мәгълүмати-компьютер, коммуникатив, иҗади үсеш, уен, проблемалы укыту, сәламәтлекне саклауга юнәлтелгән технологияләрне, системалы-эшлекле якын килү алымнарын кулланам. Дәресләрем кызыклы үтсен өчен барлык тырышлыгымны куям.

Бүгенге чыгышымда туган тел һәм әдәбияты дәресләрендә кулланыла торган берничә алымга тукталып китәрмен.

**Зирәклек агачы (Дерево мудрости)** алымы.

«Зирәклек агачы» алымы материалны өйрәнгәндә яки ныгытканда кулланыла. Укучылар текстны мөстәкыйль укыйлар. Аннары туган сорауларны кечкенә битләргә язалар. Кәгазьгә имза куялар һәм кыстыргыч ярдәмендә «Зирәклек агачы»на беркетәләр. Шуннан соң һәркем чиратлашып язуны өзә, сорауны кычкырып укый һәм аңа җавап бирергә тырыша. Калганнар сорауны да, җавапны да бәялиләр.

**Валерий Борисович Эдигей методы.** Башкача әйтсәк, **анаграммалар методы.** Әлеге алымны дәреснең төрле этабында кулланырга була. Терминнарны, кабатлау өчен сүзләрне алырга була.

Балалар дәрестә бу алымны, никадәр генә арыган булсалар да, кызыксынып, яратып кулланалар. Күпчелек укучы расшифровка белән шулкадәр мавыгып китәләр, шуның белән уку тизлеген дә аттыралар.

**«Морфологик тартма» алымы.** Авторы астроном һәм физик Фриц Цвикки. Дәреснең төрле этабында, логик мәсьәләләр чишү өчен, әдәби геройның портретын төзегәндә кулланырга мөмкин.

«Морфологик тартма» бирелгән билгеләр буенча мәгълүмат җыю һәм анализлау, өйрәнелә торган күренешнең әһәмиятле һәм әһәмиятсез билгеләрен ачыклау өчен хезмәт итә. Әлеге алым универсаль, төрле предметларда кулланылырга мөмкин.

Кеше визуаль мәгълүматны яхшырак үзләштерә. Кешеләр күргәннәрнең яки эшләгәннәрнең 80%, укыганнарның 20% һәм ишеткәннәрнең 10% гына сөйлиләр.

**Мәгълүматны визуализацияләү** – мәгълүматны күз алдына китерү, өйрәнү өчен иң эффектив чара. Визуальлекнең кайбер төрләре: «Сүзләр болыты», инфографика, интеллект/менталь карталар.

https://wordscloud.pythonanywhere.com/ сайтында «**Сүзләр болыты**»**н төзибез.**

Укыту процессында дәреснең төрле этапларында «Сүзләр болыты» алымын кулланырга мөмкин. Бу алымнар актив тыңлауны үстерә, сүзлек байлыгын, кызыксынучанлыкны, күзәтүчәнлекне арттыра; телдән сөйләмне үстерә, фикерләү эшчәнлеге нәтиҗәсендә, укучылар бу алымны үтәгәндә актив булалар. Бу алымнар белән укучылар бер-берсен тыңларга өйрәнәләр. Укучыларга сүзтезмәләр, җөмләләр төзергә дигән бирем тәкъдим итәргә була.

**Интеллект карта алымы *(Прием «Mind Map»)***

Интеллектуаль карта –татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә укучыларның фикерләү процессын күзәтү мөмкинлеген бирүче һәм мәгълүмати компетентлыкны тәэмин итүче инновацион алым. Алымның авторы – галим һәм эшмәкәр Тони Бьюзен. Максаты – фикерләү процессын визуальләштерү. Алым кешенең радиант фикерләү теориясенә нигезләнә. Әлеге теория буенча, баш миенә килүче мәгълүматның һәр мизгеле, һәр тоемлау, истәлек, фикер (сүз, сан, хис һ.б.), меңәрләгән «хәтер төене»н тирә-якка таратучы үзәк сферик объект рәвешендә күз алдына китерелә ала.

Алымның өстенлекле яклары: өйрәнелүче объектны модельләштерү укучыларның когнитив фикерләвендә һәм мәгълүматны нәтиҗәле эшкәртә белүендә килеп туган бик күп проблемаларны чишәргә мөмкинлек бирә; гомумуку күнекмәләрен формалаштыра; проблемадан чыгу юлын табарга өйрәтә; танып белү эшчәнлеген тизләтә; хәтернең барлык төрләрен яхшырта; креатив фикерләүне үстерә һ.б. Картаны эшләү өчен төсле карандашлар, маркерлар кулланыла.

Тәнкыйди фикерләү технологиясенең бер алымы булган «**Пирамидалы вакыйга**» **(Пирамидалы хат) алымы.**

Әлеге алымны әсәргә анализ ясаганда кулланырга мөмкин. Бу алым аркылы укучыларның зиһене, хәтере ныгый, уйлау сәләтләре эшкә җигелә. Укучылар үз позицияләрен аргументлар ярдәмендә күрсәтеп, сөйләм эшчәнлекләрен дә эшкә җигә. Сораулар сигез өлештән тора. Һәр баскычтагы сораулар гадидән катлаулыга таба бара. Бу алым нигезендә без әсәрне тагын бер кат күзаллыйбыз. Түбәндәге сораулар нигезендә эшлиләр:

1. Вакыйганың герое кем?/ әсәр кем турында? – 1 сүз.
2. Геройны сурәтләүче ике сыйфатны әйтегез (әсәр турында сурәтләүче ике сыйфатны әйтегез).
3. Вакыйганың урынын, вакытын тасвирлый торган өч-дүрт сүзне әйтегез.
4. Әсәрдәге төп вакыйгалар – 5–6 сүз.
5. Төп геройларны сурәтләүче 7–8 сүз (сүзтезмә).
6. Әсәрнең башында, уртасында, ахырында сез нинди тойгылар кичердегез? (8–9 сүз)
7. Әсәр нәрсә турында? (1 җөмлә)
8. Проблеманы чишүне тасвирлаучы 8 сүз (сүзтезмә). Авторның әйтергә теләгән фикере. Афористик жанр, мәкаль, канатлы сүзләр. Әсәр турында сезнең фикер.

Без җавaплардан пирамида төзибез. Шуңа күрә бу алым «Пирамидалы вакыйга» дип атала да.

Туган телне укытуда инновацион технологияләр куллану уку процессын яхшырта, укучыларның белем дәрәҗәсен күтәрә, аларның иҗади сәләтләрен үстерә. Яңа алымнарны уңышлы куллану өчен укытучыларның профессиональ әзерлеге, заманча технологияләр белән эш итү күнекмәләре югары булуы мөһим. Шулай ук, әлеге алымнар укучыларның фикер йөртү сәләтен үстерүгә юнәлтелгән булырга һәм уку процессын яхшырту чарасы булып торырга тиеш.

# ДЕФОРМАЦИЯЛӘНГӘН ТЕКСТ ӨСТЕНДӘ ЭШ. ФУНКЦИОНАЛЬ ГРАМОТАЛЫЛЫКНЫ ФОРМАЛАШТЫРУ ӨЧЕН БИРЕМНӘР (5–9 НЧЫ СЫЙНЫФ УКУЧЫЛАРЫ ӨЧЕН ДИАГНОСТИК БИРЕМНӘР)

**Нәбиуллина Луиза Зөфәр кызы**
**Низамбиева Раушания Ринат кызы**
*Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе Тирсә урта гомуми белем бирү мәктәбе Туган тел һәм әдәбияты укытучылары*

**Эшнең актуальлеге һәм әһәмияте**. Функциональ яктан белемле шәхес ул – тормышта ориентлашкан һәм рухи кыйммәтләргә ия булган шәхес, сайлау һәм карарлар кабул итү ситуациясендә мөстәкыйль булырга сәләтле кеше. Иң беренче чиратта, укучыларның уку грамоталылыгын формалаштыру әһәмиятле. Уку грамоталылыгы – функциональ грамоталылыкның иң мөһим өлеше.

Текст белән эшләү – кызыклы һәм файдалы эш төре. Укучыларны кирәкле мәгълүматны тексттан алырга һәм аны эшкәртергә өйрәтә. Эш барышында сөйләм, игътибарлылык үсеш ала. Уку грамоталылыгы – язма текстларны уку һәм аңлау, аларның эчтәлеген үз максатларына ирешү, белем һәм мөмкинлекләр үстерү, җәмгыять тормышында актив катнашу сәләте.

Укучыларның сөйләм үсешен формалаштыруга ярдәм итүче чараларның берсе – деформацияләнгән текст белән эшләү. Деформацияләнгән текст – ул үзгәртелгән текст: фикерләрне сөйләү эзлеклелеген бозып, текстны аңламаган ниндидер сүзләрен, җөмләләрен төшереп калдырып яки үзгәртеп күрсәтү. Туган тел дәресләрендә сүзләр, җөмләләр һәм текст деформацияләнгән тел берәмлекләре буларак кулланыла. Укучыларның телдән һәм язма сөйләмен үстерү өчен туган тел дәресләрендә деформацияләнгән текст белән эшләү күнегүләре тәкъдим ителә. Укучыларның сөйләмен үстерү – хәзерге җәмгыятьтә актуаль проблема, чөнки бәйләнешле сөйләм баланы мәктәптә уңышлы укытуның кирәкле шарты булып тора. Сөйләмнең иң мөһим сыйфаты булып эчтәлекне эзлекле, каршылыксыз һәм аргументлы итеп формалаштыра белү тора. Нәкъ менә шуның белән күпчелек укучыларда кыенлыклар туа.

**Эшнең максаты:** татар халкының бөек галиме, мәгърифәтче, язучы Каюм Насыйри тормыш һәм иҗат юлына нигезләнеп эшләнгән деформацияләнгән текстлар ярдәмендә укучыларның функциональ грамоталылык күнекмәләрен үстерүгә нигезләнгән диагностик биремнәр җыелмасы төзү.

**Тикшеренү методлары.** Эшебездә эзләнү, анализлау, чагыштыру методлары кулланылды.

**Эшнең структурасы.** Хезмәтебез кереш, ягъни аңлатмалы язудан, төп (диагностик биремнәрнең үрнәк вариантлары) һәм йомгак өлешләрдән тора. Кереш өлештә телнең деформацияләнгән, ягъни үзгәртелгән тел берәмлеге, деформнар белән эш төрләре күрсәтелде. Төп өлештә 4 вариантта диагностик биремнәр тәкъдим ителә. Хезмәтебез ахырында файдаланылган әдәбият исемлеге күрсәтелде.

Мәктәптә белем бирү процессында текст белән эшләү төре булган, уку эшчәнлегендә кулланыла торган эшчәнлекнең продуктив төрләреннән берсе булып деформацияләнгән текстлар белән эшләү тора. Деформация – ул теләсә нинди үзгәреш, нәрсәнеңдер нормадан тайпылуы. Деформацияләнгән текстлар белән эшләү укучыларга әйтелмәнең мәгънәсен аңлауга йогынты ясый торган дөрес язуны, орфографик һәм пунктуацион хаталарны төрле юнәлешләрдә анализларга, текстларда сүзләрнең язылу вариантларын төзәтергә, чагыштырырга, тел чараларын куллану нормаларын тоярга һәм аңларга мөмкинлек бирә. Шулай итеп, эш барышында укучылар сөйләмдә лексик һәм грамматик берәмлекләрнең эшчәнлеген

күзәтәләр һәм тел материалын анализлауның төрле төрләрен үзләштерәләр. Деформацияле текстлар – тәртипсез урнашкан җөмләләрнең эзлеклелеген үзгәртү юлы белән текст төзү. Моңа бәйле рәвештә деформацияләнгән текстларны куллану шартлары комплексына игътибар итәргә кирәк, аларны үтәү укучыларда сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен билгели белүне формалаштыру өстендә эшнең нәтиҗәлелеген арттырырга ярдәм итә. Яңа стандартлар белем бирү процессында электрон белем бирүнең төрле формаларын да куллануны таләп итә. Деформацияләнгән текстлар белән эшләү биремнәрен LearningApps.org программасында куллану да актуаль. Бу замана таләпләренә туры килә, укучыларда туган телгә кызыксынуны арттыра.

**Нәтиҗә**. Шулай итеп, деформацияләнгән текстлар белән эшләү сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен билгели белү күнекмәләрен дә камилләштерә. Бу эшчәнлек ярдәмендә күп кенә логик операцияләр башкаруга нигезләнгән фикер йөртү һәм фикер йөртү юлы белән чынбарлыкны танып белү күнекмәләре үстерелә. Тел дәресләрендә деформацияләнгән текстларны куллану укучыларның сөйләмен үстерүдә, аерым алганда, аларның сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен билгеләү күнекмәләрен формалаштыруда да зур әһәмияткә ия. Дәресләрдә деформацияләнгән текст белән эшләүнең төрле төрләрен куллану тәртипсез урнашкан җөмләләрне, анализ, синтез, гомумиләштерү, шулай ук төрле мәгълүмат чыганаклары белән эшләү кебек логик операцияләрдән файдаланып, аларның эзлеклелеген үзгәртү юлы белән бәйләнешле текстка әверелдерергә мөмкинлек бирә.

Деформацияләнгән текст белән эшләүнең әһәмияте шунда ки, аны торгыза белү балаларга текстны тирәнтен аңлау бурычын чынлыкта кабул итәргә мөмкинлек бирә. Мондый эш укучыларның кичерешләрен ачыклый, тирәнәйтә, фикерләрне башка текстларга күчерү күнекмәләрен формалаштыра. Шулай ук деформацияләнгән текст белән эшләү җөмләләрне дөрес төзергә, ягъни сүзләрне төшереп калдырмаска, сүзләрне билгеле бер эзлеклелектә куярга, аларны бер-берсе белән дөрес килештерергә һәм сүзләрне дөрес әйтергә, ә аннары торгызылганны язма рәвештә төзергә өйрәтү максатында бирелә, ягъни бәйләнешле сөйләмгә өйрәтә. Нәтиҗәдә, деформацияле текст белән эшләү тел дәресләрендә сөйләм үсешендә югары нәтиҗәлелеккә ия дигән нәтиҗә ясарга була, чөнки ул балаларны үз фикерләрен бәйләнешле, эзлекле һәм логик рәвештә бәян итәргә өйрәтә.

Авторлар тарафыннан К.Насыйриның тормыш һәм иҗат юлы материалларына нигезләнеп төзелгән деформацияләнгән текстлар белән эшләүгә нигезләнгән ярдәмлек кулланма 5–9 нчы сыйныф укучыларына, укытучыларга һәм балалар белән шөгыльләнүче ата-аналарга, татар теленнән сайлап алу имтиханына әзерләнүчеләргә дә адреслана.Укучыларның туган тел һәм әдәбиятыннан алган белемнәрен тирәнәйтергә ярдәм итә. Бөек татар галиме Каюм ага Насыйри турында белемнәрен камилләштерә, укучыларда рухи-әхлакый сыйфатлар тәрбияли.

### Кулланылган әдәбият


1. Каюм Насыйри «Әбүгалисина: балалар өчен кыйсса, Татарстан китап нәшрияы, 2019.– 119 б.
2. Моисеева О. В. Установление причинно-следственных связей – способ формирования исследовательских умений у младших школьников на уроках окружающего мира. М., 2014.
3. Нестерова Н. А. Методические аспекты работы по формированию языковых компетенций учащихся при работе с текстом на уроках русского языка. – Ярославль: 2012.
4. Татар әдәбиятыннан хрестоматия. 7 нче сыйныф өчен ярдәмлек. Казан. ТаРИХ, 2002.
5. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Казан. Татарстан китап нәшрияты.1977.
6. Хуҗиәхмәтов Ә.Н. «Мәгърифәт йолдызлыгы». Казан: Мәгариф, 2002.-287б.

# ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕН ЗАМАНЧА ТЕХНОЛОГИЯЛӘР КУЛЛАНЫП УКЫТУ

**Нуриева Рәйсә Солтанәхмәт кызы**
*Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районы*
*Осиново бистәсенең «В. В. Карпов исемендәге лицей»*
*муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесенең*
*Югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Укыту процессы – укытучы һәм укучының бердәм эшчәнлеге. Укытучы укучыны фәнне үзләштерүгә актив катнаштыра алырга, аны мөстәкыйль рәвештә акыл эшчәнлегенә җәлеп итәргә һәм анда белем алуга кызыксыну уята белергә тиеш.

Мин, үзем, күп еллар татар телен башлангыч сыйныфларда укытканлыктан, татар телен өйрәнүнең иң кызыксындыру чарасы уен икәнен яхшы аңлыйм. Уен – бала эшчәнлегенең, тормышының аерылгысыз бер өлеше. Уен формасында оештырылган дәресләр фән белән кызыксынуны көчәйтә, баланың мөстәкыйльлеген үстерә.

Заман алга барган саен, телне өйрәнүгә кызыксындыруның башка яклары да ачылып тора.

Мин татар теле дәресләрендә компьютерны төрле яклап кулланам. Соңгы елларда «Ак Бүре» анимацион сериалын дәресләрдә куллана башладым. Беренче сыйныфлар өчен ул бигрәк тә отышлы. Мультфильмда яңгыраган музыка дәресне җанландырып җибәрә, күңелләр күтәрелеп китә. «Ак Бүре» анимацион сериалы – балаларда татар телен һәм татар мәдәниятен өйрәнүгә кызыксыну уятуга юнәлдерелгән инновацион проект. Мультфильмның төп герое Ак Бүре һәм аның дуслары балаларны татар сүзләренә һәм гыйбарәләренә аңлаешлы һәм күңелле өйрәтәләр, шулай ук халкыбызның гаҗәеп тере мәдәният дөньясына озаталар. Сүзләрне искә төшерү һәм дөрес язылышын истә калдыру өчен дә бик уңайлы.

2020 елның октябрендә Татмедиа АҖ «ТАТМЕДИА Junior» яңа проектын башлап җибәрде. «Татмедиа Junior» татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы комиссия белән берлектә эшләнде. Хәзер «Татмедиа Junior» да 33 проект гамәлгә ашырыла. Алар 14 Ютуб-каналда урнашкан. Кайбер проектларны без дәресләрдә кулланабыз.

Балалар бакчасы өчен «Бәби сүз» УМК программасы (уку-методик комплекс) бар. Бу программа буенча һәр бала үз үсеше чорында билгеле бер сандагы сүзләрне белергә тиеш. «Бәби сүз» проекты үз эченә төрле темаларны ала: гаилә, хайваннар, кошлар, җиләк-җимеш, яшелчәләр, көнкүреш техникасы, ел фасыллары, кием, ризык, саннар, төсләр, формалар һ.б. Без дә бу проектны дәрестә бик рәуәтләнеп кулланабыз. «Бәби сүз» проекты балаларга бик бик ошый. Балалар сүзләрне искә төшерәләр, кече яшьтәге мәктәп балаларына аңлаешлы булган матур татар сөйләмен дә ишетәләр.

Икенче проект «Салаватики». Әлеге проектның төп максаты-балалар арасында татар җырларын популярлаштыру. Моның өчен аларны яңа, кызыклы, анимация форматында тәкъдим итү мөһим. Төрле костюмнарда киенгән һәм халыклар һәм композиторлар иҗат иткән җырлар җырлаган балалар белән бергә кушылып җырлау һәм бию дәресләрне тагын да кызыклырак итә. Кайбер җырларны физкультминут буларак та кулланырга була.

500 сүз» проекты да төрле яктан файдалы. Ул «Алфавит», «Темалар», «Этикет», «Уеннар», «Сүзлек» кебек бүлекләрне үз эченә ала.

«Сүзлек» бүлеге буенча фонетик күнегү эшлибез. Бу сүзләрне кабатлап искә төшерү өчен бик яхшы. «Уеннар « бүлегендә рәсемнәрдән дөрес вариантны сайлап алу кебек уен уйнала. «Этикет» бүлегендә билгеле бер темаларга диалоглар бирелгән. «Темалар» бүлегендә шушы темага караган сүзләрнең аудио варианты бирелгән. «500 сүз» проектының сайты: http://500slov.tatar/tt.

Татар теленә кызыксындыру чарасы буларак, кайбер татар теле укытучыларының шәхси сайтлары да ярдәмгә килә. «Күңелле татар теле. Кроссвордлар» дигән сайт балаларга бик ошый. Бу сайтта татар төркемнәре өчен дә, рус төркемнәре өчен дә материаллар җитәрлек. Рәсем белән

сүзне тәңгәл китерү, кроссвордта бирелгән сүзләрне табуга бирелгән күнегүләр балалары бик җәлеп итә.

Төрле сайтларны кулланудан тыш, интерактив тактаның да телне өйрәнүгә кызыксыну чарасы буларак әһәмияте зур. Интерактив такта укучыларда эшләү активлыгын гына арттырып калмый, ә яңа материалны һәр укучыга җиңел, аңлаешлы итеп җиткерергә дә ярдәм итә. Интерактив такта белән эшләү өчен ActivInspire программасы бик отышлы. Бу программада татар теле дәресләрен кызыклы, файдалы итеп үткәрү өчен төрле төрдәге күнегүләр төзергә була. Бу күнегүләрне татар төркемендә, беррәттән рус төркемендә укучы балалар өчен дә кулланырга була. ActivInspire программасы белән мин тирәнрәк танышырга һәм аны дәресләрдә мөмкин кадәр күбрәк кулланырга дигән максат куйдым.

Мин үзем ActivInspire программасы ярдәмендә төрле типтагы күнегүләр төзеп, дәресләрдә кулланам. Мәсәлән: соответствивие (туры китерү), распределить по категориям (категорияләр буенча урнаштыру), кроссвордлар, тренировка памяти (хәтерне ныгыту), последовательности (эзлеклелек) кебек күнегүләрне яңа материалны аңлатканда да, ныгыту, кабатлау һәм тикшерү эшләре эшләткәндә дә кулланырга була.

ActivInspire программасы, интерактив такта аша, төрле типтагы биремнәр, күнегүләр эшләп, укыту сыйфатын күтәрергә, татар телен өйрәнүгә кызыксыну уятырга, югары нәтиҗәлелеккә ирешергә мөмкинлекләр ача.

Татар теле дәресләрен төрле уеннар кулланып, заманнан артта калмыйча, төрле сайтлар, интерактив такталарда эшләп үткәрсәк, бу балаларда телгә уңай караш, кызыксыну булдырыр, укыту сыйфатын арттырыр. Татар теле һәм әдәбиятын укытуны камилләштерүнең чиге юк, фәкать эзләнергә, яңалыкка омтылырга, билгеләнгән максатка кыю барырга гына кирәк.

### Кулланылган әдәбият

1. Габдулхаков В. Ф. Теория и практика // Развития творческой одаренности учащихся. Сборник статей и методических материалов международной научно-практической конференции. – Казань-КФ У.214б.
2. Фәтхуллова К.С., Юсупова Ә. Ш., Денмөхәммәтова Э. Н. Татар теле – күңелем теле. – Казань: Мир без границ, 2013. – 308 б.
3. Хәйдәрова Р. З. Татар теле һәм әдәбияты укытуда яңа технологияләр.-Яр Чаллы..2011.69 б.
4. prometheanworld.com›ru
5. http://selam.tatar/
6. https://idel-tat.ru/news/obo-vsem-na-svete/tatmedia-junior-layk-ili-dizlayk
7. http://tatarmultfilm.ru/cartoons/animacionnyi-serial-ak-bure

## СОВРЕМЕННЫЕ ТЕХНОЛОГИИ В ПОМОЩЬ УЧИТЕЛЮ РОДНОГО (ТАТАРСКОГО) ЯЗЫКА И ЛИТЕРАТУРЫ

**Рафикова Эльвира Алмарисовна**
*МБОУ «Лицей № 4 г. Азнакеево»*
*Учитель родного (татарского) языка и литературы*

Современные технологии помогают сделать любой урок занимательным и интересным. Главное – грамотно использовать их с методической точки зрения. QR-код – помощник учителя на уроке.

**Что такое QR-код?**

Аббревиатура **QR** (quick response) в переводе с английского означает «быстрый отклик». Это двухмерный штрих-код (матричный код), который разработала японская компания «Denso Wave» в 1994 году. Он позволяет в одном небольшом квадрате поместить 2953 байта информации,

то есть 7089 цифр или 4296 букв (около 1–2 страниц текста в формате А4), 1817 иероглифов. Сегодня вы можете встретить эти загадочные квадраты на рекламных щитах, в витринах магазинов, на обложках книг и журналов и т.п.

«Дошли» QR-коды и до системы образования:

1. Учебная деятельность (учебники и учебные пособия)
2. Проектная деятельность
3. Игровая деятельность
4. Внеурочная деятельность
5. Организация пространства
6. Воспитательная работа

Конкретно, в учебной деятельности на уроке можно использовать:

1. Интерактивное задание
2. Домашнее задание
3. Образец задания
4. Помощь (формула, пример)
5. Полезные ссылки
6. Дополнительные материалы

Информационно-образовательное пространство

1. Электронный документооборот
2. Локальная сеть
3. Школьный сайт

После уроков

1. Кружок
2. Консультации
3. Конкурсы
4. Проектная деятельность
5. Исследовательская деятельность

**Как создать QR-код?**

Создать QR-код несложно, нужен лишь генератор для его создания, доступный сервис в сети Интернет или установленная специализированная программа на компьютер.

Для этого в свободном доступе существует **множество веб-ресурсов и вебсервисов:**

**qrcode.tec-it.com/ru** – кодирует текст, ссылку на сайт, телефон, SMS сообщение, Email адрес, Email сообщение, визитную карточка, Twitter, доступ к Wi-Fi и др.

**https://www.qrrd.ru/** – цветной генератор кодов. Кодирует простой текст или визитную карточку.

**Creambee.ru** – кодирует простой текст, контакт vCard, звонок на номер SMS, на номер, переход на сайт, отправку E-Mail, сообщение в твиттер, поделиться в фейсбук. Позволяет изменить размер, оформить в цветном варианте, добавить свой логотип и фон. Платный ресурс (тестовый период 14 дней).

**https://ru.qrcodechimp.com/user/dashboard** – онлайн генератор QR-кодов с логотипом и круглой формой.

На уроках татарского языка и литературы я использую QR-код;

1. При изучении фразеологизмов;
2. Можем разгадывать кроссворд;
3. Продолжить пословицу, поговорку;
4. Отгадать загадки;
5. Просмотреть буктрейлер;
6. Сделать синтаксический разбор;
7. Аудиозапись стихотворения;
8. Аудиозапись правила;
9. Разгадывать ребусы;

10. Можно зашифровать вопросы.
11. Можем сделать анаграмму (перестановка букв).
12. Создать тесты.
13. Закончить биографию писателя и т.д.

А сейчас наведите ваши гаджеты на данный QR-код. Что вы там видите? Попробуйте заменить фразеологизм другими словами.

Салпы якка салам кыстыру-юмалау, үз файдасына

Кабыргасы белән кую-катгый рәвештә, кискен кую

Дүрт аяклы кеше – абаланып баручы

Җан тартмаса, канн тарта – туган

Дуга белән печән чабу – кеше Бер сүз сөйләгәндә ялгыш аңлап, икенче сүзгә керешү

Көймәсе комга терәлгән –эшләре алага бармый

Аю хезмәте күрсәтә – беркатлы кешенең яхшылык итәм дип зыян эшләве

Тезгенне каты тота – нык тота

Утлы табага бастыра – әрли, орша.

Перед вами следующий QR-код, где вы найдете анаграммы. Как вы знаете, это составление новых слов путем перестановки букв.

Ук– ку, таза-Азат, суд-дус, абзар-базар, тавык-ватык, каба-бака, таба –бата, Һади-даһи, алсу-усал, карта-карат.

Другим, не менее интересным видом работы я считаю буктрейлеры.

Буктрейлер **(англ. booktrailer)** – это короткий видеоролик, рассказывающий в произвольной художественной форме о какой-либо книге**.** Продолжаем использовать гаджеты для определения следующего автора и его произведения. Да, действительно, это Роберт Миңнуллин «Мин мактанчык түгел!»

На моем профессиональном сайте, открывающийся при помощи следующего QR-кода, вы можете найти не только мои достижения, но и весь педагогический материал, который вы можете использовать на уроках родного (татарского) языка и литературы.

А сейчас я вам хочу предложить практическую работу:

1. Придумать слово

На сайте http://kvestodel.ru/generator-rebusov ИЛИ https://rebuskids.ru/create-rebus создать ребус

Скачать ребус

На сайте https://ru.qrcodechimp.com/user/dashboard выбрать тип QR-кода, выбрать загруженное изображение, сгенерировать код, загрузить код.

Заканчивая свое выступление я прошу вас навести на любой QR-код, который находится в презентации и желаю вам того, что написано там.

## АЛТЫПОЧМАКЛЫ УКЫТУ ТЕХНОЛОГИЯСЕ – ТӘНКЫЙДИ ФИКЕРЛӘҮНЕҢ БЕР АЛЫМЫ

**Сулейманова Танзиля Хамитовна**
*МБОУ «Утар –Атынская ООШ»*
*Арского района РТ*
*Учитель татарского и русского языка и литературы*

Федераль белем бирүнең нигезенә системалы эшлекле якын килү салынган. Укытучы дәрестә һәм дәрестән тыш эшчәнлеге укучыларда танып-белүгә кызыксыну уятырга, белем алу процессы белән кызыксындырырга тиеш. Ул дәрес технологиясен алмаштырып, үз эшеннән, аның нәтиҗәсеннән канәгатьсезлек хисе белән бәйләнешле эшне җайга салырга омтыла. Үзе үткәрә

торган гадәти дәрестә яңа компонентлар куллана һәм аны камилләштерә. Технологияләр күптөрле, ләкин аларның барысы да гомуми бер идеягә – укучыларның уку-танып белү эшчәнлеге белән идарә итү ысулларын булдыруга нигезләнә; белем бирү процессының нәтиҗәлелеген күтәрү, аң активлыгын үстерү һәм укыту процессының нәтиҗәлелеген арттыру максатына хезмәт итә.

Укучы логик фикерли, чагыштыра, классификация ясый белә һәм гомумиләштерә өйрәнә. Уку эшчәнлеген дөрес оештырганда укучы шәхес буларак формалаша, укыту процессына, объектына, шартларына, нәтиҗәләренә мөнәсәбәтен күрсәтә. Ул үз эшчәнлеген оештыруга сәләтле була. Укытучының эш юнәлешенең бер төре булып укучыларда тәнкыйди фикерләүне үстерү тора. Тәнкыйди фикерләүнең бер алымы буларак алтыпочмаклы укыту технологиясе бар. Ә бит нәкъ менә шушы алым пассив тыңлаучыдан укучыларның актив рәвештә эшләвенә һәм дәресләрнең нәтиҗәлелеген күтәрүдә зур роль уйный.

Дәресләрдә укучының белемен тикшерү, теманы кабатлап, гомумиләштерү өчен һәр укытучы төрле алымнар куллана. Ләкин практикада, үземнең дәресләремдә дәвамлы файдаланган, кулланган саен төрле уңай якларын ачып, укучылар өчен дә файдалы һәм кызыклы булган бу технологияне атап китми булмый. Чөнки, алтыпочмаклы укыту технологиясе дәрестә укучыны уятып, кызыксындырып җибәрә, укучының фикерләү дәрәҗәсен үстерүгә ярдәм итә, индивидуаль яки группалап эшләүне оештыру мөмкинлеген булдыра. Һәм аны төрле предмет укытучысы да куллана ала.

## УКУЧЫЛАРНЫҢ ИҖАДИ ФИКЕРЛӘРЕН ҺӘМ ТАНЫП-БЕЛҮ ЭШЧӘНЛЕГЕН АКТИВЛАШТЫРУ ЧАРАСЫ БУЛАРАК ТРИЗ ТЕХНОЛОГИЯСЕ

**Хуснутдинова Ләйсән Анваровна**
*Лаеш районы Усад авылы МБОУ*
*«Күп профильле «Сәламәт буын» лицее*

Педагогиканың актуаль мәсьәләләренең берсе булып – балалар иҗаты һәм аларның гомумүсеше, җитлегүе өчен иҗади эшчәнлекнең әһәмияте тора. Иҗади үсеш технологияләре ярдәмендә балаларны сөйләм эшчәнлегенә өйрәтү, аларның ихтыяр көчен, күзәтүчәнлеген, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерү – укытучылар алдында торган мөһим бурычлар әнә шулар.

Бу бурычларны тормышка ашыруда ТРИЗ тезнологиясе безгә ярдәмгә килә.

ТРИЗ технологиясенең үзенчәлеге булып, укучының фикерләү сәләтен үстерүне формалаштыру тора.

Белгәнебезчә, дәрестә материалны тиз үзләштерә, кагыйдәләрне төгәл үти торган укучылар белән бергә, тыныч утыра торган, пассив укучылар да очрый. Кыюсыз балалар белән аерым эшләгәндә, үз эченә бикләнеп утырган баланың да теле ачыла, ул да тора – бара актив балалардан калышмый башлый. Ә мондый нәтиҗәгә ирешүдә дәрес һәм дәрестән тыш вакытларда төрле алымнар куллану зур булышлык итә.

**ТРИЗ технологиясенең максаты булып түбәндәгеләр тора:**

– эшчәнлекнең төрле өлкәләрендә туган проблемаларны чишәрлек иҗади фикер йөртүче шәхес тәрбияләү

– ситемалы фикер йөртүне үстерү

– укучыларны чишелеше күренмәгән мәсьәләләр чишәргә өйрәтү

– тирә-ягыңны күрә белергә өйрәтү

– каршылыклар формалаштырырга һәм аларны чишә белергә өйрәтү

– укучыны креатив фикер йөртү ысулларына, яңа нәтиҗә таба алу методларына өйрәтү

**ТРИЗ технологиясен кулланганда**

– мәгълүмат белән мөстәкыйль эш нәтиҗәсендә белем, осталык һәм күнекмәләр формалаша

– дәрескә үзенчәлек, креативлык бирә

**ТРИЗ технологиясенең алымнары куп төрле.** Мәсәлән,
«Әйе-юк»
«Табышмаклар төзү»
«Акыл штурмы»
«Хатаны тап»
«План төзү», «Паспорт төзү», «Пинг-понг»,
«Модельләштерү» һәм башкалар.

## ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ТЕХНОЛОГИЯЛӘРНЕ КУЛЛАНЫП, УКУЧЫЛАРНЫҢ УКУГА МОТИВАЦИЯСЕН АРТТЫРУ

**Шаева Венера Мнахир кызы**
*ТР Мөслим муниципаль районы*
*Мөслим лицее*
*Туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

Соңгы елларда мәктәптә яңа педагогик технологияләр көннән-көн активрак кулланыла бара.

Бүгенге уку-укыту процессы укытучылар алдына яңа педагогик технологияләргә таянып эшләү, уку-укыту эшендә аларның барсын да теге яки бу дәрәҗәдә куллану максатларын куя. Шулар белән бергә, заманалга барган саен, бүгенге уку-укыту процессында иң әһәмиятле урынны заманча технологияләрнең берсе булган компьютер техноло гиясе алып тора. Аны дәресләрдә куллану торган саен үсә, камилләшә бара.

Укытучыларның дәрестә нәтиҗәле эшчәнлеген оештыруның күп төрле ысуллары бар. Соңгы елларда укучылар үз иткән гаджетларны дәрестә максатка ярашлы итеп файдалану тенденциясе барлыкка килде. Кул астында булган айфон, смартфон ярдәмендә тиз арада интернетка кереп, кирәкле мәгълүматны табу укучыны дәрестән читкә алып китми, киресенчә, булган осталыгын файдаланып, оператив рәвештә мәгълүмат белән эш итәргә ярдәм итә. Plickers – тест формасындагы биремнәрне тиз генә бәяләү, статистика өчен куллану отышлы.

Quizizz – онлайн викторина, тест һәм сорауларны фото, видеоматериаллар кулланыптөзергә мөмкинлек бирүче онлйн сервис. Укучылар үз планшетлары, смартффон, ноутбуклары аша биремнәр башкаралар. Укытучы тест яки викторина сорауларны үзенең компьютерында төзи, укучылар телефоннар ярдәмендә җавап бирәләр. Дөрес җавапка баллар куела. Liveqworksheets – эш битләрендә электрон рәвештә интерактив биремнәр булдыру өчен гади корал. Биредә укытучыга интерактив битләр ясау өчен кирәкле инструментлар күп.

Татар теленә өйрәтүдә ясалма интеллектның роле татар теленә өйрәтүдә ясалма фәһем (ЯФ) телне өйрәнү процессын автоматлаштыру һәм оптимальләштерү, укыту сыйфатын яхшырту һәм белемнәрне тикшерү процессын гадиләштерү өчен кулланыла.

Педагоглар бертавыштан белем бирүдә ясалма интеллект кертүне хуплыйлар, тик акыллы масштабларда гына. Татар теле – ул һәрвакыт иҗат, һәм ясалма фәһем укытучыны бушатырга, аның җилкәсеннән тестларны һәм әсәрләрне тикшерү авырлыгын төшерергә һәм шул ук вакытта бәяләүнең объективлыгын күтәрергә тиеш.

Укытучы-иҗади шәхес, ясалма интеллект – җансыз механизм. Дәресләрдә «күзгә – күз» методы мөһим-балаларга, бигрәк тә әдәбият дәресләрендә, укытучы хисләре кирәк. Мәгълүмати технологияләрдән уңышлы файдалану, тел һәм әдәбият фәненә иҗади якын килеп эшләү зур нәтиҗәләргә ирешергә ярдәм итә. Компетенлы укытучы гына компетентлы укучы шәхесе тәрбияли ала. Укучыда формалашыра тиешле комптенцияләр, беренче чиратта, укытучының үзендә булу шарт. Ә компетентлы педагог – укучы һәм ата-аналар өчен дә, мәктәп өчен дә хәзинә.

## ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ЭФФЕКТИВ ТЕХНОЛОГИЯ БУЛАРАК УЕН ТЕХНОЛОГИЯСЕ

**Мөхәмәтгалиева Айгөл Рифхәт кызы**
*Казан шәһәре «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 71нче татар-рус урта гомуми белем мәктәбе»*
*Туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучысы*

Заманча укыту процессы укучыларның иҗади сәләтләрен үстерүгә ярдәм итәргә тиеш. Моның өчен яңа, эффектив технологияләр эзләү сорала. Мәгарифтә инновацион технологияләр фәннең һәм информацион технологияләрнең заманча казанышларын куллануга нигезләнә. Алар белем сыйфатын күтәрүгә, укучыларның иҗади һәм мөстәкыйль карарлар кабул итү сәләтен үстерүгә юнәлтелгән.

Мәктәптә татар теле дәресләрендә заманча укыту чараларын куллану эше мөмкин һәм кирәкле эш, чөнки мәктәптә дәрес өйрәнү процессында укучыларның иҗади сәләтен ачу юллары бихисап.

Мәкаләнең максаты – мәктәптә татар теле дәресләрендә укучыларның танып-белү активлыгын үстерү чарасы буларак эффектив уен технологияләрнең кулланылышын өйрәнү.

Башлангыч сыйныфларда уен – татар теле дәресләрендә уку эшчәнлеген оештыруның югары нәтиҗәле чарасы. Уен балаларның фикерләвен, сөйләмен һәм хәтерен үстерә. Башлангыч сыйныфларда укучылар предметлы уеннарны, әкият геройларына бәйле булган рольле уеннарны теләп башкаралар.

Уеннарның тел дәресендәге урыны һәм уенга бирелгән вакыт шартлы, чөнки бу берничә факторга, ягъни укучыларның тел белү дәрәҗәсенә, балаларның әзерлегенә, өйрәнелә торган материалга, дәреснең максатлары һәм шартлары һ.б бәйле. Димәк, уеннар һәм уен технологияләре мәктәп дәресенең төрле этапларында кулланылырга мөмкин: дәрес башында да, аның уртасында да, һәм, әлбәттә, дәреснең соңгы этабында да.

Дәрес башында уен уйнатып алганда, балалар уку процессына җиңелрәк керәләр, хәтерләрен яңарталар, яңа материал өйрәнергә кызыксыналар, иң мөһиме – укучыларны тел мохите белән таныштыралар. Әйтергә кирәк, уен дәрес башында уйналса, калган дәрес планлаштырылган һәм структураланган булырга тиеш, шул чакта гына балалар уен вакытында уеннан ләззәт алып, дәрескә җиңел генә керешеп китә алачак.

Дәрес уртасында балалар бераз ял итсеннәр, стреслы моментларны җиңеп, активлыкларын арттырыр һәм телне өйрәнүгә яңа көчләр белән керешсен өчен уеннар кулланырга киңәш ителә.

Дәрес ахырында уен уйнау да зур уңыш китерә. Дәрес ахырын көтеп торган балалар бик зур дәрт белән «уйныйлар», әгәр дә укучылар казанышлары өчен мактала икән, алар киләсе дәресне тагын да зуррак түземсезлек белән көтәләр.

Уеннарны тел материалы өстендә эшләүнең төрле этапларында кулланырга мөмкин: яңа материал белән танышканда, алдагы дәресләрдә алган белемнәрне кабатлау һәм ныгыту өчен, күнекмәләрне һәм сәләтләрне берләштергәндә, шулай ук өйрәнелгәннәрне кабатлаганда һәм системалаштырганда да. Укыту процессында уен эшчәнлеге төрле функцияләр үти:

– мавыктыргыч (бу уенның төп функциясе – мавыктырырга, күңелен күрергә, кызыксыну уятырга);
– коммуникатив (сөйләм диалектын үзләштерү);
– диагностик (уен барышында үз-үзеңне танып белү);
– милләтара коммуникацияләр (бөтен кешеләр өчен дә бер булган мәдәният кыйммәтләрен үзләштерү).

Дәрестә укытучы, уеннар кулланып, укучыларның танып-белү эшчәнлеген оештырганда, аларның иҗади сәләтләрен ачарга тырышу максатын куя. Уен һәрвакыт эмоция һәм акыллылык таләп итә, шулай ук тиз арада җавап кабул итүне сорый (ничек җавап бирергә, нәрсә эшләргә,

ничек җиңәргә?). Бу сорауларны чишәргә тырышу уйнаучыларның уйлау эшчәнлеген көчәйтә. Уен барышында балаларның татарча сөйләшергә тырышулары бик зур уңай факт булып тора. Уен алымнарын, эш төрләрен төрлечә сайларга мөмкин. Ләкин һәр уен ныклап уйланылган, һәрьяклап эшкәртелгән булырга тиеш. Уеннарны, гадәттә, берничә төркемгә бүлеп йөртәләр:

1) әле өйрәнелмәгән татар лексикасын үзләштерергә ярдәм итә торган уеннар;

2) өйрәнелгән лексиканы ныгытырга ярдәм итә торган уеннар;

3) грамматик кагыйдәләрне кызыклы формада бирә торган уеннар;

4) грамматик формаларны, җөмләдә сүзләр бәйләнешен һәм җөмлә төзү күнекмәләрен ныгытырга ярдәм итә торган уеннар.

Формалары буенча алар телдән һәм язма, өстәл һәм хәрәкәтле уеннарга бүленәләр.

Уен алымын күп кенә укытучылар үз дәресләрендә куллана, ләкин һәркем аны үзенчә тәкъдим итә. Уен – ул укытучының иҗади эше. Димәк, аның яңалыгы да шунда.

Мин сезгә укучыларны татар теленә өйрәткәндә уңышлы кулланып була торган берничә уен технологияләре элементларын күрсәтеп үтәргә телим. Мин моны татар теле һәм инглиз теле дәресләре үрнәгендә күрсәтермен.

Мәсәлән. 3 нче сыйныфта «Гаилә» (Family) темасын өйрәнгәндә, дәрес башында татар һәм инглиз теле авазларын үзара чагыштырып карау уенын укучылар өчен кызыклы һәм нәтиҗәле дип күрәм.

Дәрес барышында балаларны ике төркемгә бүлеп «Гаилә» темасына кагылышлы видео күрсәтеп, сорауларга җавап бирдерергә була. Алар бу уен ярдәмендә төркемнәрдә эшлиләр, үзара киңәшләшәләр.

Икенче уен итеп «Сүзләрне тап» уенын уйнап була. Монда укучылар тактага чыгып темага кагылышлы сүзләрне табырга тиеш(шулай ук төркемнәрдә дә эшләп була).Дәрестә җавап бирергә оялган укучылар үзләренең сәләтләрен күрсәтәләр. Шулай ук дәрестә җырлар куллану да бик отышлы.

Дәресләрдә уен технологиясе элементлары киң куллану уңай нәтиҗә бирә, укучыларның күзәтүчәнлек, игътибарлылык, сабырлык кебек сыйфатларын, хәтер һәм зиһенен үстерә, фикерләү сәләте үсеше белән бергә, туган телгә, туган якка мәхәббәт тә тәрбияләнә.

**Кулланылган әдәбият**

1. Азимов Э.Г., Самуйлова Н. И., Шамши Л. Б. ТСО на современном этапе развития методики преподавания русского языка как иностранного // Русский язык за рубежом. – 1998. – № 2.

2. Бурняшева Л. А. Активные и интерактивные методы обучения в образовательном процессе высшей школы. Методическое пособие / Л. А. Бурняшева. – М.: КноРус, 2016.

3. Щукин А. Н. Обучение иностранным языкам: теория и практика. 3-е изд. М., 2007. – 186 с.

## БЕЛЕМ БИРҮНЕҢ ЯҢА СЫЙФАТЫНА ИРЕШҮНЕҢ НӘТИҖӘЛЕ ЧАРАСЫ БУЛАРАК МӘГАРИФТӘ ПРОЕКТ ЭШЧӘНЛЕГЕ

**Сафина Зиля Сахабетдиновна**

*Нурлат шәһәре 2 нче урта гомуми белем мәктәбе*

*Туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

Бу мәкаләдә проектлау методы бары тик укытучы һәм укучы эшчәнлеген тиешле бәйләнештә алып барганда гына югары нәтиҗәләр бирүе турында сүз бара.

«Проект» – фарсы теленнән алга атлаучы, алдан баручы дигәнне аңлата. Проект методын куллану – ул алган белем һәм күнекмәләрне системалаштыру, «белү һәм белмәү» зонасында мөстәкыйль эшчәнлек кору, фәннәр арасында бәйләнеш табу, проблеманы билгеләү, чишү юлларын табу, эш нәтиҗәсен тәкъдим итә алу. Проект-ул конкрет проблеманы хәл итүгә, алдан

планлаштырылган нәтиҗәгә оптималь ысул белән ирешүгә юнәлдерелгән эш. Проектлар методы педагогикада берничә елдан артык кулланыла. Әлеге метод шәхеснең иҗади мөмкинлекләрен активлаштыруга, уку эшчәнлегенең яңа формаларын ачыклауга ориентлаша.

Проектлау методын кулланганда укытучы һәм укучыларның аралашуы, хезмәттәшлек итүе үзенчәлекле төс ала: укытучы укучыларның эшчәнлеге белән генә түгел, аларның бергәләп эшләве, фикер алышуы, карар кабул итүе белән дә идарә итәргә тиеш. Бу укытучыдан балаларның аралашу культурасына аеруча игътибар итүне таләп итә. Проектлау методы бары тик укытучы һәм укучы эшчәнлеген тиешле бәйләнештә алып барганда гына югары нәтиҗәләр бирә.

Шулай итеп, проект – ул:

1) нинди дә булса механизмның яки корылманың планы;

2) нинди дә булса документның алдан әзерләнгән тексты;

3) теләгеңне тормышка ашыру планы.

Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә проект эшчәнлегенең берничә төре: мәгълүмати, рольле, практик юнәлешле, иҗади һәм тикшеренү проектларын аерып алырга мөмкин.

Мәгълүмати проект нинди дә булса объект турында мәгълүмат җыюга, аны анализлау, гомумиләштерү һәм киң аудитория өчен тәкъдим итүгә юнәлдерелгән. Мәсәлән, теге яки бу язучының яки шагыйрьнең биографик мәгълүматлары буенча китап булдыру.

Рольле проектта укучылар уйлап чыгарылган геройларның әдәби яки тарихи персонажлары ролен үз өстенә ала. Мәсәлән, теләсә кайсы әсәрнең эпизодын, экиятләр инсценировкасы күрсәтү.

Татар теле һәм әдәбияты буенча гамәли юнәлешле проект, проектта катнашучыларның социаль мәнфәгатьләренә юнәлдерелгән. Мәсәлән, татар теле буенча кагыйдәләр ни өчен өйрәнелә, хәзерге тормышта кагыйдәләрне белү кирәк булырмы?

Иҗади проект максималь ирекле һәм традицион булмаган нәтиҗәләрне рәсмиләштерүгә якын килүне күздә тота. Татар теле һәм әдәбияты буенча проектларның озынлыгы төрлечә.. Мини-проектларны бер дәрес эчендә эшләргә мөмкин. Мәсәлән, «язучылар турында сүз» яки «минем яраткан язучыларым».

Татар теле һәм әдәбияты буенча кыска вакытлы проектлар ике-дүрт дәрес алып тора. Атналык проектлар төркемнәрдә башкарыла. Эш укытучы җитәкчелегендә бара.

Татар теле һәм әдәбияты буенча еллык проектлар төркемнәрдә дә, индивидуаль рәвештә дә башкарылырга мөмкин. Ел саен үткәрелә торган проект – проблемаларны һәм теманы билгеләүдән алып презентациягә кадәр-дәрестән тыш вакытта башкарыла. Бу җитди тикшеренү, аны яклау мәктәп һәм муниципаль фәнни-гамәли конференцияләрдә ешрак үткәрелә.

Проектларның күптөрлелеге укытучыга яшүсмерләрне укыту һәм тәрбияләүнең төрле мәсьәләләрен алар өчен кызыклы формада хәл итәргә мөмкинлек бирә. Бу укучыларга белем һәм күнекмәләрне актив кулланырга, үз уку арсеналын киңәйтергә, ә аннары алган тәҗрибәне башка уку-укыту һәм укудан тыш эш төрләренә күчерергә мөмкинлек бирә. [2, 188].

Проектлар методы фәнне өйрәнү өчен бирелә торган барлык уку вакыты дәвамында, мөстәкыйль танып-белү, гамәли һәм сәнгать-иҗади эш алымнарының һәм формаларының күптөрлелеген кулланып, чын-чынлап тикшеренү иҗади мөстәкыйль эшчәнлекне оештырырга мөмкинлек бирә. Проект методикалары бүген заманча мәгариф системасының компонентларының берсе булып тора. Аның асылын чагылдыручы проектлар методының мөһим билгесе булып укучыларның мөстәкыйль эшчәнлеге тора. Алар уку процессының актив катнашучылары булып торалар. [4;17]

Заманча мәктәптә проект эшчәнлеге методын куллануның түбәндәге актуаль өстенлекләрен билгеләп үтәргә мөмкин:

1. Укучыларның мөстәкыйльлеген арттыру.

2. 1 Яңа материалны үзләштерү. Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү.

3. Укучыларның укуда мотивациясен арттыру.

4. Укучыларның танып-белү мәнфәгатьләрен активлаштыру.

5. Проект эшләрен башкару белән шөгыльләнүче укучыларның үз-үзләренә бәя бирергә өйрәтү.

6. Укучыларның иҗади сәләтләрен үстерү.

7. Барлык укучыларны да коллектив фикерләү эшчәнлегенә җәлеп итү.

8. Коллективта эшли белү, аралашу күнекмәләрен үстерү.

9. Үз-үзеңне һәм үз эшеңне тәкъдим итү күнекмәләрен төрле формаларда: телдән, язма рәвештә, өр-яңа технологик чаралар куллана белү.

10. Күпчелек проектларның практик әһәмияте яшүсмерләрне социумда тормышка әзерләргә мөмкинлек бирә.

Шулай итеп, проект эшчәнлеге хәзерге заман мәгарифендә социализация процессында оператив белемнәр белән тәэмин итү буенча иң перспективалы юнәлешләрнең берсе булып тора. [3;4]

Нәтиҗә буларак, кешене иҗат итәргә мәҗбүр итү мөмкин түгел. Фантаст А.Азимов үзенең «Һөнәр» дигән искиткеч хикәясендә язганча, кеше үз теләге белән эшкә килергә, сынап карарга һәм ялгышырга тиеш. Иҗат итү хокукын якларга әзер булган кеше генә чын иҗатка сәләтле, ә татар теле һәм әдәбияты укытучыларының бурычы-укучыларны бу иҗатка мотивлаштыру, аларга үзләренең кечкенә һәм зур ачышларын ясарга ярдәм итү. Яшь буын зиһенле, фикер йөртә белүче, җәмгыятькә файдалы шәхес булырга тиеш. Чөнки балалар – безнең киләчәгебез. Ә киләчәк тормышны кору өчен сәламәт, зиһенле кешеләр кирәк.

**Файдаланылган әдәбият**


1. Проектная деятельность школьников в разновозрастных группах. – М.: Просвещение, 2013.
2. Дубровская деятельность на уроках литературы в рамках реализации ФГОС [Электронный ресурс], Режим доступа //http://www.anedu. ru/uo/docs/documents/nortativ_pravov/uo/31–4.pdf
3. Литература. 5–11 классы: проектная деятельность учащихся / сост. . – Волгоград: Учитель, 2012. – 283 с.
4. Пахомова учебного проекта в образовательном учреждении. – М.: АРКТИ, 2008.

# НАУКА И ОБРАЗОВАНИЕ: СОЗДАЁМ БУДУЩЕЕ, ОПИРАЕМСЯ НА ЦЕННОСТИ (ГЕОГРАФИЯ, БИОЛОГИЯ, ХИМИЯ, ИСТОРИЯ, ОБЩЕСТВОЗНАНИЕ, ФИЗИКА)

---

## УКУЧЫЛАРНЫҢ БЕЛЕМ АЛУГА ОМТЫЛЫШЛАРЫН ПРОЕКТЛАУ АЛЫМНАРЫ АША КҮТӘРҮ


**Гайнуллина Гүзәл Харун кызы**
*Апас муниципаль районы*
*«М. Х. Гайнуллин исемедәге Кызыл Тау*
*урта гомуми белем бирү мәктәбе»нең*
*тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы*


Педагогика фәнендә укыту-тәрбия процессы сыйфатын үстерергә булышлык итүче технологияләр шактый. Укытучының бурычы – яңалыклар агымында югалып калмыйча, дөрес юнәлеш алу, укытуның һәр этабы өчен уку материалын үзләштерүнең иң уңышлы вариантын кулланып эшләү.

Уку-укытуда яңа педагогик технологияләр куллану бала тәрбияләүдә, аларны нинди дә булса яңалыкка өйрәтүдә каршылыклар да китереп чыгара. Юкка гына хәзерге балалар «унынчы сыйныфны бетереп» туалар дип әйтмиләрдер. Чыннан да, хәзерге уку-укыту системасы укытучыдан заманга яраклашуны, алдынгы тәҗрибәне үзләштерүне, укучыны һәрьяклап кызыксындыра белүне таләп итә. Шунлыктан теге яки бу фәнне өйрәнгәндә универсаль (ягъни һәр фәнне өйрәнгәндә кулланып була торган) алымнар барлыкка килә.

Мин укучыларга тарих фәнен укытам. Тарихны өйрәнгәндә фәнгә карата кызыксындыру уяту максатыннан, проект алымын кулланам. Ул да гадәти «репродуктив» (хәтерләү, искә төшерү) юнәлешендәге кебек уңай нәтиҗәгә ирешүне тәэмин итә. Яңалыкны тормышка ашыру җиңел эш түгел, чөнки һәр үзгәреш-яңалык гадәттә каршылыклы кабул ителә. Кайбер кешеләрнең үзгәрешләргә булган мөнәсәбәтен немец шагыйре И. В. Гете болай дип бәяләгән: «…башта – «бу юк сүз», аннары – «анда нәрсәдер бар, ахры», һәм соңыннан әлеге идея аңлашылып үзләштерелгәч, «бу инде яңалык түгел» – диләр». Проект методын кулланылышка керткәндә дә төрле каршылыклар белән очрашырга туры килде, чөнки әлеге эшчәнлек укучыдан гына түгел, укытучыдан да зур тәҗрибә, осталык таләп итә. Ахырда барлык каршылыклар юкка чыга.

Проект методы XX йөз башында Америка педагогы, психологы, фәлсәфәчесе Джон Дьюи (1859–1952) тарафыннан уйлап табыла. Аның фикере буенча, белем бирү ул – «балаларның шәхсән кызыксынуларына, максатларына тәңгәл килгән максатчан эшчәнлеккә нигезләнеп төзелгән процесс».

Проектлы укытуга нигезләнгән әлеге чаралар ярдәмендә күп максатларга ирешергә була. Тик иң элек укытучы проектның нәрсә икәнен үзе төгәл аңларга һәм укучыларга аңлатырга тиеш. Мәсәлән, гади презентация әзерләү, реферат язу берничек тә проект булып санала алмый, чөнки проект эшләүнең үз шартлары бар:

1. Проект нәтиҗәдә әзер продукт (сайт, белешмә, кушымта, китап, сүзлекчә, видеофильм, модель, җиһаз һ.б) буларак тәкъдим ителә. Аны Интернетка урнаштыру яки әзер килеш тарату, гамәлдә куллану мөмкин булырга тиеш.
2. Проектның гамәли файдасы, кулланучысы булуы шарт.
3. Проектны башкару процессында укучылар нинди дә булса яңа белем, яңа осталыклар, компетенцияләр үзләштерергә тиеш.

4.Проектның теге яки бу проблеманы тулыландырырлык, хәл итәрлек максаты, актуальлеге булуы зарур. Проект өчен тема сайлаганда, укучылар фикерен искә алу әһәмиятле. Моның өчен аларның кызыксынуларына игътибар итәргә кирәк.

Проект эшчәнлеге укучы шәхесенең белем алуга иҗади якын килүенә юнәлтелгән. Бу метод белән эшләгәндә, укучылар актив рәвештә уйлау, фикерләү эшчәнлегенә тартылалар. Ул, теге яки бу проблеманы тирәнтен өйрәнү максатында, укытучы җитәкчелегендә эшләнә торган мөстәкыйль иҗади эш. Компьютер технологияләреннән уңышлы файдалану, фәнгә иҗади якын килеп эшләү зур нәтиҗәләргә ирешергә ярдәм итә. Укучыларны ул һәрьяклап үстерә, шәхес итеп тәрбияли.

Әлбәттә укытучы һәм укучының уртак эше булса да, укучы билгеле бер мәсьәләне чишү юлларын үзе эзләргә, табарга тиеш була. Нәтиҗәдә укытучының роле дә үзгәрә – гади белем бирүчедән, ул эшнең оештыручысына әверелә. Проектны эшләү барышында төрле ситуацияләр килеп чыга һәм укучылар нәтиҗәдә үзләре проектлаштыруның максатын билгелиләр.

**Проектлаштыру** – ул, һичшиксез гамәли эшчәнлек, анда яңа эшчәнлек ысуллары тумый, бары тик практик бурычларны чишү чарасына әйләнә. Практик бурыч куеп, укучылар аңа үзләренең конкрет чараларын эзлиләр.

**Проект эшчәнлегенең үзенчәлеге:**

1. Укучылар эшчәнлегенең максат һәм бурычлары, аларның шәхси һәм социаль мотивлары буенча билгеләнә. Мондый эшчәнлек билгеле бер предмет өлкәсендә яшүсмерләрнең компетентлыкларын үстерүгә генә түгел, ә башкалар өчен дә әһәмиятле булган продукт булдыру.
2. Проектның үзенчәлеге булып, конкрет ситуацияне анализлау.
3. Укучыларның проект эшенең оештыруы, танып-белү эшчәнлегенең төрле төрләрен тәэмин итә.

**Проект эшенең этаплары:**

– Эзләнү этабы;
– Аналитик этап;
– Практик этап;
– Презентацион этап;
– Контроль этап;

**Эзләнү этабы**

| Укучы | Укытучы |
|---|---|
| Кызыксындырган сорауны билгели, үз фикерен дәлилли;<br>Информацион чыганаклар туплый. | Күзаллауны киңәйтүче темалар тәкъдим итә;<br>Проблемалы ситуацияләр тудыра;<br>Укучыларның сорауларына җавап табу өчен тематик чикләрне билгели. |

**Аналитик этап**

| Укучы | Укытучы |
|---|---|
| Информацияне системалаштыра;<br>Булачак «туачак» продуктны күзаллап тасвирлый;<br>Эш планын төзи. | Күзәтә, алга этәрүче сорау һәм ситуацияләр булдыра;<br>Укучының хронологик тәртиптә эш итүе белән идарә итә;<br>Консультацияләр оештыра. |

**Практик этап**

| Укучы | Укытучы |
|---|---|
| Мөстәкыйль рәвештә план буенча эшли;<br>Эшнең барышы белән уртаклаша. | Мөстәкыйль эшләү мөмкинлекләрен булдыра;<br>Эш барышына карата анализ ясый;<br>«проект дәфтәре» булдыру эшен оештыра. |

**Презентацион этап**

| Укучы | Укытучы |
|---|---|
| Проектны презентацияләү формасын сайлый;<br>Эксперт ролен үти (башка укучыларга карата). | Бәхәс тудыручы сораулар әзерли;<br>Проектны кабул итәргә әзер булган аудитория әзерли. |

**Контроль этап**

| Укучы | Укытучы |
|---|---|
| Бәяләү нормаларына туры китереп, проектка үзбәя бирә. | «проект дәфтәре» булдыру эшен йомгаклый;<br>Алдагы үсеш юлларын ачыклый. |

**Проект өстендә эшләү этаплары:**

– Әзерлек этабы;
– Оештыру этабы;
– Планлаштыру эшчәнлеге;
– Проектны үтәү;
– Әзер продуктны тәкдим итү;
– Эш нәтиҗәсен һәм процессын бәяләү этабы;

**Проектларны дәвамлылыгы буенча классификацияләү**

***Нейропсихологический подход*** в работе логопеда помогает определить незрелость всех психических функций и наметить индивидуальный образовательный маршрут для успешной лого– коррекционной работы.

На что направлены нейропсихологические упражнения:

- развитие концентрации и внимания, координации, умения чувствовать своё тело;
- развитие памяти, мелкой и общей моторики, умения ориентироваться в пространстве;
- работа над гармоничным взаимодействием полушарий;
- активизация речи;
- работа над эмоциональной устойчивостью, повышением внимания и т.д.

**Использование нейроупражнений в работе учителя-логопеда достаточно изучено** и имеет положительные результаты.

Некоторые факты, которые подтверждают степень изученности:

- **Исследования специалистов** нейрофизиологов и нейропсихологов доказывают, что нейропсихологические методы позволяют качественнее оценить тяжесть и локализацию нарушений, а также анатомических структур мозга.
- **По данным разных авторов**, методы нейрологопедии позволяют на 35% быстрее справиться с речевыми нарушениями у детей, чем традиционно применяемые методики.
- **Регулярное использование нейроупражнений** в логопедической работе положительно влияет на коррекционный процесс обучения, улучшает состояние физического, психического, эмоционального здоровья, повышает интерес к занятиям и положительный эмоциональный настрой.
- **Нейропсихологические игры** можно использовать с самого раннего детства, как в индивидуальной, так и в групповой работе и не только с детьми, но и со взрослыми.

Однако, по мнению одного из авторов, успешность применения нейропсихологических методов определяется уровнем владения специалистов методикой, технологией, наличием у него опыта, что определяет необходимость проведения специальных исследований в этой области.

**Цель использования нейроупражнений в работе учителя-логопеда** – активизация речевой активности у детей с речевыми нарушениями.

**Задачи** применения нейроупражнений:

- развитие фонематического слуха, слухоречевого внимания;
- развитие познавательных процессов: речи, мышления, памяти, внимания;

- развитие межполушарного взаимодействия детей;
- развитие согласованности трёх основных блоков мозга.

Также с помощью нейропсихологических игр и упражнений решаются следующие задачи:

- ребёнок учится чувствовать своё тело и пространство вокруг;
- развивается зрительно-моторная координация (глаз-рука, способность точно направлять движение);
- формируется правильное взаимодействие рук и ног;
- развивается слуховое и зрительное внимание;
- ребёнок учится последовательно выполнять действия, разбивая его на ряд задач.

**Выводы об использовании нейроупражнений в работе учителя-логопеда:**

- **Улучшение нейропластичности**. Нейроупражнения помогают способности мозга адаптироваться и изменяться, что важно для детей с речевыми нарушениями, так как позволяет восстанавливать утраченные функции.
- **Развитие координации**. Упражнения, направленные на моторику, улучшают координацию движений, что положительно сказывается на артикуляции и произношении.
- **Стимуляция речевых центров**. Движения и дыхательные упражнения активируют речевые центры, улучшая качество речи и понимание.
- **Развитие когнитивных функций**. Нейроупражнения способствуют улучшению памяти, внимания и восприятия, что напрямую влияет на качество речевой деятельности.
- **Повышение мотивации**. Нейроупражнения в игровой форме делают занятия более увлекательными и мотивирующими для детей.
- **Улучшение эмоционального состояния**. После нескольких месяцев работы с нейроупражнениями у детей повышается уверенность в себе, улучшается произношение, а также общее эмоциональное состояние.
- **Профилактика и коррекция нарушений**. Нейроупражнения способствуют профилактике и коррекции нарушений письма и чтения.
- Для достижения наилучших результатов важно проводить занятия регулярно и следовать заранее разработанному плану.

## ТАТАР ХАЛЫК УЕННАРЫ – ГАИЛӘДӘ ТУГАН ТЕЛНЕ, МӘДӘНИЯТНЫ САКЛАУ ЧАРАСЫ

**Хәкимова Галия Илгизәр кызы**
**Сәлимуллина Гүзәл Әгзам кызы**
*«Татар телендә тәрбия һәм белем бирүче*
145 нче катнаш төрдәге балалар бакчасы»
Татар телен укыту буенча тәрбияче, тәрбияче

«Без барыбыз да балачактан», – дигән атаклы язучы Экзюпери. Бу – чыннан да, шулай. Кем генә булсак та – язучымы, укытучымы, әллә гади бер эшчеме – күңел балачакка еш әйләнеп кайта. Ә балачактагы иң истәлекле, иң кызыклы әйбер ул – уеннардыр, мөгаен. Нindiләре генә юк аларның? «Түбәтәй», «Яшерәм яулык», «Итек-читек», «Утыр-утыр Мәликә» «Чума – үрдәк, чума каз» – хәер, аларны санап бетерерлек түгел. Менә шушы уеннар безне физик яктан да, рухи яктан да камилләштергән. Алай гына да түгел, алар бездә дуслык, иптәшлек, гаделлек, кыюлык, зирәклек, тапкырлык кебек сыйфатлар да тәрбияләгәннәр.

Сез уйный беләсезме? Бу сорау, мөгаен, сезгә кызык тоелыр. Чыннан да, безнең балаларыбыз уйный беләме соң? Балалар гына түгел аларның ата-аналары да татар халык уеннары белән таныш түгел. Ә иң мөһиме һәм иң кызганычы – алар балаларыны, нинди уен уйнатырга, нәрсә

белән кызыксындырырга икәнен үзләре дә белмиләр. Уен уйнатырга, уйнарга, яңа мавыктыргыч уен эзләргә вакытлары да юк! Иң кулае – баланың кулына телефон биреп, балам бар уйна, кымачаулама минем эшем бик күп дип әйтүе бик җайлы. Чыннан да игътибар белән күзәтсәк, балаларыбыз шактый вакытларын кәрәзле телефон, телевизор каршында үткәрергә ярата. Шуңадыр, бәлки, без, олылар арасында «алар уйный беләмени?» дигән фикер дә очрый. Кайвакыт эти-әниләр бала тормышында уеннарның нинди зур әһәмияткә ия булуын онытып җибәрде. Ә бу исә баланың кече яшьтән үк чыныккан, хәрәкәтчән һәм җитез булып үсүенә комачаулый.

Мәктәпкәчә тәрбия учреждениеләренең төп бурычы балаларны рухи яктан бай, физик яктан сәламәт итеп үстерү. Алар төрле юллар белән тормышка ашырыла. Ә шулар арасында иң әһәмиятлесе – уеннар.

Уен – ул бала эшчәнлегенең, тормышының аерылгысыз өлеше. Алар – балаларны уйланырга, эзләнергә, фикер тупларга, берләштерергә, күнекмәләрне, гадәтләрне тормышта кулланырга өйрәтүче һәм тәрбия бирүче көчле чараларның берсе.

Татар халык уеннары – милләтнең бай рухи хәзинәсе. Ул баланың иҗади үсешен тәэмин итә, рихи – әһләкый яктан үстерә, тирә – юн белән таныштыра, татар телен, мәдәниятен, халыкнын көнкүреше турында тулы мәгълүмат бирә.

Шуна күрә үз алдыма зур **бурыч** итеп балаларны һәм ата-аналарны татар халык уеннары белән таныштыруны куям.

Уеннарны оештырганда үз алдыма түбәндәге **максатларны** куям**:**

– ата-аналарны татар халык уеннары белән таныштыру;
– балаларны татар халык уеннарына өйрәтү;
– балаларның сөйләү һәм фикерләү сәләтен үстерү;
– татар әдәби телен төрле өлкәләрендә иректе куллана белү;
– дөрес сөйләм эшчәнлегенең үзара аралашу чарасы булдыру;
– ата-аналар һәм балалар арасындагы аралашуны, көндәлек сөйләмдә ана телен камил куллана алу;
– халкыбызның бай рухи дөньясы белән танышуны дәвам итү;
– татар халкы белән горурлану хисләре тәрбияләү өстендә эшләүне дәвам итү.

Уеннар кешегә яшәве күңеллерәк булсын өчен дә кирәк дияргә мөмкин. Балага җитез, өлгер, зирәк булып үсү өчен төрле характердагы уеннарның әһәмияте бик зур. Яшь буын тормышның төрле җайсызлыкларына бирешмәскә, уңайсызлыкларыннан җебеп төшмәскә тиеш дибез. Ә моңа яшьтән үк балаларның төрле уеннарда катнашуы аша ирешергә мөмкин.

Халык уеннары – җитезлеккә, көчкә, зирәклеккә сынау ул. Аларда халыкның гасырлар буена тупланган традицияләре буыннан-буынга бирелә. Халык уеннары һәрвакыт актуаль, чөнки алар үткәннәр аша кешенең киләчәгенә юнәлдерелә. Уеннар баланың шәхес буларак төрле яклап үсүен тәэмин итә, моның өчен шартлар тудыра. Татар халык уеннарының күбесе җырлар белән бергә башкарыла. Аларга моң, төгәл ритмика, отып калуда да җиңеллелек хас.

Шуннан чыгып, үз төркемемдә балалар белән татар халык уеннарын өйрәтә башладым. Бу уеннар балаларда зур кызыксыну уятты. Иң беренче уенның тарихын, уйнау тәртибен, кагыйдәләрен аңлатам. Уен өчен мөһим булган – шигырьләр, җырлар, әйтемнәр, санагычлар, мәкальләр өйрәнәбез.

Безнең балалар белән күмәк, иҗади эшебез, ата – аналарда зур кызыксыну уятты. Алар балалар, өйрәнәсе килгән ләкин өйрәнеп өлгермәгән сүзләрне, җырларны, такмакларны өйдә өйрәнер өчен сүзләрен өйгә бирергә сорый башладылар. Шунлыктан балар белән өйрәнелгән уеннардан торган мастер-класс әзерләргә булдык.

Мастер-классыбыз төрле уеннарны үз эченә алган видеоматериаллардан тора. Сезнең өчен дә биш уеннан торган видео кисәкләр тәгъдим итәсебез килә.

Алар: «Түбәтәй», «Яшерәм яулык», «Итек-читек», «Утыр-утыр Мәликә» «Чума үрдәк, чума каз». Уеннарда бөтен төркем дә катнаша ала, шулай ук кечкенә төркемнәр белән дә уйнап була.

Балалар бу уеннарны бик яратып уйныйлар, уеннар тәрбияви, үзенчәлекле үтсен өчен, төрле ысуллар кулланып өйрәтергә тырышам. Шул уеннарның берничәсенә тукталып китәсем килә. Мәсәлән, «Чума үрдәк, чума каз», уен барышында матур җырлар өйрәнүдән тыш, татар халкының борынгы гореф-гадәтләре, йолалары белән танышабыз. Аулак өй, кич утыру йолаларының әһәмияте, үзенчәлеге турында сөйлим.

«Итек-читек» уенын уйнаганда, балаларны читекче һөнәре белән таныштырабыз. Халыкның милли киемнәре, дан казанган бизәлгән читекләре турында күбрәк мәгълүмат бирәбез, милли орнамент үрнәкләре белән танышабыз.

«Яшерәм яулык» уенында миили бизәкләр белән танышуны дәвам итәбез. Татар халкының чигү үрнәкләре, чигүле алъяпкычлар, мендәр тышлары, чигүле куляулыклар күрсәтеп, матур күргәзмәләр оештырабыз.

Уеннар мавыктыргыч булсын өчен уен оештыруда берничә файдалы **киңәш** тәкъдим итәсем килә.

1. Уенны башка шөгыль белән алыштырырга тырышмагыз.
2. Уенны бала тормышының барлык өлкәләрендә дә кулланыгыз.
3. Бала сезне уенга чакырса, шатланыгыз, димәк ул сезне үз итә һәм сезгә ышана.
4. Бала белән уйнаганда, үзегезнең олы кеше икәнлегегезне онытыгыз.
5. Балага уеннан «мәхрүм итү җәза»сын бирмәгез.
6. Уен кагыйдәләрен бозган балага тынычрак карарга тырышыгыз.
7. Уен вакытында рольләрне көчләп такмагыз.
8. Чираттагы эш көненә әзерләнгәндә, һәр яңа уенның балага иң яхшы бүләк икәнен исегездән чыгармагыз!

Татар халык уеннары балаларның уен кагыйдәләрен үтәргә ирешүләренә, хәтерне үстерүгә, әйләнә-тирәдә ориентлашырга, зирәклеккә, роль башкарырга өйрәтә, әхлак сыйфатлары тәрбияли, җитезлек, өлгерлек һәм кыюлыкларын үстерә, хезмәттәшлек, җаваплык шикелле сыйфатлар тәрбияли. Уртак шатлык балаларны шәхес буларак үстерә, камилләштерә.

Ата – аналар өчен бу видеодан торган мастер-класслар, татар халыкының – бай тарихы, мәдәнияты, көндәлеге белән таныштыруда зур роль уйный. Балаларның сөйләм телен камилләштерү өчен зур чара икәнлеген ачыклый.

## ЦИФРЛАШТЫРУ ЧОРЫНДА ПЕДАГОГ, НАСТАВНИК ҺӘМ МЕНТОР

**Халитова Гөлшат Галимҗан кызы**
**Шәрифуллина Ләйсән Мәүләтхан кызы**
*Казан шәһәре Совет районы*
*119 нчы балалар бакчасы*
*1 категорияле тәрбиячеләр*

Цифрлаштыру – безнең тормышның аерылгысыз өлеше. Ул тормышның төрле өлкәләренә торган саен ныграк үтеп керә. Хәзер түләүләрне дә өйдән чыкмыйча гына башкарабыз, табибка чиратка язылабыз, еракта яшәүче туганнарыбыз белән аралашабыз. Әлбәттә, бүгенге көн балалары да «кулына гаджет тотып туа». Үсеп килүче буынның тормышны гаджетсыз күз алдына да китерә алмавы берәүгә дә сер түгел. Ләкин бүген максатыбыз цифрлаштыруның уңай һәм тискәре якларын, аның яшәү рәвешебезгә ничек йогынты ясавын ачыклау түгел.

Безнең максат – гаҗәеп мөмкинлекләр биргән цифрлаштыруны файдалы итеп куллана белергә өйрәнү, **цифрлаштыру чорында традицияләрне саклап, киләчәккә атлау.**

Ләкин менә ничек ул максатка ирешергә, гореф-гадәтләрне саклап, гомумкешелек кыйммәтләренә тугъры калган хәлдә яңа заманга ничек яраклашырга? Замана балалары белән ничек уртак тел табарга?

Иң элек «Нинди ул яңа заман баласы?», – дигән сорауга җавап табып карыйк. Бала ул кайсы чорда туса да бала-төрле холыклы, төрлечә сәләтле, тирә-якны, дөньяны танып-белергә омтылучан. Ләкин кайсы чорда тууы, илдә, икътисадта, җәмгыятьтә барган үзгәрешләр аның үз-үзен тотышына, карашларына нык тәэсир итә. Психологлар шушы факторларга бәйле рәвештә соңгы 100 елда туган берничә буынны аералар.

«Туганда ук кулларына гаджет булган» дип нәкъ менә шушы буын хакында әйтәләр дә инде. Алар кечкенәдән үк үзләренә кирәкле мәгълүматны бик тиз эзләп таба һәм куллана белә. Альфа буыны балалары кечкенәдән үзләрен шәхес итеп тоя, үз-үзләренә ышанган, мөстәкыйльлек яратучы булып үсә. Шуңа күрә алар белән авторитар стильдә аралашу туры килми. Педагогикада баланың индивидуаль үзенчәлекләрен исәпкә алып эшләү алымы турында күптән сүз бара. Безнеңчә, альфа буыны белән аралашканда, тәрбияләгәндә һәм уртак эшчәнлек барышында шәхси һәм индивидуаль үзенчәлекләрен исәпкә алу бигрәк тә кирәк.Альфа буын балалары белән берничә ел эшләгәндә без түбәндәге нәтиҗәләргә килдек:

• *Алар өчен барысын да күз алдына китерү мөһим, шуңа күрә теләсә нинди мәгълүмат визуаль булырга тиеш!*

• *Барысын да тиз эшләргә кирәк!*

• *Аерылып торырга өйрәнергә кирәк!*

• *Яңа мәгълүмати технологияләр, интернет-ресурслар белән эш итәргә өйрәнү мөһим.*

ИКТ ресурсларын дөрес һәм продуктив куллана белү пандемия шартларында аеруча актуаль булды. Педагоглар алдында булган практикаларны интерактив форматка салу һәм үзгәртү бурычы куелды. Бу эш мәктәпләр һәм югары уку йортларында гына түгел, балалар бакчаларында да барды. Әти-әниләр җыелышлары, мастер-класслар, иҗади мәйданнар ***стрим*** юнәлеш алды (реаль вакытта турыдан-туры аралашу).

Педагогларның цифрлы технологияләрне куллану даирәсе хәзер дә киң:

– дистанцион белем алуда, онлайн семинарлар, вебинарларда;
– электрон документ әйләнеше, педагогик документация;
– онлайн бәйгеләрдә;
– балалар белән Zoom эшчәнлекләрдә;
– педагогик аттестация үткәндә;
– методик лабораторияләр, сайтларалып барганда;
– балалар белән эшчәнлек вакытында.

Компьютер чаралары танып-белү, тикшеренү, уен эшчәнлеге процесслары замана балалары өчен көндәлек, кызыклы шөгыль, яңа белемнәр һәм тәэсирләр алу өченкулай ысул булып тора. Без белем бирү процессында ***мультимедиа-презентацияләр*** кулланабыз.

Моннан тыш, ИКТ ресурсларның ***милли мирасны өйрәнү һәм саклауда*** да роле зур. Балалар бакчасында бигрәк тә борынгы гореф-гадәтләребез, тарихыбызны өйрәнгәндә уңайлы. Гадәттә, музейларга еш бара алмыйбыз. Музей-күргәзмәләргә онлайн экскурсияләр ясау балаларны әби-бабаларыбызның борынгы чорлардагы тормышы белән танышырга мөмкинлек бирә. Күп кенә методик ярдәмлекләрнең, балалар өчен хрестоматияләрнең электрон формасы булу да педагогларның эшен күпкә җиңеләйтә. Без шулай ук **«Бала РФ мультимедиа китапханәсе»н** ябатып кулланабыз. Биредә куар-код аша кереп татар язучыларының әсәрләренә төшерелгән мульфильнарны карарга була. Соңыннан әсәрнең эчтәлеге буенча сорауларга җавап та бирергә кирәк. Шулай ук интерактив уеннар да бар. Ә инде татар телен һәм Идел буе халыклары– рус, чуаш, мордва (эрзя), мордва (мокша), мари һәм удмурт телләрендә иң күп кулланыла торган сүзләрне һәм дә алфавитны үзләштерергә ярдәм итү максатыннан **«Аваз»** проекты эшләп килә.

Куар-кодлар турында аерым әйтеп китмичә булмый. Хәзерге вакытта төрле газета-журналлар, шул исәптән балалар өчен булганнары да куар-код аша кереп карап була торган материаллар белән тулыландырылган. Бу журналларның эчтәлеген дә күпкә кызыклы итә. Без төркемебезгә

«Салават күпере» журналын яздырып алабыз. Башта журналдагы әкиятләрне-шигырьләрне балаларга кычкырып укыйбыз, рәсемнәрен күрсәтәбез. Аннан куар-кодаша кереп мастер-классларны үтибез, **«Салаватiklар»**га кушылып җырлыйбыз, биибез.

Әлбәттә, цифрлаштыру технологияләрен кертү өчен, иң беренче, матди-техник база булуы шарт. Бу яктан безнең балалар бакчасында матди база җитәрлек: интерактив такталар, проекторлар, компьютер, рейбуклар, LEGO робототехникасы, ком өстәлләре, график планшет һ.б.

Бакчабызда «Могҗизалар илендә» дип исемләнгән мультистудия булдырылды. Аның махсус сәхнәсе, ел вакытларын чагылдыручы арткы бизәлешләре бар. Зурлар төркеме балалары белән «Могҗизалар илендә» мультстудиясендә «Нәни мультипликаторлар» авторлык проекты буенча түгәрәк эше алып барыла.

Интерактив такталар, проекторлар, компьютер, рейбуклар, LEGO робототехникасы, ком өстәлләре, график планшет кебек җайланмалар ярдәмендә без мультфильмнар төшерәбез. Мультфильм төшерү эше балалар өчен бик мавыктыргыч. Без башта әкият яки шигырьнең эчтәлеге белән танышабыз. Аннан геройларны барлыйбыз һәм төсле пластилиннан персонажлар әвәлибез. Бу балаларның фантазиясен тулы көченә эшкә җигү өчен дә менә дигән мөмкинлек. Әлеге алым балаларның татар телендә сөйләмен камилләштерү өчен дә бик файдалы.

Хәзерге шартларда яңа технологияләр кулланырга кирәклеге бәхәссез. Әлбәттә, без аны мәктәпкәчә белем бирүдә куллану турында җитди уйларга, балаларның яшенә туры килгән материал сайлап рөхсәт ителгән күләмдә генә кулланырга тиеш. Ләкин чамасын белеп кулланганда замана технлогияләренең бик күп уңай якларын табарга була. Шәхсән үземә килгәндә, эшчәнлегемә цифрлаштырылган мәгариф технологияләрен кертү, беренче чиратта, тәрбия һәм белем бирү процессын активлаштырырга һәм индивидуальләштергә, белем бирүнең сыйфатын күтәрергә булышты, эшемне оптимальләштерү өчен мөмкинлекләр ачты.

**Кулланылган әдәбият**


1. Журнал «Генеральный директор». 7 способов подстроить поколение Z на благо компании. 2017 г. https://www.gd.ru/articles/9356-pokolenie-z
2. Кристина Миронюк. Ты моргнуть не успеешь, как центениалы захватят мир!
3. Всё, что нужно знать о поколении Z. https://takprosto.cc/pokolenie-z/
4. Гараева Л.// Икс, игрек, зет//Сөембикә № 1/2023// «Татмедиа» АҖ
5. Вагизова А. Ф.//Балалар бакчаларында цифрлаштыруның әһәмияте// Мәгариф, 2022.

# ИНСТРУМЕНТЫ И МЕТОДЫ ВОСПИТАНИЯ РОССИЙСКОЙ ГРАЖДАНСКОЙ ИДЕНТИЧНОСТИ

## ТВОРЧЕСТВО КАК СМЫСЛ ЖИЗНИ ШКОЛЫ

**Нигматуллина А. А.,**
*заместитель директора по НО*
**Исмагилова Р. Д.,**
*заместитель директора по ДО*
**Нигматуллина Л. Н.,**
*учитель родного языка*
*МБОУ «Школа № 100 – Центр образования»*
*Приволжского района г. Казани*

**Краткое описание проекта**

В нашей школе обучаются дети различных национальностей: русские, татары, таджики, чеченцы, чуваши, марийцы… Всего 446 учеников, из них 187 – русских, а остальные 259 – татары и дети других национальностей. Татарский язык изучают 100%. Однако не каждый ребенок знает язык своих предков, культуру своего народа. У современных детей очень «скудный» запас знаний и представлений о том, как жили их предки, какие они соблюдали традиции и обычаи, чем украшали свой быт, как одевались, какие игры были у детей, какие праздники. Создание творческой студии в рамках проекта «Творчество как смысл жизни школы» позволит учащимся приобщиться к культуре родного народа. В творческой студии найдет место каждый, кто хочет развить свой актерский талант, свои способности, систематизировать уже имеющиеся знания и творческие навыки, раскрыть творческий потенциал и придать себе внутренней уверенности.

Проект создан в целях изучения родных языков, народного искусства, сохранения культурных традиций, памятников истории и культуры, этнокультурного многообразия, культурной самобытности всех народов и этнических общностей народов, проживающих в Республике Татарстан. Для многонациональной Республики очень важно сохранение и развитие языкового наследия. Именно поэтому сегодня так актуальны праздники, мероприятия, посвященные родному языку, родной культуре. Языки являются самым сильным инструментом сохранения и развития нашего наследия.

В рамках проекта в творческой студии проводятся мероприятия по популяризации родных языков. Учащиеся школы знакомятся с культурой народов, проживающих на территории Республики, узнают много нового и интересного, раскрывают свои способности: изучают национальные костюмы, блюда и готовят их, угощая всех на праздниках; изучают творчество поэтов, поют песни и декламируют стихи на родном языке; ставят спектакли, исполняют танцы своего народа.

**Цель проекта**: Создание условий для популяризации народного искусства и языков народов, проживающих в Республике Татарстан, для творческого развития и реализации способностей учащихся.

**Задачи проекта:**

– расширить знания обучающихся о языках народов, проживающих в Республике Татарстан;

– сохранять преемственность поколений, воспитывать бережное отношение к языковому и культурному наследию народов РТ;

– создавать благоприятную эмоциональную атмосферу общения обучающихся, их самовыражения, самореализации, позволяющей «найти себя» поверить в свои силы, преодолеть робость и застенчивость;

– прививать любовь к творчеству

**Срок реализации проекта:** 1.09.2024–31.12.2026

**Обоснование значимости проекта:**

В настоящее время Россия переживает сложное время – время социальных перемен. Сегодня мы на многое начинаем смотреть по-иному, многое для себя заново открываем и переоцениваем. Это относится и к прошлому нашего народа

Дальнейшее развитие народа органично связано с возрождением его культуры. В этой связи нам нужно усилить работу по сохранению, созданию, распространению и освоению культурных ценностей, развитию национальных и культурных традиций, декоративно-прикладного искусства, сохранения национальной и культурной идентичности, и приобщить к этому подрастающее поколение. Развитие культуры поможет молодежи постичь духовные истоки своего народа, сохранить этнокультурную память.

Актуальность этой проблемы в наше время очень велика и нам, педагогам, необходимо проводить с учащимися большую работу в данном направлении: от возрождения колыбельной, языка, умения рассказывать детям сказки и предания своего народа, до приобщения детей к художественным промыслам и декоративно-прикладному искусству.

Проект направлен на сохранение культурного наследия народов, населяющих Республику Татарстан, развитие творческого потенциала обучающихся, преследует цель обеспечения преемственности культурных традиций, сохранения и развития родного языка, направленных на воспитание подрастающего поколения в культурных традициях своего народа, приобщения к истокам народной культуры, формирование средствами культуры духовных ценностей, направленных на воспитание чувства национальной гордости, гражданственности и патриотизма.

Проект способствует развитию творческих способностей учащихся, формированию высокой нравственности, воспитывает любовь к Отечеству, уважение к предкам.

**Описание опыта работы в указанном направлении (за последние 3 года):**

В нашей школе работают творческие учителя и обучаются талантливые ребята. В течение последних 3 лет ученики школы занимают призовые места на конкурсах чтецов произведений на родном языке, принимают участие в вокальных конкурсах. Особенно в этом направлении хочется отметить учеников которые учатся вокальному искусству Ганибаева Инсафа и Нурманову Миляушу. Они являются победителями и лауреатами международных конкурсов, как «Созвездие-Йолдызлык», «Казан сандугачы», «Казан йорт», лауреаты фестиваля Р.Вагапова, стипендиаты Мэра.

Большая работа ведется педагогами по изучению родного татарского языка, в результате работы ученики школы становятся призерами муниципального этапа республиканской олимпиады школьников по татарскому языку. Знание родного языка помогает при участии в научно практических конференциях.

Ученики 2 класса являются частыми гостями телеканала Шаян ТВ. Они с удовольствием рассказывают стихотворения, показывают инсценировки.

2021 год в РТ был объявлен Годом родных языков и народного единства. В связи с этим учителя родного языка провели мероприятие, посвященное открытию Года родных языков и народного единства в РТ; конкурс чтецов «Родное слово»; проводились выставки книг на родных языках, литературные чтения и обсуждения произведений национальных авторов; организовали встречу с татарским поэтом Рифатом Салахом, Йолдыз Шараповой; с детским журналом «Салават күпере». Организовались совместно с ДК «Отары» фестивали национальных культур, конкурсы народного творчества. Наши ученики начиная с 2021 года по сегодняшней день участвуют в уникальном проекте «Хәрәкәттә-бәрәкәт», проект «Сөйлә». Это лишь некоторые из мероприятий, проведенных в рамках Года родных языков и народного единства. Они способствуют укреплению межнационального сотрудничества, сохранению языкового и культурного наследия и формированию уважения к многообразию народов. Ученики школы с удовольствием принимают участие во всех мероприятиях, изучают родной язык, традиции и обычаи своего народа.

**Целевые группы проекта:** школьники 7–18 лет

**Социальные партнеры проекта**: родители обучающихся, Средняя специальная музыкальная школа № 22 Приволжского района, Дом Культуры «Отары».

**Ожидаемые количественные и качественные результаты проекта:**

1. Повышение интереса и мотивации обучающихся к изучению родного языка и культуры.
2. Повышение актерского мастерства обучающихся.
3. Реализация творческого потенциала учащихся в совместной деятельности с педагогами и родителями
4. Активное участие учащихся в творческих конкурсах

**Руководитель проекта:** Абдуллина Рахиля Дамировна – директор школы;
**Команда проекта:** Нигматуллина А. А. – заместитель директора по НО;
Исмагилова Р. Д. – заместитель директора по ДО;
Нигматуллина Л. Н. – учитель родного языка.

**Информационная открытость/публичность**

Информационная открытость, публичность достигается путем размещения информации о деятельности Творческой студии на сайте школы и в школьной группе в Контакте, публикации материалов, организации встреч, семинаров, взаимодействия с театрами, музеями организациями, школами района, города, республики.

## НАСТАВНИЧЕСТВО КАК ЭЛЕМЕНТ РАЗВИТИЯ ПЕДАГОГИЧЕСКОГО КОЛЛЕКТИВА

**Акашина Ниля Мухамедовна**
*МБОУ «Школа№ 9»*
*Ново – Савиновского района г. Казани*
*Заместитель директора по учебной работе*
*по вопросам национального образования,*
*Почетный наставник РТ*

***«Наставничество – серьезный, ответственный процесс, поэтому большую роль играет изначальная мотивация педагога»***

Наставничество – это процесс обмена знаниями и опытом между молодым учителем, который не обладает необходимыми знаниями и навыками в определенной области, и учителем, который имеет соответствующие знания и опыт и готов ими поделиться. Как правило, наставника назначают при приеме на работу молодого учителя для того, чтобы ускорить его адаптацию, помочь быстрее втянуться в работу компании, быстрее обучиться новой работе, успешнее выполнять новые обязанности и быстрее приступить к самостоятельной работе.

Наставник лично обучает молодого учителя, быстро реагирует на допущенные им ошибки, детально их разбирает и подсказывает, как правильно поступить в той или иной рабочей ситуации.

**Сегодня я уже смело могу говорить о результатах своей работы:**

– создана система работы, которая объединяет деятельность молодого учителя и наставника;

– применяются эффективные формы и методы работы, которые содействуют дальнейшему профессиональному становлению молодого специалиста;

– молодой учитель ведет работу по самообразованию, что позволяет ему пополнять и конкретизировать свои знания, осуществлять анализ возникающих в работе с детьми ситуаций;

– у молодого учителя формируется потребность в постоянном пополнении педагогических знаний, гибкость мышления, умение моделировать и прогнозировать образовательного процесса;

– молодому учителю обеспечена необходимая помощь и поддержка на самом трудном этапе вхождения в новый коллектив и профессию.

Таким образом, использование системы наставничества позволяет учителям быстро адаптироваться к работе в школе, почувствовать уверенность в своих силах, убедиться в правильности выбора профессии, наладить плодотворное сотрудничество с коллегами, проявить себя грамотным учителем. Не меньше пользы приносит эта система и наставнику.

Работа с молодыми специалистами помогает повысить свою профессиональную компетенцию: стараюсь следить за новинками методической литературы, участвую в педагогических конкурсах, конференциях, использую в работе инновационные технологии.

Общаясь с молодыми коллегами, приобретают новые взгляды на развитие и воспитание детей.

С 2005 г. являюсь наставником молодых учителей по родному (татарскому) языку и литературе Ново-Савиновского и Авиастроительного районов г. Казани. Для этого занимаюсь самообразованием и передачей собственного опыта учителям родного (татарского) языка и литературы через участие в профессиональных конкурсах, проведение семинаров республиканского, международного уровней, выступления и проведения мастер – классов на муниципальном, городском, республиканском, федеральном, международном уровнях. Стимулирую молодых педагогов к использованию в работе новых педагогических технологии, мотивирую их к участию в работе сетевых сообществ создании и реализации творческих проектов, в конкурсах профессионального мастерства.

Сама я лауреат премии имени Каюма Насыйри (за заслуги в развитии национального образования), МО и науки Республики Татарстан, 2015 г., в конкурсе «Лучшие механизмы педагогических работников дополнительного профессионального образования субъектов РФ, осуществляющих преподавание предметной области «Родной язык и родная литература» заняла II место, г. Москва (очное участие), 2021 г., финалистка Всеросссийской научно – практической конференции «Наставничество в образовании: современная теория и инновационная практика», 2016 г., 2019 г. Учителя родного (татарского) языка и литературы активно участвуют в районном этапе городского тура «Учитель года» в номинации «Учитель татарского языка и литературы». Консультирую учителей родного (языка) и литературы для активного использования учебно – методического пособия «Сәлам!» по татарскому языку, участвуют в апробации внедрения новых УМК по татарскому языку и современных педагогических технологий преподавания татарского языка и литературы. С 2019 г. совместно с молодым учителем Галимовой Л. И. организовываю и провожу на базе МБОУ «Школа № 9» международный диктант «Яз» на татарском языке в целях популяризации родного языка.

Являюсь руководителем педагогической практики студентов 4,5 курсов Института филологии и межкультурной коммуникации Казанского Федерального университета отделения татарской филологии и межкультурной коммуникации им. Г. Тукая.

В 2022 г. была в числе лучших учителей города Казани (Билборд, посвященный профессиональному празднику «День учителя), 05.10.2023 г. приняла участие в радиопередаче «Фидакәрләр» Татар Радиосы (Казань) с предоставлением своего педагогического опыта.

Главное в работе – видеть результат своего труда и это является стимулом для дальнейшей работы и хочется делать еще больше.

# ШКОЛЬНЫЙ МУЗЕЙ КАК ОДНО ИЗ СРЕДСТВ ФОРМИРОВАНИЯ ПАТРИОТИЗМА И ГРАЖДАНСТВЕННОСТИ В ПРАКТИКЕ РАБОТЫ УЧИТЕЛЯ

**Бронникова Эльвира Камилевна,**
**заведующий**
**Ахсанова Роза Василовна,**
**старший методист**
*УМС ИМО УО ИКМО г. Казани*
*по Авиастроительному и Ново-Савиновскому районам*

В современных условиях особую важность приобретает обращение к культурному наследию прошлого, духовному опыту, накопленному человечеством за многие века. Именно поэтому в наши дни обретают такую высокую значимость музеи, как хранители ценностей прошлого. Для патриотического воспитания наиболее реальным путем к ребячьим сердцам стало продолжение, а во многих случаях возрождение школьных музеев, направления работы которых достаточно обширны, что позволяет активно включать его в целостный образовательный и воспитательный процессы.

В образовательных организациях Авиастроительного и Ново-Савиновского районах действуют 38 школьных музеев, из них 21 этнографический и 17 военно-патриотических. В 43 учреждениях созданы уголки Боевой славы и Музейные комнаты. Памятники и мемориальные доски закреплены за 19 образовательными организациями.

Школьные музеи являются центром военно-патриотического, гражданского, этнокультурного воспитания подрастающего поколения, центром жизни школы.

Целью школьных музеев патриотической направленности является создание условий для приобщения обучающихся к гражданско-патриотическому воспитанию.

Задачи: вовлечь детей в научно-исследовательскую деятельность; формировать их гражданское сознание и патриотизм; развивать интерес учащихся к истории, политике, к жизни людей, к своей семье; формировать гордость за сопричастность к деяниям предков и современников, исторической ответственности за происходящее в обществе; способствовать становлению активной жизненной позиции; воспитывать чувство патриотизма, гуманизма, нравственных и культурных ценностей.

Уникальная среда школьного музея позволяет интегрировать содержание, формы организации общего и дополнительного образования, педагогические технологии и методы деятельности, знания различных научных областей, формировать предметные, межпредметные и ключевые компетенции школьников, развивать навыки межличностной коммуникации. Деятельность музея значительно расширяет кругозор учащихся, развивает интеллектуальную, эмоциональную, творческую сферы личности.

Гражданско-патриотическое воспитание, как и воспитание вообще, должно основываться на знании тех компонентов бытия, культуры, которые формируют в целом представления учащихся о Родине, ее культурно-исторических традициях, достижениях и ценностях, лучших ее представителях. Решению данной задачи служат школьные музеи, деятельность которых направлена на формирование социально-активной позиции, личное участие, поиск и постижение социального и духовного начала своей Родины, народа. Важное место в решении этой задачи занимает непосредственный контакт воспитанника с историческими материалами, элементами культуры, осуществляемый в условиях школьного музея.

Музей обладает огромным образовательно-воспитательным потенциалом, так как он сохраняет и экспонирует подлинные исторические документы. Эффективное использование этого потенциала для воспитания учащихся в духе высокой нравственности, патриотизма, гражданского самосознания является одной из важнейших задач школьного музея. Участие детей в поисково-собирательной работе, изучении и описании музейных предметов, в создании экспозиций, проведении экскурсий, вечеров, конференций способствует заполнению их досуга. В процессе исследовательской деятельности учащиеся овладевают различными приемами

и навыками краеведческой и музейной профессиональной деятельности, а в ходе краеведческих изысканий – основами многих научных дисциплин, не предусмотренных школьной программой.

Когда мы говорим о патриотическом воспитании, то в первую очередь подразумеваем, формирование у молодого человека чувства любви к своей малой родине, ответственности за её благополучие и процветание, а через этот «мосток» прокладываем путь к гражданской ответственности за всю страну, её безопасность и суверенитет. И главная роль в этом принадлежит краеведению. В учреждениях района создано 17 краеведческих музеев, уголков и музейных комнат.

Значение краеведческой работы переоценить трудно. Занимаясь краеведением, ученик чувствует себя субъектом исторического процесса, осознаёт, что именно он, его родители, друзья, соседи делают историю своего района, города, республики, а, значит, и страны.

Школьник, посредством работы с местным материалом, глубже усваивает и программные темы. В основе краеведческой работы лежит исследовательский метод, который позволяет научиться формулировать цели, задачи исследования, планировать рабочий процесс, двигаться от намеченного и делать собственные выводы. Краеведческое исследование предполагает кропотливую работу с литературой, документами, цифрами, фактами.

Из учащихся, которые проявляют особую заинтересованность созданы советы музея. Именно эти ребята проводят экскурсии для учащихся, участвуют в разработке и реализации многочисленных акций, принимают участие в конкурсах различного уровня, занимаются поисково-исследовательской деятельностью, реставрационными и оформительскими работами.

Формы работы в школьном музее различны: ревизия фондов музея и оформление летописи школы, поисковая работа и написание очерков о ветеранах Великой Отечественной войны и ветеранах труда, тематические встречи, оформление выставок, проведение праздников и многое другое.

Школьный музей является не только хранителем экспонатов, документов, но и местом, где проводят музейные уроки. Общаясь в музее с педагогами, школьники через призму визуального восприятия принимают историю, которая принимает живые очертания. Формируя наглядно-действенное мышление, школьник активнее запоминает информацию, воспроизводит полученные знания и может применить ее в жизни.

Таким образом, деятельность музея в школьной образовательной организации представляет собой системообразующую структуру, в рамках которой осуществляется образовательная и воспитательная деятельность, ориентированная на гражданско-патриотическое воспитание подрастающего поколения. Основным показателем эффективности деятельности школьного музея является личность, формирующая целостное понимание исторического развития страны, ценящая значимость ее культурного и исторического прошлого для современности.

## МИЛЛИ ТРАДИЦИЯЛӘР АША УКУЧЫЛАРГА МИЛЛИ ТӘРБИЯ БИРҮ

**Габделвәлиева Розалия Зөфәр кызы**
*Аксубай муниципаль районы МБББМ*
*«З. Т. Шәрәфетдинов исемендәге Карасу төп мәктәбе»*
*Туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучысы*

Тормышта очрый торган куркыныч хәлләрдән, явызлыклардан гыйбрәт ала белмәгән, мондый тормыш рәвешенең әхлаксызлыгын аңламаган кеше үзен бәхетсез тормышка дучар итә, үзенең нәселен пычрата, ата-бабаларының бай рухи байлыгын юкка чыгара. Бу, үз чиратында, милләтнең, халыкның, ил-җирнең тотрыклы үсешенә тискәре йогынты ясый.

Мәктәптә милли тәрбия процессы – катлаулы, кешелек җәмгыятенең иҗтимагый, икътисадый, сәяси, педагогик һәм психологик шартларына бәйле күренеш. Милли яшәешкә юнәлеш бирүче милли тәрбия системасын ачыклаганда, күренекле педагоглар Р.Фәхреддин, К.Насыйри,

М. Х. Корбангалиев, М. И. Мәхмүтов, В. С. Казыйханов хезмәтләре нигез итеп алынды. Бүген дә милли мәгариф өчен кыйммәтен югалтмаган бу педагогик хезмәтләр эшне максатчыл һәм нәтиҗәле итеп оештырырга кирәклеген искәртеп тора. Галимнәрнең өйрәтүләре бүгенге заман таләпләренә туры килә.

Милли тәрбия бирү нигездә дүрт юнәлештә алып барыла:

1. Укучыларны кешелек җәмгыятенең әхлакый нигезләре булган гомумкешелек кыйммәтләре белән таныштыру, аларның асылын аңлату, таныту.

2. Укучыларда җәмгыятьтә мөнәсәбәт нормалары булган гомумкешелек сыйфатларын формалаштыру.

3. Укучыларда милләт буларак яшәүнең төп шарты булган милли үзаң формалаштыру.

4. Укучыларның үз милләтенә хас уңай сыйфатларга ия булуы.

Дәресләрдән тыш тәрбия эшләре алып бару – балаларга төп белем бирүнең, аларны шәхес буларак үстерүнең аерылгысыз бер өлеше.

Мәктәп яшь буынга белем һәм тәрбия бирүдә халыкның милли традицияләренә нигезләнгәндә генә үзенең тәрбияви һәм белем бирү бурычларын уңышлы хәл итә ала.

Тәрбия планының төп максаты – тормышка һәр яктан әзерлекле, камил, үз милләтенең, матди һәм рухи байлыкларын арттыручы, туган халкының киләчәген кайгыртучы шәхес тәрбияләү.

Бурычлары:

– халкыбызның милли үзенчәлекләрен, күркәм сыйфатларын, йола-гадәтләрен, гаилә этикасын кечкенәдән аңлатып, укучыларны өлкәннәр үрнәгендә тәрбияләү, буыннар бәйләнешен тәэмин итү;

– әхлакый сыйфатлар тәрбияләү, балаларны кешеләр белән аралашу кагыйдәләренә өйрәтү, югары әдәп, әхлак сыйфатлары булдыру; иҗади сәләт һәм милли үзаң формалаштыру;

– туган телебез, мәдәниятебез үсеше өчен җаваплылык хисе булдыру;

– йолалар нигезендә сәламәт яшәү рәвеше алып бару.

Төп принциплары:

– сыйныфта гуманлылык мөнәсәбәтләре урнаштыру;

– укучыларның белем дәрәҗәсен арттыру һәм иҗади фикер йөртү сәләтен үстерү;

– балаларда гомумкешелек сыйфатларына аңлы караш тәрбияләү;

– иҗтимагый активлыкны үстерүгә юл күрсәтү.

Халкыбызның алдагы көне, язмышы бүгенге балаларны, яшьләрне тәрбияләү белән бәйләнгән. Тәрбия эшендә авыр, әлегә хәл ителмәгән мәсьәләләр шактый күп. Бүген без укучыларны туган телдә укырга һәм язарга, сөйләргә өйрәтү белән генә чикләнмичә, һәр яклап камил шәхес тәрбияләүнең бер юнәлеше булган милли культура формалаштыру, халкыбызның милли-мәдәни рухын тәрбияләү юнәлешендә эшлибез.

Әдәплелек, тыйнаклык, намуслылык, башкаларга хөрмәт белән карау кебек әхлакый сыйфатлар һәр милләт кешесенә хас. Милли культура формалаштыруда иң мөһиме – халык традицияләренә, гореф-гадәтләренә нигезләнеп, әхлаклылык сыйфатлары тәрбияләү.

Укучыларда милли мәдәният турында бербөтен күзаллау булдыру – туган телеңне белү һәм шул телдә аралашу; халык авыз иҗатын – әкиятләр, мәкаль-әйтемнәр, табышмаклар, бишек җырларын белү; шигырьләр, җырлар өйрәнү; халыкка хас әдәп кагыйдәләрен, туган як табигатен, милли халык уеннарын белү дигән сүз.

Шәхес тәрбияләү – ул укучыларда башка милләт кешеләренә, аларның мәдәниятенә уңай мөнәсәбәт булдыру дигән сүз. Без балаларда үз халкыбызга, үз илебезгә мәхәббәт тәрбияләү белән генә чикләнмичә, кайда яшәүләренә һәм нинди милләт кешеләре булуга карамастан – барлык халыкларны, аларның мәдәниятен, гореф-гадәт, традицияләрен хөрмәт итәргә, табигатьне яратырга өйрәтәбез, гомумкешелек кыйммәтләре белән таныштырабыз. Үз мәдәниятләре белән беррәттән, укучылар башка халыкларның да мәдәниятен, телен белергә тиеш.

Балаларга дөрес тәрбия бирүдә ата-ананың абруе көчле. Аларның шәхси үрнәге генә балаларның мәхәббәтен яулый ала. Шуңа күрә ата-аналар дөрес тәрбияне иң беренче чиратта үзләреннән башларга тиеш. «Гыйлем вә тәрбия орлыкларын хәзер ихлас вә мәхәббәт илә чәчсәгез, киләчәктә файдалы җимешләрне дә үзегез җыярсыз», – ди Р.Фәхреддин.

Яшь буынга дөрес тәрбия бирү вазыйфасына һәр ата-ана җаваплы карарга тиеш. Ә моңа тиешле педагогик белем алу, тәрбия бирү чараларын белү, үтәү нәтиҗәсендә генә ирешергә мөмкин. Ә мәктәп менә шул зур вазифаны башкара ала. Бу юнәлештә түбәндәге темаларга ата-аналар җыелышлары, кичәләр һ.б. үткәрәбез.

1. «Тәрбиядә ата йогынтысы».
2. «Ни чәчсәң – шуны урырсың».
3. «Кыз балалар, ир балалар тәрбиясе бер-берсеннән нәрсә белән аерыла?»
4. «Укучы нинди шәкерт әдәпләрен үтәргә тиеш».
5. «Ата-ана әдәпләре».
6. «Гаилә учагы нинди булырга тиеш».
7. «Хатын-кыз – дөньяның тоткасы».
8. «Изге балалар күктән төшмиләр».
9. «Ата-ананың олуг бурычы»

В.Казыйхановның «Әхлак дәресләрен», Р.Фәхреддиннең «Балаларга үгет-нәсыйхәт» исемле китаплары класс сәгатьләрендә һәрвакыт кулланыла.Татар теле һәм әдәбияты укытучысы буларак төп максатым – укучыларда халкыбызның буыннан буынга күчеп килгән әхлакый сыйфатларын тәрбияләү. Әдәбият дәресләренең эчтәлегенә бәйләп, тормышта очрый торган гыйбрәтле мисаллар китерү, аларга бергәләп аңлатма бирү, укучыларны җәлеп итә торган алымнар куллану, уңай нәтиҗәгә китерә, дип уйлыйм.

Дәресләрдә әдәплелек сыйфатларын аңлату белән генә чикләнмичә, әхлак кагыйдәләрен үтәү гадәтләре тәрбияләү өчен гаиләдә дә, мәктәптә дә тиешле шартлар булдыру кирәк.

Яшь буынга белем һәм тәрбия бирү ил тормышының өстенлекле өлкәсенә әверелә бара, яшьләрне тәрбияләүгә юнәлтелгән федераль һәм республика программалары гамәлгә ашырыла. Әлбәттә, аларны укытучылардан башка тормышка ашыру мөмкин түгел. Чөнки алар, мәктәптә үз фәннәре буенча белем бирүдән тыш, укучылар белән төрле чаралар үткәрә, балаларның психологик үзенчәлекләрен өйрәнә, уй-фикерләрен белә, әти-әниләре белән тыгыз элемтәдә тора.

Менә шулай, мәктәбебездәге төрле чаралар укучыларга милли белем һәм тәрбия бирүгә мөмкинчелек бирә. Киләчәктә дә без аны дәвам итәрбез.

Әйе, киләчәгебез – балаларда. Халкыбызның күркәм гадәтләрен, матур сыйфатларын, рухи хәзинәләрен буыннан-буынга тапшыру – без, укытучылар алдында торган зур бурычларның берсе. Шуңа без укучыларга татар телен, халкыбызның тарихын, әдәбиятын, сәнгатен, гореф-гадәтләрен өйрәтүне максат итеп куеп эшлибез.

# ПАТРИОТИК ТӘРБИЯ: ТРАДИЦИЯЛӘРҺӘМ ИННОВАЦИЯЛӘР

**Зайнуллина Люция Гаптрауфовна**
*Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы*
*муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе*
*«Сосна төп гомуми белем мәктәбе»*
*Тәрбия эшләре буенча директор урынбасары*

*«Тәрбиясе булмаган җирдә гүзәл*
*ашлык җитешмәгән кебек, тиешле*
*тәрбия бирелмәгәндә, гүзәл кеше дә җитешмәс.*
*Шулай икән, тәрбия – иң кирәкле эш булачактыр».*
***Р.Фәхретдин***

Күренекле мәгърифәтчебез, галим – педагог Р.Фәхретдиннең яшь буынны тәрбияләүдә әйтеп калдырган гыйбарәсе бүгенге көн өчен үтә актуаль. Патриотик тәрбия – бик киң мәгънәне аңлата. Ул бала күңелендә туган йортка, эти-әнигә, туган авылга, аның тарихына мәхәббәт уятудан гыйбарәт. Үз төбәген белмәгән, өйрәнмәгән, аңа битараф кеше үз туган илен ярата алмый. Шуңа күрә укучыларга патриотик тәрбия бирү һәр укытучының бурычы дип саныйм.

Патриотизм нәрсә ул? Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә: «Патриотизм – ул үз илеңне, халкыңны өзелеп ярату һәм үз Ватаның өчен армый – талмый көрәшергә әзер тору. Патриотизм-гасырлар буе тәрбияләнеп килгән тирән хис» – дигән мәгънәдә. Бүгенге көндә безнең алда торган мөһим бурычларның берсе – тормышка әзер булган, үз Ватанына чын күңелдән бирелгән Кеше, Гражданин һәм Патриот тәрбияләү. Ә кем соң ул патриот? Патриот – үзенең туган җирен, халкын, Ватанын сөюче, шулар өчен һәртөрле корбаннарга да әзер булган кеше.

Белгәнебезчә, 2025 нче ел Россия президенты В. В. Путинның 16.01.2025 № 28 Указы нигезендә, Ватанны саклаучылар елы дип игълан ителде. Шул максаттан мәктәбебездә патриотик тәрбиягә тагын да күбрәк басым ясыйбыз.

Укучыларда гражданлык һәм патриотик хисләр тәрбияләү юнәлешләре:

а) республикабыз, туган ягыбыз тарихы, мәдәнияте турында мәгълүмат бирү;

б) төбәктә яшәүче язучылар, сәнгать кешеләре белән очрашулар үткәрү;

в) халкыбызның гореф-гадәтләре, традицияләре белән тулырак таныштыру;

г) хезмәт һәм сугыш ветераннары белән очрашулар үткәрү.

Мәктәптә укучыларны патриотик тәрбияләүгә юнәлдерелгән чаралар системасы эшләнгән. Дәресләрдә һәм сыйныфтан тыш чараларда педагоглар балаларда шәхеснең актив тормыш позициясен формалаштырырга, гражданлык гамәлләре, демократик тәртип һәм аралашу тәҗрибәсе тупларга, конструктив – тәнкыйди фикерләү, мөстәкыйльлек күнекмәләрен үстерергә, халык традицияләренә һәм мәдәниятенә хөрмәт тәрбияләргә, башка халыкларның мәдәнияте һәм традицияләренә ихтирамлы һәм толерантлы мөнәсәбәт тәрбияләргә омтылалар, балаларны принципларны һәм кыйммәтләрне аңларга өйрәтәләр.

Шушы юнәлештә эшләнелә торган, мәктәптә традициягә кергән чаралар белән таныштырып үтәсе килә.

2025 нче ел Ватанны саклаучылар елын ачу чарасын тантаналы рәвештә ачып җибәрдек. Әлеге чара 3 өлештән торды. Беренче өлеше концерт номерлары, ә икенче өлешендә этиләр һәм малайлар арасында эстафета, өченче өлешендә этиләр һәм егетләр арасында волейбол ярышы үтте. Әлеге чара һәр укучының, эти-әниләрнең күңелләренә кереп калды.

